ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№04 (387)
АПРЕЛЬ2024

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

– МИН ҺӘРВАКЫТ ТАТАРСТАННЫ ҮРНӘК ИТЕП КУЯМ

№04 (387)
АПРЕЛЬ 2024

16+

Редакция:
Адрес: 420066, Россия,
Татарстан Республикасы,
Казан, Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

АЛГА, ЗАМАН БЕЛӘН БЕРГӘ!

Сезнең ярашмаганны яраштырырга тырышып караганыгыз бармы? Булырдай эш түгел, дибез без, өметсезләнеп. Шушы көннәрдә, отпуск өчен бер генә ай булса да калдырыйк дип тырышканда, моңа тагын бер кат инандык. Майда – KazanForum, июньдә – БРИКС Уеннары. Һәм алга таба арту тәртибендә: Нефть-газ форумы, Kazan Digital Week, БРИКС саммиты, Россия-Кытай форумы... Һәм тагын галәм масштабында булмаган, әмма аңа карап мөһимлеге кимемәгән дистәләгән вакыйга... Аларны «Татарстан» игътибарыннан читтә калдыру укучыга мәгълүматны җиткереп бетермәүгә тиң булыр иде. Шуңа күрә ничек кенә тырышсак та, ял итү өчен вакыт таба алмадык. Икенче яктан караганда, ә бәлки бу яхшыгадыр, республикада салмак провинциаль тормыш агышы инде күптән динамик, бай, киеренке активлыкка алышты. Катлаулыракмы? Әйе. Җаваплыракмы? Һичшиксез. Аның каравы колачлырак, кызыклырак, җанлырак. Перспективалырак та. Ә сез ял дисез...

Сезнең хезмәт сөючән редакциягез

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина, vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров, sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре: Руфия Фазылова, Николай Коновалов, Евгения Чеснокова, Дмитрий Сивков
Авторлар: Римма Вильданова, Әхмәт Шакиров, Айдар Шәйхин, Луиза Янсуар
Фотографлар: Александр Ефремов, Алсу Шакирова, Лилиана Вәлитова
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Анастасия Хатыйпова
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: Казахстанның Казандагы Генераль консулы Ерлан Искаков. Александр Ефремов фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнә

ММЧ исеме: ТАТАРСТАН TATARSTAN

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.
Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды. Адрес: 420066, Россия, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: А-0670
Басарга кул куелды: 15.04.2024
Чыгу көне: 19.04.2024

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900
Коммерция директоры урынбасары:
Алина Майорова,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9033-132-741
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева, milyaushanb@tatmedia.com

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛАХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы: «ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ
Адрес: 420097, Россия, Татарстан Республикасы, Казан, Академическая ур., 2

«Татарстан» журналына ТРның барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин:
Индекс **П2381** – татар телендә ярты елга
Индекс **ПА468** – татар телендә бер елга

Индекс **П2378** – рус телендә ярты елга
Индекс **ПА471** – рус телендә бер елга

2024 елның ярты еллыгына ТР буенча язылу бәясе:
1212 сум 00 тиен китереп бирешле,
1175 сум 40 тиен соратып алганда.
2024 елга ТР буенча язылу бәясе:
2423 сум 92 тиен китереп бирешле,
2350 сум 66 тиен соратып алганда.

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» журналына 103 яшь

\# Татарстанның 100 җәүһәре

\# бары тик Татарстанда

ДӨНЬЯ ШӘҺӘРЛӘРЕНЕҢ БЕРДӘМ ТАВЫШЫ

Казан Россиянең өченче башкаласы һәм Татарстан башкаласы гына түгел. Шәһәр «Берләшкән шәһәрләр һәм җирле хакимиятләр» Бөтендөнья оешмасы Евразия бүлегенең штаб-фатиры булып тора. Мондый карар егерме ел элек, 2004 елның апрелендә, Евразия бүлегенең оештыру конференциясендә кабул ителгән иде. Шулай итеп, республика башкаласы төп офисы Барселонада урнашкан «Берләшкән шәһәрләр һәм җирле хакимиятләр» Бөтендөнья оешмасына кергән җиде төбәк үзәгенең берсенә әйләнде. Оешманың төп бурычы – «бөтендөнья демократик җирле үзидарәсенең бердәм тавышы һәм яклаучысы булу». Оешманың штаб-фатиры Казанда урнашкан бүлеге БДБ илләре һәм Монголиянең 1000 нән артык шәһәрен һәм җирле хакимиятләр ассоциацияләрен берләштерә. Ә Казан мэры Илсур Метшин 2021 елда «Берләшкән шәһәрләр һәм җирле хакимиятләр» Бөтендөнья оешмасының президенты итеп сайланды.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

4. Архитектура иленә сәяхәт, яисә Студентны министрга кадәр ничек үстерергә

12. Уңайлылык территориясе Кайсы шәһәрләрдә яшәү уңайлы һәм куркынычсыз

игелекле эшләр

16. Шаккатыра белүче Минзәлә Кызыл китапка кергән аккошларны кайда күрергә була

26. Һава шартларына бәйсез рәвештә Минзәлә аграрийларыннан нәрсәгә өйрәнергә мөмкин

28. Туган тел, IT-технологияләр һәм йөзү Туган телне кайда балалар бакчасыннан ук өйрәнәләр

34. Туган як риваятьләре Генералиссимус Суворовның әтисе безнең төбәктә нәрсә эшләгән

38. Гаилә бәхетенең ачкычы Аны Заһриевлар гаиләсендә ничек саклыйлар

42. Агафуровлар йорты хәзинәсе Аны табарга кем ярдәм иткән

44. Редакция кухнясында Казахстан консулының яраткан ризыклары нинди

56. Актив озын гомер серләре Легендар тренер ничә спорт мастеры әзерләгән

58. Сугыш кайтавазы Ветеран белән очрашу мизгелләре

мәңгелек кыйммәтләр

62. Тарихи сәхифә Шакир Измайлов татар тарихында нинди эз калдырган

70. Безнең киштәдә «Без кешеләрне, комдай, иләк аша илибез...»

78. Татар авыллары Югары Тәкермән нинди хыяллар белән яши

87. Ай кәефе Республика ифтары

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: **protatarstan.ru**

Фото: Александр Ефремов

Акыллы гамәлләр



26.03

Талия Миңнуллина, ТР ИҮА җитәкчесе, – 2024 елда беренче ТР Инвестиция советы нәтиҗәләре турында:

– Инвестиция советы 230 млрд 141 млн сумлык 10 инвестиция проектын карады. Инвесторлар ачарга ниятләгән эш урыннарының гомуми саны 20 меңгә якын. Без сәнәгать үсеше тенденциясенең дәвам итүен күрәбез, авыл хуҗалыгында эшкәртү темплары үсештә, социаль проектларга кызыксыну арта.

Игелекле эшләр

12.03

Фәрит Хәнифов, Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры, – ТР Министрлар Кабинетында узган брифингта:

– Татарстанда «Куркынычсыз һәм сыйфатлы автомобиль юллары» илкүләм проектын тормышка ашыруга быел 8,2 млрд сум акча юлланды, шул исәптән 2,4 млрд сумы – федераль бюджеттан, 5,8 млрд сумы – республика бюджетыннан. 97 км юлны норматив хәлгә китерү һәм 28 күперне ремонтлау планлаштырыла. Объектларда эшләр башланды. Бу ел ахырына норматив таләпләргә туры килгән төбәк юллары өлеше – 52% ка кадәр, шәһәр агломерацияләренеке 85% ка кадәр артачак.

Мәңгелек кыйммәтләр

22.03

Зиннәтулла Билалетдинов, «Ак Барс» хоккей командасының баш тренеры, – сезон йомгакларына багышланган матбугат конференциясендә:

– Мин тренер булып бик озак эшләдем. Бу эш миңа ошый. Бу үзем яраткан, үзем өйрәнгән, үзем белгән шөгыль, ул миңа канәгатьлек китерә. Ләкин баш тренер булып эшләү зур көч, эмоцияләр таләп итә. Бу зур җаваплылык та. Шуңа күрә хоккейда эшләвемне дәвам итсәм, үзем өчен яхшырак булыр, дип уйлыйм, әмма башка форматта.

Фото: tatar-inform.ru, ak-bars.ru

игелекле эшләр

акыллы гамәләр/

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Вуз **ничек** шаккатыра ала

Студентны **ничек** министрга кадәр үстерергә

Кайсы шәһәрдә яшәү уңайлырак

АРХИТЕКТУРА ИЛЕНӘ СӘЯХӘТ

Евгения Чеснокова

Казанда җәмәгать киңлекләре белән беркемне дә шаккатырып булмый. Парк-скверлар, яр буйлары шәһәр халкының гадәти ял итү урынына әверелде. Алар уңайлы, матур, кызыклы итеп ясалган, күп функцияле, аларны иҗат иткән архитекторлар ниятләгәнчә, төрле идея һәм активлыклар белән тулы. Һәм без аларның барысын да беләбез кебек. Шуңа да һич көтмәгән урыннарда, мәсәлән, югары уку йортында ял зоналарына тап булу гаҗәпкә калдыра.

Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты (КДАТУ) студентлары, мәсәлән, шәһәр буйлап йөрүгә караганда, үзләре укыган бинада ял итеп йөрүне өстенрәк күрәләр һәм, гаҗәпләнмәгез, монда күрерлек, карарлык, шаккатарлык әйберләр шактый!

Университеттагы һәр урын үз мәгънәсенә ия. Барлык вак-төяк лабораторияләр, проект үзәкләре һәм остаханәләр халыкара дәрәҗәдәге фәнни-белем бирү үзәкләренә әверелгән, аларда бик рәхәт һәм уңайлы. Һәм, әлбәттә, тышкы бизәкләрдән тыш, мон-

Фото: Алсу Шакирова

да, университетның фәнни мәктәпләренә таянып, төзелеш бизнесы өлгеләре буенча практикага юнәлдерелгән инженерлык белеме бирү гамәлгә ашырыла.

– Бүген бездә эзерлекнең төрле юнәлешләре буенча фән-белем бирү үзәкләре эшли – ныклыкны исәпләү, архитектура, дизайн, юл технологияләре һәм материаллары, төзелешне тәэмин итү системалары – дип аңлата КДАТУ ректоры Рәшит Низамов. – Барлыгы унтугыз шундый үзәк эшли.

Казан мэры Илсур Метшин шундыйларның берсе – «Нигез» үзәгенә килгәч болай диде: «Булдырасыз, бик тәэсирләндем! Минем күз алдында бу еллар эчендә бик җитди үсеш (барды – ред. иск.)! Әлбәттә, Казан архитектура мәктәбенең иң яхшы традицияләрен дәвам итүегез сөендерә һәм бер урында тормавыгыз да, шундый күп җиңүләргә ирешәсез, ә ярыш – ул һәрвакыт файдалы: илдәге шундый ук югары уку йортлары, шундый ук яшь, креатив архитекторлар фонында нинди булуыбызны күрү әйбәт».

ЯХШЫ СТУДЕНТ ЯХШЫ АБИТУРИЕНТТАН ЧЫГА

– Рәшит Корбангалиевич, сез бит үзегез дә кайчандыр шушы югары уку йортын тәмамлагансыз...

– Әйе, һәм шушында хезмәт юлын да үттем: ассистенттан алып профессорга һәм ректорга кадәр...

– Димәк, сез белергә тиеш: бүген замана таләпләренә җавап бирүче төзүче яки архитектор әзерләү өчен нәрсә кирәк?

– Бездә укырга керү өчен бик югары дәрәҗә саклана. Бюджетка эләгү өчен БДИ буенча уртача 75 балл сорала. Түләүлегә – 68. Йөз балл җыючылар да, олимпиадаларда җиңүчеләре дә бар. Мөһим момент: безгә түләп укырга килүчеләр бик күп. Быел без беренче курска бюджет урыннарына 600 кеше һәм түләүлегә 300 кеше кабул иттек. Магистратурада тагын да кызыклырак картина: бюджетка 150 кеше кабул ителгән, бюджеттан тыш – 250. Һәм бу безнең бакалаврларны башка югары уку йортларына бушлай укырга чакыру шартларында!

– «Сыйфатлы» абитуриентларны нәрсә белән җәлеп итәсез?

– Бүген бездә халыкара дәрәҗәдәге кампус булу бик мөһим. Без 2008 елда ук Ирек Әнвәр улы Фәйзуллин (хәзерге Россиянең төзелеш һәм ТКХ министры, ә ул вакытта ул безнең попечительләр советы рәисе иде) белән бергә, университетка шундый кампус кирәк дигән карарга килдек. Бездә бит мо-



Университетыбызны үстерү концепциясендә инфрастуктура үсешен һәм заманча фән-мәгариф мохите бурычларын чишә алырлык **халыкара дәрәҗәдәге кампус формалаштыру** мөһим максат иде.

ның өчен барысы да бар: бер территориядә урнашкан уку корпуслары, лабораторияләр, тулай тораклар...

Әмма шул ук вакытта университет аркылы чыга торган ишегалды булып тора иде – туры һәм күчерелмә мәгънәләрдә. Чехов урамыннан кешеләр безнең территория аша Калинин урамына узалар. Ишегалды тулы машина, музыка, тәмәке тарту... Уку биналарының тузган стеналарына карасаң, монда бер дә архитекторлар белән төзүчеләр укый дип уйламассың. Күп очракта Универсиада-2013 ярдәмендә без кампус периметрын яба алдык, яңа спорт комплексы төзедек, бина фасадларын тәртипкә китердек, дизайнерлар интерьерларны бизәде.

Быел ук безнең кампус аша өч мең ярым укучы үтте, шул исәптән республика районнарыннан да. Безгә экскурсиягә киләләр. Бу кампусны күреп киткән укучыларның 85–90 проценты безнең абитуриент булачак. Чөнки без тудырган шартларда уку-яшәү үзе бер бәхет. Бездә студентлар йокларга да: ура, иртәгә яңадан укырга барабыз, дип яталар!

ИНИЦИАТИВАЛАРНЫ ХУПЛЫЙБЫЗ

– Фәнни мәктәпләр, практикага юнәлдерелгән белем – болар барысы да грамоталы кадрлар таләп итә. Ә КДАТУ биредә башкала вузлары белән ярыша аламы?

– Без фәнни мәктәпләребезне, абруйлы укытучыларыбыз һәм галимнәребезне саклап кала алдык. КДАТУда бик яхшы материаллар белеме мәктәбе, көчле ныклык конструкторлары, юлчылар, дизайнерлар, архитектура мәктәбе бар. Аларга ярдәм итәргә тырышабыз, анда яшь кадрлар килүен көтәбез. Без укытучыларыбызга башка югары уку йортларына караганда күбрәк

Университетта һәр локация үз мәгънәсенә ия. Мәсәлән, монда, янып торган хәрефләр артында, студентлар статик, циклы һәм режимлы шартларда деформацияләнгән туфраклы модельләрдә төзелеш нигезләрен өйрәнә.

түли алмыйбыз, ләкин без аларга бик яхшы эш шартлары тудырдык. Халыкара дәрәҗәдәге кампус, менә шушы үзәкләр, көчле студентларны туплый алу... Укытучыларның инициативаларын хуплыйбыз. Мин үзем дә ассистенттан профессорга кадәр юл үткән кеше, укытучының нәрсә белән яшәгәнен, аны ничек эшкә тартырга кирәклеген беләм, коллективтагы һәркем белән диярлек таныш.

САЗЛЫКТА НИЧЕК ДӨНЬЯ ДӘРӘҖӘСЕНДӘГЕ СТАДИОН ТӨЗЕРГӘ

– Практикага юнәлдерелгән белем бирү эш бирүчеләр белән ныклы элемтәләр урнаштыруны күздә тота...

– Без җитештерүчеләр, сәнәгатьчеләр, төзүчеләр белән дус. Фәнни эшләнмәләребезгә ихтыяҗ бар. «Без моны булдырачакбыз һәм унбиш елдан соң аның никадәр яхшы эшләвен күрсәтәчәкбез!» димибез. Юк, безнең эшләнмәләр бүген үк кирәк! Фәнни-тикшеренү проектлары белән елына 100 млн сум акча эшлибез. Шуңа күрә галимнәребез ректордан күбрәк акча ала.

Һәм алар катлаулы проектлар: башкалар хәл итә алмаган, бик зур җаваплылык таләп иткән эшләр. Әйтик, безнең «Ак Барс Арена». Ә бит үз вакытында бу сазлыклы урында стадион төзергә мөмкин дигән нәтиҗәне без ясаган идек. Җаваплылык дәрәҗәсен сизәсезме? Ә 2015 елда, анда йөзү буенча дөнья чемпионатын кабул иткәндә, футбол кырында бассейннар урнаштырылды, аларны яңгырдан капларга кирәк иде. Без консоль конструкцияләр тәкъдим иттек, һәм бу эшкә яраклы идея булып чыкты, җитмәсә, моңа кадәр тәкъдим ителгән балка һәм конструкцияләргә караганда дүрт тапкырга экономиялерәк булып чыкты.

Тагын бер мисал: безнең университет янында элеккеге Шамов хастаханәсе урнашкан. Реконструкция вакытында, безнең исәпләргә таянып, бу бинаны яңа нигезгә күчереп утырттылар һәм аннан бер метр ераклыкта утыз метр тирәнлектә парковка ясадылар. Әгәр без берәр нәрсәне дөрес исәпләмәгән булсак, бина түбәнгә шуышыр иде. КДАТУ белгечләре менә шундый, еш кына башкалар алынырга җөрьәт итмәгән проектларны эшли.

Әйе, без җитештерүчеләр белән тыгыз хезмәттәшлек итәбез. Өстәвенә, республикада федераль дәрәҗәдәге күп кенә мегапроектлар тормышка ашырыла – М-12 трассасын салуны гына алыйк, анда да безнең белгечләр катнашты. Университет студентлары да, мондый проектларда катнашып, практикага юнәлдерелгән белем ала. Әлбәттә, аларга хезмәт базарында да ихтыяҗ кимеми.

– Безнең кампус һәм безнең фән-белем бирү үзәкләре һәрвакыт кунакларыбыздан иң югары бәя ала. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов бездә җитди лаборатория базасы булуын берничә мәртәбә билгеләп үтте. Күптән түгел генә бездә Россиянең фән һәм югары белем бирү министры Валерий Фальков булып китте, аңа КДАТУ үзәкләре бик ошады. Ул шундый үзәкләрне оештыру тәҗрибәсен башка университетларга да таратырга кирәк, дип басым ясады.

– Яхшы белгеч әзерләү өчен, беренчедән, яхшы абитуриент кабул итәргә кирәк.

КЛИМАТ һӘМ ИНТЕНСИВ ХӘРӘКӘТ ЮЛЛАРГА КАРШЫ

– Сүз уңаеннан, М-12 турында. Россиядә юлларның начар булуы мемга әйләнгән факт кебек. Без кайчан да булса, шул исәптән сезнең уку йорты ярдәменә таянып, илебездә юл проблемасын хәл итә алырбызмы?

– Без бу юнәлештә бик күп эшлибез. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов күрсәтмәсе буенча, мәсәлән, юлда ни өчен тәгәрмәч эзләре – колеялар барлыкка килү проблемасын тикшердек. Әйе, гадәттәгечә юлчыларны сүгәбез – алар асфальтны суга салалар, составына нәрсәнедер салып бетермиләр, яисә киресенчә күбрәк салалар. Чынлыкта юл бизнесы – югары дәрәҗәдә оешкан хезмәт. Анда заманча техника, заманча материаллар һәм технологияләр бар. Күләмнәр белән генә, бернинди дә хилафлык китермичә эшләп була. Ләкин, кызганычка каршы, бездәге климат, тизлекнең арта баруы, хәрәкәтнең интенсивлыгы юлларны җимерә. Юл бит ул – тере субстанция. Өстебездәге күлмәк, машинадагы резина тузган кебек, юллар да җимерелә. Ремонт ясарга туры килә.

Моңа бәйле рәвештә еш кына юллар төзелешендә бетон куллану мәсьәләсе карала, монда да үзенең плюслары, минуслары бар.

Бүген безнең вуз Татарстан Рәисе күрсәтмәсе буенча авылга керү юллары өчен конструктив схемалар булдыру юнәлешендә тагын бер бурычны хәл итә. Әгәр авылда биш кеше яши икән, анда классик юл төзү – артык исрафчылык. Ләкин җирле материалларны кулланып һәм үзгәртеп эшләп була. Бу экономияләү мөмкинлеге дә, бүгенге тренд та, һәм без әлеге юнәлештә эшлибез. Хәзерге вакытта республиканың төрле районнарындагы утызга якын участокта шундый эш бара.

ГАРВАРДТАН КИМ ТҮГЕЛ

– Казан студент-архитекторлары еш кына төрле халыкара конкурсларда җиңү яулый. Аларның проектлары арасында шәхсән сезне гаҗәпләндергәннәре бармы?

– Сезгә архитекторларга карата карашымның ничек үзгәрүе турында сөйлим әле. Мин инженерлыкка укыдым. Хәрби өйрәнүләр вакытында архитекторлар һәрвакыт җиңелрәк эш белән шөгыльләнә иде – нәрсәдер буйыйлар, майлыйлар, ябыштыралар. Ә без окоп казыйбыз. Ә миңа бу ошамый иде, шуңа архитекторларны яратып бетерми идек. Ә унбиш



Фән-белем бирү үзәкләре – университетның фәнни мәктәпләренә таянып, төзелеш бизнесы өлгеләре буенча практикага юнәлдерелгән инженерлык белеме бирү мәйданчыклары.

еллап элек, инде ректор чагымда, ашханәне үзгәрергә уйладык. Акча аз, әмма безнең архитекторлар һәм дизайнерлар стеналарны ничектер төсләр ярдәмендә үзгәрттеләр, абажурларны алыштырдылар, яңа төрле лампочкалар элделәр дә ашханәбез бөтенләй башка төрле күренә башлады! Менә шул ике-өч тиенлек проекттан соң, минем архитектура һәм дизайнга карашым үзгәрә башлады.

Бездә Резеда һәм Илнар Әхтәмовларның архитектура-проект үзәге уңышлы эшли. Аларны чыннан да бөтен дөньяда беләләр, һәм хәтта хәзерге вакытта да безнең яшьләрне Япониягә, АКШка конкурсларга чакыралар, һәм алар анда җиңәләр дә. Күптән түгел, мәсәлән, Ксения Крепкогорская белән Данил Назаров Нью-Йоркта кунакчыллык индустриясе архитектурасы өлкәсендә сәүдә үзәкләре түбәләрендә иҗтимагый инфраструктуралы кемпинглар булдыру проекты өчен беренче премия алдылар. Мария Световидова Nisshin Kogyo (Япония) компаниясе оештырган халыкара конкурста җиңде, анда бөтен дөньядан җыелган 400 гә якын профессиональ архитектор катнашты.

Ә студент архитектура бюроларының эш сыйфаты бәяләнә торган Алтынчы Лиссабон архитектура триенналесында без, Гарвард (АКШ) һәм Bartlett School (Англия) белән беррәттән, дөньяның иң яхшы алты архитектура мәктәбе исемлегенә кердек.

– Әңгәмәләрегезнең берсендә сез КДАТУ Россия Төзелеш министрлыгы күрсәтмәсе буенча федераль стандартлар эшли дигән идегез. Сүзнең нинди стандартлар хакында баруын белү кызык булыр иде…

– Хәтерлисезме, Советлар Союзында ГОСТлар һәм СНИПлар бар иде? Хәзер нормативлар базасы үзгәрә. Россия стандарты – илебездә төп нормалар булдыру органы. Аның күрсәтмәсе буенча Төзелеш министрлыгы яңа стандартлар эшли. Министрлык вәкилләре университетка килделәр, безнең базаны күрделәр, эшебез турында белделәр. Әйтергә кирәк, безгә килеп киткән җитештерүчеләрдә, җитәкчеләрдә партнерларыбыз булу теләге туа, ә абитуриентларның безнең университетта укыйсы килә башлый!

Әйе, без бүген кайбер Россия стандартларын эшлибез – эшләнмә һәм конструкцияләрнең ныклыгын һәм чыдамлылыгын тизләтелгән методларга таянып фаразлау буенча, заманча цемент җитештерү буенча, шулай ук төзелештә аддитив технологияләр өчен яңа композицион материаллар эшләү (3д-принтерлар кулланып) буенча һ.б.

СТУДЕНТНЫ МИНИСТРГА КАДӘР ҮСТЕРҮ

– Сезнең заман студенты бүгенгесеннән нык аерылып торамы?

КДАТУНЫҢ 19 ФӘН-БЕЛЕМ БИРҮ ҮЗӘГЕ:

- **«Ныклык»** – төрле катлаулы төзелеш конструкцияләрен исәпләү, проектлау һәм сынау;
- **«BFFT. space»** – Резеда һәм Илнар Әхтәмовларның махсус авторлык программалары буенча архитекторлар әзерләү;
- **«Системалар»** – төзелешне тәэмин итүнең инженерлык системаларын исәпләү һәм проектлау;
- **«Технологияләр»** – төзелеш комплексы өчен яңа материаллар һәм технологияләр уйлап табу;
- **«Юллар»** – яңа юллар өчен технологияләр һәм материаллар;
- **«Цифрлы юллар» - ТИМ** – юлларны төзү һәм эксплуатацияләү технологияләре;
- **«15»** – мәгълүмат-белем бирү киңлеге;
- **«Цифр»** – төзелештә мәгълүмати модельләштерү технологияләре;
- **«Шәһәрне планлаштыру»** – шәһәрләрне территория-киңлек ягыннан үстерү;
- **«Архитектор»** – заманча архитектура проектлары;
- **«Дизайн»** – архитектура мохите дизайны, график дизайн, интерьер дизайны, ландшафт дизайны;
- **«ДАШКА»** – балалар архитектура мәктәбе, балалар һәм мәктәп укучыларының архитектура-дизайн компетенцияләрен үстерү үзәге, 3500 укучы;
- **«Архфизика»** – тормыш-көнкүреш мохите параметрларын тикшерү һәм проектлау;
- **«Мирас»** – тарихи объектлар архитектурасын реставрацияләү һәм саклау;
- **«Нигез»** – «Геотехника» һәм «Төзелеш» үзәкләреннән гыйбарәт – нигезләрнең төрле типларын һәм биналарның грунтларын һәм конструктив карарларын тикшерү;
- **«Механика»** – материалларның төрле төрләренең җимерелүен тикшерү;
- **«Яктылык»** – биналарны ясалма һәм табигый яктырту, биналарның интерьерын һәм фасадларын яктырту;
- **«Девелопмент»** – инвестицион-төзелеш проектларының тормыш циклларының барлык стадияләрендә икътисади һәм идарә бурычларын чишү;
- **«Ташкыннар»** – төзелешне тәэмин итүнең инженерлык системаларын исәпләү һәм проектлау.

– Бүген студентлар минем замандашларым кебек үк искиткеч. Патриотлар, акыллылар, дустанә. Алар бары тик индивидуалистрак кына. Мәсәлән, алар тулай торакта бер бүлмәдә яшәп, аерым ашарга мөмкин. Без студент чакта бу мөмкин түгел иде. Әгәр бәрәңге кыздырабыз икән, аны этажыбыз белән бергә ашадык.

– КДАТУны тәмамлаучылар арасында иң зур уңышка ирешкәне, мөгаен, без инде искә алып үткән Россия төзелеш һәм ТКХ министры Ирек Фәйзуллиндыр. Бүгенге студентлардан министрлар үсә аламы?

– Ә нигә юк, ди? Кешедә билгеле бер сыйфатларның берләшүе генә булырга тиеш. Беренче урында – системалы рәвештә эшләү, максатлар куя белү, аларга ирешү теләге һәм осталыгы. Моның өчен күп физик, интеллектуаль, эмоциональ көч куярга кирәк. Мин студентларга бу турыда һәрвакыт сөйлим. Мин дә бит фән докторы, профессор, ректор булдым. Илле биш яшемдә инглиз телен өйрәнә башладым. Үз алдыма максат куйдым һәм шуңа таба барам. Иң мөһиме – эшли белү.

– Сез «Телеграм»да үз каналыгызны да алып барасыз, диләр?

– Әйе, анда ике мең ярымга якын язылучы бар. Телеграм-каналымны чыннан да үзем алып барам, барлык чаралар турында сөйлим – студентлар концерты булсынмы, футбол матчымы...

Университетта шаярталар, әлбәттә, янәсе, бик уңайлы – ректорның кайдалыгы һәрвакыт билгеле. Җитмәсә, проблемалар туган очракта мөрәҗәгать итәргә дә мөмкин, мин һәрвакыт ачык һәм янәшәдә.

– Телеграм-каналымны чыннан да үзем алып барам, барлык чаралар турында сөйлим – студентлар концерты булсынмы, футбол матчымы...

БЕЗГӘ ТӘҖРИБӘ АЛУ ӨЧЕН КИЛӘЛӘР:

- Санкт-Петербургның вице-губернаторы Владимир Княгинин;
- «Төньяк-Көнбатыш» стратегик эшләнмәләр үзәге» Фонды директоры Марина Липецкая;
- **вуз ректорлары һәм вәкилләре:**

  Мәскәү дәүләт автомобиль-юл техникасы университеты;

  Россия транспорт университеты;

  Себер дәүләт автомобиль-юл университеты;

  Санкт-Петербург дәүләт архитектура-төзелеш университеты;

  Тәбриз ислам сәнгате университеты (Иран);

  МООСАО, УМО вузлары.
- **җитәкчеләр:** «СИБУР», «КАМАЗ»; «Северсталь», «Газпромнефть – Битум материаллары» кебек компанияләр; «Казан шәһәре Торак-инвестиция компаниясе», «Грань», «Ак Таш», «Бриз», «СМУ-88», «Унистрой», «Сувар-Казан», «ТСИ» девелопер һәм төзелеш компанияләре; «Кнауф», «Сен-Гобен», «Ак Барс Металл», «Казан корыч профильләр», Казан йорт төзелеше комбинаты кебек төзелеш материаллары, эшләнмәләре һәм конструкцияләре җитештерүчеләр; «Автодор» ТК, «Россия юллары ФТИ» ФАУ, «Татавтодор», «Татдорпроект», «АСТЕХ Индастриз» ҖЧҖ (Санкт-Петербург) кебек юл-төзелеш предприятиеләре һәм оешмалары; SIMETRA (Санкт-Петербург), «ТрансНет» (Мәскәү) территориядә транспорт челтәрен планлаштыру программаларын эшләүчеләр; «Ферекс» Сәүдә йорты, «Ледел» яктылык-диод яктырткычларын җитештерүчеләр һ.б.

КДАТУ студентлары шәһәр буйлап йөрүгә караганда, үзләре укыган бинада ял итүне өстенрәк күрә һәм, гаҗәпләнмәгез, монда күрерлек, карарлык һәм шаккатарлык әйберләр шактый!

РОССИЯ ШӘҺӘРЛӘРЕ: УҢАЙЛЫЛЫК ТЕРРИТОРИЯСЕ

1	Мәскәү	индекс 304
2	Санкт-Петербург	индекс 270
3	Түбән Новгород	индекс 237
4	Казан	индекс 226
5	Краснодар	индекс 225
6	Ростов-на-Дону	индекс 223
7	Пермь	индекс 220
8	Уфа	индекс 220
9	Новосибирск	индекс 219
10	Воронеж	индекс 213

Фото: tatar-inform.ru

2023 ЕЛ ӨЧЕН ШӘҺӘР МОХИТЕ СЫЙФАТЫ ИНДЕКСЫ. ТОП-10*

ШӘҺӘР МОХИТЕ СЫЙФАТЫ ИНДЕКСЫ ел саен Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан РФ субъектларыннан, Россия Эчке эшләр министрлыгыннан, Россия Мәдәният министрлыгыннан, Роспотребнадзордан, Росстаттан, ДОМ.РФ үсеш институтыннан алынган мәгълүматлар нигезендә исәпләнә.

Марат Хөснуллин,
РФ Хөкүмәте Рәисе урынбасары:

– Шәһәр мохите сыйфаты индексы – шәһәрләр ярышы түгел, ә аларның үсеш өстенлекләрен билгеләүнең нәтиҗәле коралы. Ул проблемаларны хәл итү өчен беренче чиратта нинди чаралар күрергә, шәһәр мохитенең сыйфатын яхшырту һәм кешеләрнең тормыш дәрәҗәсен күтәрү өчен кайсы өлкәләрне активрак үстерергә кирәклеген аңларга ярдәм итә. Быел без аны инде алтынчы тапкыр санадык. Узган ел нәтиҗәләре буенча уңайлы шәһәрләр саны 759 га җитте. Индексның уртача кыйммәте 200 балл тәшкил итә. 2019 ел белән чагыштырганда, ул 18 %ка үсте. Шунысын билгеләп үтәм: ирешелгән өч күрсәткеч тә милли проектның планлаштырылган кыйммәтләреннән югарырак. Бу саннар гына түгел, ә реаль эшләр, чөнки кешеләр шәһәрләрнең үзгәрүен күрәләр.

6 киңлек
X
6 күрсәткеч
=
36 индикатор

360 балл
шәһәр индексының максималь мөмкин булган күләме

Индекс шәһәр мохите сыйфатының 36 индикаторын бәяли. Алар шәһәр киңлекләренең иң кирәкле алты төрен күрсәтә: торак, иҗтимагый-эшлекле һәм социаль-ял инфраструктурасы һәм аларга якын булган киңлекләр, яшел территорияләр, яр буйлары, урам инфраструктурасы һәм гомумшәһәр киңлеге. Аларның һәрберсе алты күрсәткеч буенча бәяләнә: куркынычсызлык, уңайлылык, экологик яктан чисталык, тәңгәллек һәм төрлелек, әйләнә-тирә мохитнең заманчалыгы һәм хакимият органнары эшенең нәтиҗәлелеге.

** Халык саны миллионнан арткан шәһәрләр категориясе.*

AGRATOR DISK

AGRATOR DISK 9000
AGRATOR DISK 12000

ДИСКЛЫ ЧӘЧҮ КОМПЛЕКСЛАРЫ

Төп комплектациягә Zero Max вариаторлы чәчү аппараты, бункер тәгәрмәче әзен йомшарта торган индивидуаль әйләнмәле система, тигезли торган штригель тырма.

Тар тырма оптималь күрүне тәэмин итә. Бункерны җыеп куюның өр-яңа системасы гомуми билгеләнештәге юлларда каршылыкларсыз хәрәкәт итәргә мөмкинлек тудыра.

Реклама

AGROMASTER
www.pk-agromaster.ru
Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы,
Мөслим авылы, Тукай ур., 33 а, e-mail: agromaster@mail.ru
тел: 8 (85556) 2-39-08, 2-43-59, сот.: 8-939-396-83-44

акыллы гамәлләр

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Кайсы күперне Туп-патша белән чагыштырып була

Кем суда йөзә торган йорт төзегән

Минзәлә аграрийларыннан **нәрсәгә** өйрәнергә мөмкин

Туган телне **кайда** балалар бакчасыннан ук өйрәнәләр

Казахстан консулының яраткан ризыклары **нинди**

Минзәлә

Фото: Александр Ефремов, Әскәр Сабиров, Fu[illegible]ka kids. Иллюстрация: Оксана Кузнецова. РЕКЛАМА

МИНЗӘЛӘ: АККОШЛАР ШӘҺӘРЕ

Җәй көне әлеге шәһәргә туп-туры аккошлар кайта, Кызыл китапка кертелгән кошлар. Аккошларның ел саен кайтуын монда атаклы Туп-патша һәм Чаң-патша белән чагыштыралар. Ә һәр мәктәп укучысы, дүрт арифметика гамәлен белүдән тыш, йөзә һәм татар телендә ким дигәндә 172 сүз белергә тиеш. Без – Минзәләдә.

Шәһәрне шәһәр итү өчен, югары даирәләр указы гына җитми, тарих кирәк. 16 мең кеше яши торган кечкенә генә Минзәләдә тарих – адым саен. Ленин урамында, аңа күрше тыкрык һәм урамнарда XIX гасыр–XX гасыр башындагы сәүдәгәр йортлары урнашкан. Нык, зәвыклы, дәрәҗәле – аларны төзегән сәүдәгәрләрнең үзләре кебек үк. Лупповның күлмәк сәүдә йорты, Андреев кунакханәсе, сәүдәгәр Горбушин утары, Кунак йорты бинасы, сәүдәгәр Федоров кибете, Глафира Стахеева акчасына төзелгән Епархия училищесы, өяз дворяннары җитәкчесе Пасмуровның керем йорты...

Минзәлә, бәхеткә, бертөсле панель йортлар төзү хисабына күптән инде үзенең тарихи йөзен җуйган шәһәрләр исемлегенә керми – бу яктан язмыш аңа мәрхәмәтле булган. Иске йортлар тарих чоңгылында җуелу түгел, хәтта ки яңа тормышка яраклашып та китә алган, гәрчә хуҗаларын һәм билгеләнешләрен югалтсалар да. Епархия училищесы хәзер – педагогика училищесы, Лупповның күлмәк сәүдә йорты – «Купец» сәүдә йорты, ә Пасмуров керем йортында район администрациясе урнашкан. Монда нindидер кычкырып торган төсләр, тарихи фасадларны каплаган ямьсез сайдинглар юк – барысы да тыйнак, олпат һәм нык. Минзәләдә тарихка сак карыйлар: өяз дворяннары җитәкчесе йортын реставрацияләүгә 18 миллион сум акча сарыф ителгән, аның каравы фасады нәкъ 150 ел элек булгандагы кебек – иң вак элементларын кадәр, чөнки реставраторлар элеккеге сызым һәм фотоларга таянып, чагыштырып эшләгән.

Кайчандыр Зур Уфа дип аталган Ленин урамы сезне туп-туры Минзәлә елгасының биек ярына алып чыгачак. Ә бу урыннан шәһәрнең истәлекле урыннарга кадәр ара – кул сузымында гына.

ЕКАТЕРИНА КҮПЕРЕ. ТУП-ПАТШАДАН ТЕКӘРӘК

– Менә ул, безнең Екатерина күпере, – ди җирле туган якны өйрәнү музее директоры Лариса Кәрамова, елга уртасыннан күтәрелгән челтәрле конструкциягә ишарәләп. – Халыкта аны Екатерина күпере дип йөртәләр. Легенда буенча, күперне императрицаның Минзәләгә килүен көткән җирле сәүдәгәрләр төзеткән. Дөрес, Екатерина Минзәләдә беркайчан да булмаган. Тик бу атама каян килгән соң? Кем белә, бәлки, халык хәтере патшабикәгә рәхмәтен шул рәвешле белдергәндер, чөнки 1781 елда Минзәлә шәһәр статусын алган, ә бу Екатерина идарә иткән чор...

Чынлыкта Минзәлә елгасы аша тимер юл күпере 1910 елда төзелә башлый. Төзелешкә земство һәм җирле сәүдәгәрләр акча бирә, чөнки тимер юл булмау сәүдә эшен нык тоткарлый. 1914 елда күпер әзер була. Николай II хәтта Бөгелмәдән Минзәләгә кадәр тимер юл салу турында Указга кул куярга да өлгергән, дип сөйлиләр, әмма шул вакытта Беренче бөтендөнья сугышы башлана... Әлбәттә, эшләр туктала, бу матур күпер дә шул килеш тимер юлсыз кала.

Минзәләлеләр, әллә шаяртып, әллә чын күңелдән ышанып, күперләрен Туп-патша һәм Чаң-патша кебек раритетлар белән бер рәттә тора, дип саный. Янәсе, беренчесе беркайчан да атмаган бердәнбер туп, икенчесен дә билгеләнеше буенча беркайчан да кулланмаганнар, ә инде Минзәләнеке дөньяда беркайчан да поезд узмаган бердәнбер тимер юл күпере. Совет чоры пессимистлары аны гомумән беркая да алып бармый торган күпер дип йөрткәннәр.

Әмма минзәләлеләрне белгәннәр әйтер: күпер, сирәк сәнәгать архитектурасы һәйкәле буларак, анда-санда килүче кунаклар өчен генә хезмәт итә алмый, ул һич кенә дә эшсез торырга тиеш түгел. Шуңа күрә бүген күпер уникаль җәмәгать киңлегенең бер өлеше санала. Мондый урын башка бер генә шәһәрдә дә юк – монысын тәгаен әйтә алабыз.

ЕЛГА КИҢЛЕКЛӘРЕ БУЙЛАП ЯЛ

Ницца, Сочи яр буйлары... Начар түгел, әлбәттә, әмма бигрәк гадәти. Ә менә Минзәләдәге Екатерина күперенә таба без җәяүләп атлаган сукмак – бөтенләй башка. Хәтта хәзер – тирә-якта берничә кышкы балык тоту фанатыннан кала, беркем дә күренмәгән ап-ак карлы тынлыкта да. Ә җәй көне бу урыннар оҗмахка тиң: уң якта да – су, сул якта да – су, хәтта җәйге чиллләдә дә монда җиләс, салкынча һава бөркелеп тора, ерак түгел генә урнашкан утрауны исә сирәк очрый торган кошлар үз иткән.

Минзәлә елгасы яр буе - шәһәр халкы һәм туристларның яраткан ял итү урыны. Ул елганың ике як ярын тоташтырган күперләр белән бергә дамба буенча сузылган. Күперләрнең берсе менә ул – Екатерина күпере, корычтан, зур, матур бизәкләр белән бизәлгән. Аңа аяк басуга, өслеккә батырылган рельслар һәм паровоз макетына тап буласың.

– Җәмәгать киңлеген ясарга тотынгач, Екатерина күпере, стильләштерелеп булса да, үзенең беренчел билгеләнешен искәртеп торырга тиеш дип уйлаштык, шул рәвешле монда рельслар һәм ясалма паровоз пәйда булды, – дип аңлатты Лариса Кәрамова.

Сүз уңаеннан, ял итү зонасының бизәге саналган икенче күпер кай ягы беләндер Казанның «Миллениум» күперен хәтерләтә: хәтта алгы өлешенә дә «М» хәрефе ясалган. Әллә монда да «Миллениум»мы?

– Юк, Минзәлә! – дип төзәтәчәк сезне беренче очраган кеше үк. Минзәлә халкының горурлыгы ул.

Инде күперләрне беркая да алып бармый дип әйтә алмыйбыз. Минзәлә елгасының икенче як ярында бүген уңайлы итеп төзекләндерелгән пляж эшли, шәһәр халкы аның турында дистә еллар хыялланган. Киенү, душ бүлмәләре булган, ятаклар куелган су коену урыны. Сочидагы кебек дияргә була, тик чистарак һәм чиратлар юк. Ә шәһәр ягында – Фестиваль мәйданы, анда концерт һәм дискотекалар уза, гаилә белән ял итү территориясе, балалар пляжы ясалган, парковка бар. Тагын бер «фишка» – җирле уха фестивале, ул елына ике тапкыр уза. Иң зур балыкны эләктерергә, шуңардан аш әзерләү буенча осталык дәресе алырга яисә иң тәмле ухaны авыз итеп карарга

(ә монда бөтен кунакны да сыйлыйлар!) теләүчеләр бирегә хәтта күрше республика һәм өлкәләрдән дә килә.

– Җәй көне монда тагын бер арт-объект пәйда булачак. Паровоз, бу юлы чыны, – дип серне ачты Минзәлә муниципаль районы башкарма комитеты рәисе Марат Кәримов. – Ә елга буйлап аквабайкта яки катамаранда йөрергә мөмкин булачак, аларга электр моторы куелган – экологик чиста шәһәрдә экология иң беренче урында.

Безнең илдә электр катамараннары кайда ясала? Сорап торырга да кирәкми. Әлбәттә, Минзәләдә! Җирле эшмәкәр Дамир Каюмов шөгыльләнә бу эш белән.

АКВАБАЙК – КҮҢЕЛ ӨЧЕН

Дамир Каюмов һөнәре буенча – дизайнер, холкы буенча – уйлап табучы. Яхшы эшләнгән, ләкин уңайсыз яки эстетик ягы уйланып бетмәгән нәрсәләр аны теше сызлаган кебек йөзен чытарга мәҗбүр итә. Һәм эшкә дәртләндерә. Шул ук вакытта бер кешедә рәссам да, конструктор да, бизнесмен да ничектер тыныч кына яшәп ята.

– Менә карагыз, бу шактый билгеле бер француз фирмасы эшләгән катамаран, – ди Дамир, безгә бер фото күрсәтеп. – Мин аның кайбер нәрсәләрен яхшыртыр идем, әмма, гомумән алганда, начар катамаран түгел. Һәм бәясенә күз салыгыз – мондый экземпляр якынча 800 мең сум тора. Кыйбатмы? Сүз дә юк!

Җәй көне Каюмов пляжда прокат пункты ачачак, моның өчен муниципалитет субсидия бүлеп биргән. Ләкин Каюмов автомобиль бәясе торган педальле катамаран (асылда гадәти су велосипеды) сатып алуны акчаны суга салу, әрәм-шәрәм итү дип саный. Һәм үз конструкциясен уйлап табу эшенә керешә.

Эш барган саен күбрәк уйлана: кешеләр катамаранны рәхәтләнеп ял итәр өчен ала бит, шуңа күрә бөтен кешенең дә педаль әйләндерәсе килеп тормый. Ә су велосипедына двигатель куйсак, ничек булыр? Җиңел, экологиягә зыян китерми торганын?

Бүген Каюмов уйлап тапкан катамараннар тиешле сынауларны узган һәм күпләп җитештерүгә кертелгән. Кайберләре гадәти, педальле, актив ял яратучылар өчен, икенчеләренә электр моторы урнаштырылган, боларына тынычлап ял итәргә теләүчеләр ягыннан ихтыяҗ бар. Бәясе? «Француз» тиңдәшеннән дүрт тапкырга арзанрак.

Каюмовның Мюнхгаузен түгел, ә идеяләре ташып торган прагматик бизнесмен булуына Минзәләдә күп тапкырлар инанганнар инде. Берничә ел элек, мәсәлән, ул кыйммәтле машиналар формасында бала караваты җитештерүне оештыра. Беренче үз балаларым сынап карады, ди Дамир. Әти кеше-

Җирле эшмәкәр Дамир Каюмов.

Конструкторлык сәнгатенең тагын бер җимеше – суда йөзеп йөри торган йорт. Барлык уңайлылыклары булган һәм, әлбәттә, электрга көйләнгән.

нең йокы машиналары өчен материалны ничек җентекләп сайлавы турында язып торырга кирәкме икән? Мәсәлән, дсп-такта тәкъдим итүче дистәләгән тәэминатчы арасыннан бары тик икесен генә сайлап ала ул – аларның материалларында гына формальдегид рөхсәт ителгән нормадан артмаган чөнки...

Каюмов балалар «мерседес»лары, «мазда»лары, «скания»ләре Канада, Испаниядә, БДБ илләрендә, безнең илдә үз сатып алучыларын таба – Made in Menzelisk. Дөрес, дөньяда вазгыятьнең үзгәрүенә бәйле рәвештә товарны дустанә булмаган илләргә җибәрү туктатыла, әмма Россиядә, Казахстанда яки Кыргызстанда бу «иномаркалар» элеккечә базарда бар әле.

Сүз уңаеннан, автомобиль-караватларның барлык өлешләре дә Дамир Каюмов идарәче директор булып эшләгән Минзәлә сәнәгать паркында җитештерелә икән. Әйтергә кирәк, алар бик гади детальләр түгел. Ортопедик матраслар һәм рәшәткәләр, «автомобиль» кузовлары, фурнитура...

Бүген бу сәнәгать паркында алты резидент исәпләнә. Әлегә – алты. Җиргә салым ташламалары, буш мәйданнар, кече һәм урта бизнеска ярдәм итү республика программасы акчасы хисабына үткәрелгән юл – барысы да резидентлар саны артачагына ишарәли. Нәкъ менә икенче бер сәнәгать паркындагы кебек үк – «Изыскатель»дә бүген тугыз резидент эшли. Аларның да үз казанышлары бар: эре федераль челтәрләрнең берсе җирле минераль суны сыйфаты буенча иң яхшысы дип тапкан.

Җирле эшмәкәрләрнең идеяләре һәм планнары бер елга гына исәпләнмәгән. Тынгы белмәс Каюмов бүген үзе үк куйган чираттагы бурычны ничек үтәргә дип баш вата. Базарда тәкъдим ителгәннәрдән уңайлырак, яхшырак булырга тиешле аквабайк ясау белән шөгыльләнә. Бернинди дә бензин двигателе булырга тиеш түгел – бары тик электр двигателе генә!

Минзәлә елгасында тагын бер ул ясаган конструкторлык сәнгате җимеше навигация ачылуын көтә. Суда йөзеп йөри торган йорт – барлык уңайлылыклары булган һәм, әлбәттә, электрга көйләнгән. Башкача була алмый! Чөнки минзәләлеләр өстенлекле үсеш юнәлешләренең берсе итеп экологик туризмны сайлаган.

Ни өчен нәкъ менә экологик? Чөнки эре предприятиеләр булмаган Минзәләдәге кебек чиста һава, мөгаен, башка бер генә шәһәрдә дә юктыр. Районда шулай ук Игим боры бар, анда кәҗәболан, селәүсен, кабан һәм Кызыл китапка кергән сирәк кошлар яши, чын табигый хәзинә бу. Ә сез җәйгә аккошлар кайта торган шәһәрләрне күп беләсезме? Минзәләгә кайталар.

ШӘҺӘР ИНТЕРЬЕРЫНДА – ТАБИГАТЬ

Җәй көне аккошларны карарга дип, еракларДан киләләр. Аклары белән бергә, май-июнь айларында елгада шулай ук аеруча сирәк очрый торган кара төстәгеләре дә күренә, һәм алар көзгә кадәр монда яши. Аларга сокланыр өчен, хәтта Минзәлә елгасына төшәргә дә кирәкми – нәзакәтле бу гүзәлләрне шәһәр үзәгендәге Ленин исемендәге парктан карарга була. Паркны яңартканда урнаштырылган стереоторба аша. Башкалаларда туристлар өчен урнаштырылган оптик җайланмалардан аермалы буларак, биредә аңардан бушлай файдаланырга мөмкин.

Ленин паркы шәһәрдә соңгы дистә ел эчендә федераль һәм республика программалары кысаларында грант акчаларына төзелгән яки яңартылган берничә җәмәгать киңлегенең берсе: шәһәр тәкъдим иткән проектлар бөтен илдән тупланган йөзләгән кандидат арасыннан сайлап алынган. Пляжы, ял итү сукмагы булган Минзәлә елгасы яр буе кебек үк, Ленин паркы да ял итәргә, спорт белән шөгыльләнергә, үзең өчен нindидер яңалык алырга мөмкинлек бирә торган күпфункцияле киңлеккә үрнәк мисал булып тора.

Парктагы йөзьяшәр агачлар арасыннан сузылган табигый сукмак буенча атлаганда, сез районга хас флора һәм фауна турында барысын да диярлек беләчәксез: рәсемле такталар кечкенә генә энциклопедияне хәтерләтә. Бераз гына читтәрәк - спорт сукмагы,





анда кыш көне – чаңгыда, ә җәй көне чаңгы роллерларында йөриләр. Минзәләнең XVI гасырда биек елга ярында күтәрелгән ныгытмадан башлануын искә төшерүче тарихи сукмак та бар монда. Ә янәшәдә – рәссам иҗатына лаек манзара ачыла торган күзәтү мәйданчыгы. Әлбәттә, пикник өчен урыннар да каралган...

Шуңа күрә экотуризм белән шәһәрдә үк шөгыльләнергә мөмкин, чөнки бу парк – шәһәр уртасындагы чын урман. Аны яңартканда, сүз уңаеннан, барлык агачларны да диярлек саклап калырга тырышканнар – бер генә сәламәт агач та юк ителмәгән.

Ә Минзәләнең матур елгалары буйлап сәяхәт итәргә теләсәгез, ай да җитмәс. Утраулары булган Минзәлә елгасы – менә ул! Бераз арырак Чулман җәйрәп ята. Ә менә монысы – урман-кырлар арасыннан еландай боргаланып аккан Ык елгасы! Сулыкларның озынлыгы буенча да Минзәлә байлар арасында. Ык елгасы Россиянең өч төбәгендә ага, әмма аның дүрттән бер өлешеннән артыгы Минзәлә районына туры килә, биредә ул Чулманга кушыла...

Дөрес, туган якларының байлыгы турында сөйләгәндә, Минзәлә халкы, һичшиксез, фаҗигале мизгелләрне дә искә төшерәчәк. Дүрт ел элек монда ике аккошны атканнар. Ул явызлар килгән кешеләр булган, ерак китәргә өлгермәгәннәр – аларны шунда ук тотканнар. Бәхеткә, әлеге тетрәндергеч хәлдән соң да аккошлар монда кайтудан туктамаган. Кошлар, әйтерсең лә, барысын да сизә: Минзәлә җире бары тик мәрхәмәтлелек территориясе генә була ала.

Кайчандыр Минзәләгә шәһәр статусы биреп, императрица аның туграсын да раслаган: анда муллык символы – лачын ыругының бер төре – шоңкар сурәтләнгән. Өстәвенә, геральдикада очарга дип канатларын җәйгән кош югары омтылыш, алдан күрә белү һәм рухи байлык символы булып тора. Бик туры килә торган тугра, шулай бит?

КҮЗ САЛ,
СИН ЯШӘГӘН
ДӨНЬЯ НИНДИ
МАТУР!

АВЫЛ: ҮСЕШ НОКТАЛАРЫ

Руфия Фазылова

Май аендагы салкыннар, җәйге корылык аркасында Минзәлә районы аграрийлары 2022 елгы уңышның яртысыннан күбрәген генә җыйган. Хәер, гаҗәп тә түгел: Татарстан буенча да якынча күрсәткечләр шундыйрак булды. Әмма аңа карап, районда сөт, ит җитештерү кимемәгән, ә киресенчә арткан. Моның сере нәрсәдә соң?

Авыл хуҗалыгы үсеше буенча Минзәлә районы беренче бишлеккә керми, тик артта да түгел, алтын урталыкта алар. Ләкин яшермиләр: максат – беренче бишлеккә керү. Моның өчен җирлек тә бар кебек: мөгезле эре терлекнең баш санын 19 900 гә җиткергәннәр. Узган ел бу сан ике меңгә азрак булган. Әлбәттә, баш саны арткач, мал азыгы да кирәк. Шуның өчен 2024 елда барлык сөрүлек җирләренең 30 проценттан артыгында терлек азыгы культуралары утыртырга уйлыйлар.

Минзәлә районында авыл хуҗалыгы җирләренең мәйданы 97,7 мең гектар, шуның 82,544 мең гектары – сөрүлек җирләре. Район язгы чәчүгә тулысынча әзер.

– Районның авыл хуҗалыгы тармагы инвесторлар, эре фермер хуҗалыкларының яхшы күрсәткечләре нәтиҗәсендә алга бара, – диде Минзәлә авыл хуҗалыгы идарәсе җитәкчесе Илфар Халиков. – Мисал өчен «Минзәлә таңнары» ҖЧҖ узган ел 22,6 мең тонна бөртекле культура җыеп алды. Уңыш гектарыннан 22,1 центнер чыкты. «Август – Мөслим» ҖЧҖ 18,6 мең тонна иген үстерде, уңыш гектарыннан 25 центнер чыкты. «Калмурзино» ҖЧҖ, «Илнур» КФХ, «Заиковский» ҖЧҖнең нәтиҗәләре бик яхшы.

Икмәккә бәя түбән булу сәбәпле, Минзәлә районы авыл хезмәтчәннәре күпләп көнбагыш, рапс үстерә башлаган. Әш шунда ки, районның тәҗрибәле җитәкчесе Алмаз Шәрипов 2022 елда «АГРОМАЙ» компаниясе оештыра. Беренче елда хуҗалыгында үстерелгән көнбагыш, рапсны эшкәртеп, рафинацияләнмәгән май ясый. Алга таба

Фото: Александр Ефремов. РЕКЛАМА

районның башка хуҗалыклары үстергән көнбагыш, рапсны да сатып алып, салкын ысул белән пресслап, сыек май җитештерәләр.

Минзәләдә сөтчелек тармагы үсештә. Бүген биредә көн саен 250 тонна сөт савалар, бу узган ел белән чагыштырганда, 178 процент дигән сүз. Табигый ки, бозаулар саны да арткан: 2023 елда 8 380 баш туган, бу 2022 ел белән чагыштырганда, 2 508 башка күбрәк.

Районның эре хуҗалыгы – «Камский Бекон» ҖЧҖ эшчәнлегенә аерым тукталасы килә. Егерме еллап элек, сыер фермалары киләчәктә шундый булачак дисәләр, һич ышанмас идек. Бүген исә чынбарлык шундый: биредәге чисталыкны күреп хәйран калдык. Чын заманча фермалар: барысы да автоматлашкан, тәүлегенә 50 шәр литр сөт бирә торган нәселле сыерлар. Ә саннардан хәтта баш әйләнә... Хуҗалыкта 12 440 баш мөгезле эре терлек бар, шуларның 5 625 е савым сыеры. Яңа сөт комплексы 6 мең баш сыерга исәпләнгән.

– «Камский Бекон» ҖЧҖ сөт кенә түгел, ит җитештерү буенча да районда беренче, – диде Илфар Мәгарифович – Әле алга таба тагын да зураерга исәплиләр. «Камский Бекон» сыйфатлы ит җитештерә. Мөгезле эре терлек нәселле – Бельгиядән кайтарылган. Маллар, безнең шартларга тиз җайлашып, бик яхшы күрсәткечләр бирә.

...Кошчылык тармагы, яшелчә үстерү, сугым цехлары – кайсы гына өлкәне карасаң да, минзәләлеләр үсештә. Эре агрофирмалар кебек, шәхси ярдәмчел хуҗалыклар да алардан калышмаска тырыша. Әлбәттә, аларны чагыштырып булмый, масштаблар төрле. Әмма тегеләре дә, болары да сөт, ит җитештерә, иген, яшелчә үстерә. Заманга яраклашып, яңа җиһазлар кайтаралар. Фермерларның үз акчалары да керә, дәүләттән дә ярдәм зур. 2023 елда гына да Минзәлә авыл хуҗалыгы тармагында эшләүчеләр дәүләттән 596 миллион сум ярдәм алган. Мондый саннар, күрсәткечләр булганда, республиканың авыл хуҗалыгы тармагы берничек тә артта кала алмый, шулай бит?!

БАЛАЛАР БАКЧАСЫННАН УК – ТУГАН ТЕЛ, МӘКТӘП ЭСКӘМИЯСЕННӘН – IT-ТЕХНОЛОГИЯЛӘР

Евгения Чеснокова

Дөнья стандартлары буенча шахмат турнирлары, мәгарифтә VR-технологияләр, мәдәни киңлектә мәңгелек классика белән кискен заманчалык кушылмасы... Бу районда социаль тормыш өлкәсе бай һәм төрле. Монда һәркем үзенең иҗади, интеллектуаль яки спорт талантын ача һәм тормышта куллана ала.

Без килгәндә Өметбаев исемендәге Минзәлә дәүләт драма театрының яшь артистлары сәхнәдә иде. Бөтен залга рок яңгырый, солистлар ниндидер катлаулы заманча хореография өйрәнәләр...

КЕЧКЕНӘ ШӘҺӘРНЕҢ ЗУР ТЕАТРЫ

– Балалар өчен яңа спектакль кабатлый идек, – дип аңлатты театр директоры Илнур Гайниев. – «Югалган вакыт турында әкият», Шварц буенча. Бездә яшь тамаша-

Фото: Александр Ефремов. РЕКЛАМА

чылар өчен спектакльләр күп, хәтта курчаклар да бар.

Театр труппасы кечкенә – 30 кеше. Ә менә афишадагы репертуар саллы, директор сүзләренчә, аңа 47 спектакль кергән. Татар классикларын да, Достоевскийны, Шекспирны, Айтматовны да куялар... Заманча авторлар буенча күп кенә эксперименталь постановкалар бар.

Ә барысы да бер гасырдан элегрәк башланган.

– Без – республикадагы иң өлкән татар театрларының берсе, – дип сөйли Илнур Гайниев. – Быел сиксән сигезенче сезонны үткәрәбез. Әмма чынлыкта безнең бинага инде 130 ел, аны 1894 елда җирле сәүдәгәрләр акчасына халык аудиториясе буларак төзегәннәр.

Халык аудиториясе, хәзергәчә әйтсәк, җәмәгать киңлеге була инде. Бинада 1890 нчы елларда бушлай китапханә урнашкан, шулай ук халык сәнгать коллективлары да эшләгән.

– Әйе, безнең театр буш урында гына пәйда булмаган, – дип сөйли Татарстанның халык артисты, театр музее мөдире Рәзилә Муллина. – Һәвәскәрләр монда революциягә кадәр үк спектакльләр куйган. Бөтен халык аларны бик рәхәтләнеп караган. Сүз уңаеннан, кайбер мәгълүматлар буенча, безнең сәхнәдә СССРның булачак халык артисты, Мәскәүдәге Кече театр йолдызы Елена Гоголеваның әнисе уйнаган.

Башкаланың танылган шәхесләре турында әйткәндә, шунысын да искә алыйк: 1950 нче елларда совет кинематографындагы иң гүзәл затларның берсе Алла Ларионова сугыш елларында әнисе белән Минзәләгә эвакуацияләнә. Ун яшьлек кыз яралылар өчен куелган концертларда катнаша, шигырьләр сөйли. РСФСРның халык артисты дәрәҗәсенә ирешкән ханымның актерлык карьерасы әнә шулай башлана. Мөгаен, бу концертларда Минзәлә театры артистлары аның партнерлары булгандыр, чөнки сугыш елларында алар бик күп концерт һәм спектакльләр куйганнар. Хәтта бервакыт, ир-ат артистлар

сугышка китеп бетү сәбәпле, театрны ябарга җыенгач та, Минзәлә актрисалары ир-ат рольләрен үзләре уйнарга карар кылалар. Һәм бу эшне уңышлы башкаралар.

Тарихта беренче спектакльнең исеме дә сакланып калган, ул 1930 нчы еллар уртасында – Минзәлә татар театры рәсми рәвештә оешканнан соң куела. Кәрим Тинчурин пьесасы буенча куелган «Зәңгәр шәл» спектакле була ул. Минзәлә артистлары, Рәзилә Мирхәт кызы искә алганча, һәрвакыт тавышларының матур булуы белән аерылып торган:

– 1952 елда без Казанда гастрольләрдә булдык, һәм Салих Сәйдәшев, актерларыбызның җырлавын тыңлагач, хәтта академия театрында да мондый тавышлар юк, диде. Бахия Вәлиева, Ания Фәттахова театрыбызның сандугачлары иде!

Бераз гына сугыш елларына тукталыйк. Театр музеенда бер мандолина кадерле экспонат санала, килгән вакытларында Муса Җәлил шул мандолинада уйнарга яраткан. 1941 ел ахырында башкалар белән бергә ул да Минзәләгә хәрби-сәяси курсларга килә. Аннан фронтка китә, әмма бик кыска вакытка гына килсә дә, Минзәлә артистлары белән бергә концертларда катнаша.

Сүз уңаеннан, сугышның беренче елында шәһәрдә оештырылган концертларда тагын кем катнашканын беләсезме? Зиновий Гердт! Минзәләгә Мәскәү хәрби-инженер училищесын эвакуацияләделәр. Курсант Гердт 1942 елның гыйнварында хатынына болай дип яза: «Мин монда зур көч белән актерлык эшчәнлеген җәелдердем. Еш кына курчаклар һәм гитара белән концертларда чыгыш ясыйм».

Ә 1960 нчы еллар башында Минзәлә сәхнәсендә яшь артист Туфан Миңнуллин уйный. Шул ук вакытта монда күренекле драматургның беренче пьесасы – «Безнең авыл кешеләре» куела.

Театр һәрвакыт гастрольләргә йөри, Татарстан буенча гына түгел. 1957 елда Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы вакытында чыгыш ясаганнан соң, аңа дәүләт театры статусы бирелә.

– Һәм без элеккечә тәгәрмәчле театр, – дип елмая Илнур Гайниев. – Безнең төп керемебез дә гастрольләрдән килә. Күптән түгел Бөек Новгородта, Ярославльдә, Грозныйда булдык, тиздән Башкортстанга, аннары Ижевскига барачакбыз. Апрель аенда безне Казанда көтәләр...

Әлбәттә, Минзәлә районында да үз театрлары чыгышын көтеп алалар. Мондагы халык тамашаларны ярата һәм кадерли. Һәм үзе дә аларда актив катнаша: бүген район авыл клублары һәм мәдәният йортларында дистәләгән үзешчән иҗат коллективы эшли (шул исәптән сигезе «халык театры» исемен йөртә). Фольклор һәм бию ансамбльләре, хорлар һәм һәвәскәр театрлар – теләге булган һәркем үзе өчен иҗади шөгыль төрен таба ала. Алар арасында сәнгать мәктәбендә шөгыльләнүче балалар да, ветераннар (иҗади түгәрәкләргә йөрүче өлкәннәрнең саны ел саен арта бара) да, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр дә, халык коллективлары да бар.

Кайчандыр, Минзәлә театрының тәүге эш елларында, шул чор кешеләренең истәлекләренә караганда, артистлар халыкны агарту белән шөгыльләнгән: театрда катгый билгеләнгән урыннарда утырырга кирәк, спектакль вакытында сөйләшергә, көнбагыш чиртергә ярамый. Бүген районның теләсә кайсы торак пунктында яшәүчеләр китапханәләргә, мәдәният йортларына, кинозалларга йөри, театр спектакльләрен карый һәм үзләре дә концерт-спектакльләр

оештыруда актив катнаша. Мәдәни традицияләр элеккеге халык аудиториясенә генә сыешмый. Хәзер бөтен район шундый мәдәни җәмәгать киңлегенә әверелгән.

РОБОТОТЕХНИКА, ГРАФИК ДИЗАЙН. АЛГА ТАБА НӘРСӘ?

Театрдан ерак түгел генә - Минзәлә педагогика көллияте. Ул классик кызыл кирпеч бинага урнашкан. Бу йортны 1914–1918 елларда сәүдәгәр Стахеевлар төзеткән.

Узган гасыр башында Минзәлә үзәгендә салынган бу матур корылма баштан ук белем бирү максатларын күздә тоткан, әмма күпмедер вакыт буш торырга мәҗбүр булган, чөнки революция елларында мәгариф икенчерәк планга чигенә. 1932 елда гына ТАССР Мәгариф халык комиссариаты биредә рус һәм татар төркемнәре эшләгән педагогика техникумы ачуга ирешә. Соңрак техникум училище итеп үзгәртелә.

Бөек Ватан сугышы елларында нәкъ менә биредә Мәскәү хәрби-сәяси училищесының хәрби-сәяси курслары ачыла, шунда укучы курсантларның берсе Муса Җәлил була. Сүз уңаеннан, курсантлар биредә уку сыйныфларында ясап куелган күпкатлы агач сәкеләрдә йоклаган.

Муса Җәлил турында истәлекне, аның Минзәлә чорында язылган һәм өлешчә шәһәргә багышланган шигырьләрен халык шагыйрьнең исеме тыелган вакытта да кадерләп саклый. Ә 1970 елда нәкъ менә педагогика училищесы бинасында Советлар Союзында беренче Муса Җәлил музее ачыла, ул бүгенге көнгә кадәр эшли.

Аннары училище көллият итеп үзгәртелә, һәм 2010 елдан Минзәлә педагогика көллияте герой-шагыйрь исемен йөртә. Бүген бу урта һөнәри белем бирү уку йорты гына түгел, ә республика ресурс үзәкләренең берсе, аның базасында милли кадрлар әзерләү эше алып барыла, Татарстанда туган телдә белем бирүне үстерү һәм саклау шартлары тәэмин ителә.

Бүген көллияттә алты белгечлек буенча урта буын белгечләре әзерләнә: «Башлангыч сыйныфларда укыту», «Мәктәпкәчә белем бирү», «Махсус мәктәпкәчә белем бирү», «Физик культура», «Гамәли информатика» (тармаклар буенча), «Мәгълүмат системалары һәм программалаштыру».

Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумы тарихы да кызыклы. Аңа узган гасырдан да алдарак – 1889 елда, ягъни 135 ел элек нигез салынган. Ул вакытта ул I разрядлы Минзәлә түбән авыл хуҗалыгы мәктәбе санала. Хәзер бу техникум да ресурс үзәгенә әверелгән, биредә агрономнар, ветеринарлар, аш-су осталары, шулай ук техник белгечләр, икътисадчы һәм хисапчылар әзерлиләр. Шулай ук техникум базасында цифрлы аграр полигон булдыру планлаштырыла, анда авыл хуҗалыгында яңа технологияләрне студентлар гына түгел, ә республика агрокомпанияләрендә эшләүче хезмәткәрләр дә өйрәнә алачак.

Минзәләдә медицина училищесы да бар, анда дәвалау һәм шәфкать туташы эшенең нечкәлекләрен, фармакологияне үзләштерүче студентлардан тыш, район табиблары да, һөнәри курсларда укып, квалификацияләрен күтәрә ала.

Минзәлә районы мәктәпләре 2023 елда күп кенә чыгарылыш укучыларын БДИ буенча югары балл алырлык итеп әзерләгән – бу күрсәткеч буенча район республикада икенче урында тора. Ә өстәмә белем бирү өлкәсендә соңгы вакытта ИТ-



Минзәлә районын 10 елдан артык Айдар Фәслах улы Сәлахов җитәкли. Соңгы елларда ирешелгән уңышларда аның өлеше бик зур. Шушы көннәрдә генә район башлыгына 60 яшь тулды, аның көч-куәте әле ташып тора.

юнәлешне актив үстерәләр. Робот техникасы, график дизайн – боларның барысы белән дә Минзәлә укучылары рәхәтләнеп шөгыльләнә ала. Ә февраль аенда балалар иҗат йортында район башлыгы ярдәме белән VR-технологияләр белән җиһазландырылган өр-яңа сыйныф ачылган. Монда укучылар бүген пилотсыз очкычлар белән идарә итәргә өйрәнә.

Шулай да районның мәктәпкәчә белем бирү системасы турында күбрәк сөйлисе килә. Элек мәктәптә генә белем ала башлыйбыз дип уйлый идек. Балалар бакчалары җитди саналмый, ата-аналар балаларын эшкә барганда гына «калдырып торган» урын кебек иде. Ләкин соңгы ун елда мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә мөнәсәбәт үзгәрә башлады, хәзер алар рәсми рәвештә һәр кеше үтәргә тиешле өзлексез белем бирү чылбырының беренче баскычы дип таныла. Һәм монда, әлбәттә, һәркемгә мондый белемне алу мөмкинлеге тудырылу бик мөһим. Шуңа күрә Минзәлә районында мохтаҗларның йөз проценты балалар бакчасына урын белән тәэмин ителгән. Барлык бакчаларда да бер яшьтән алып өч яшькә кадәрге балалар өчен төркемнәр ачылган, һәм мондый балалар җирле балалар бакчаларында тәрбияләнүчеләрнең өчтән берен диярлек тәшкил итә.

Ә районда милли белем бирү нәкъ менә балалар бакчасыннан башлана. Сабыйлар бакчада татар телен өйрәнә. Педагогларның да конкрет максаты бар: беренче сыйныфка кергәндә һәр рус телле бала ким дигәндә 168 татар сүзен белергә тиеш.

Мәктәпкәчә һәм мәктәп белем бирү системаларының бәйләнешен тәэмин итү һәм балаларны һәрьяклап үстерү максатында район башлыгы инициативасы белән 2022 елдан район мәгариф учреждениеләре балаларны комплекслы тәрбияләүнең «Стремление в будущее» – «Киләчәккә омтылыш» муниципаль программасы буенча эшли. Программаны гамәлгә ашыру өчен барлык мәгариф оешмалары да тиешле материаллар белән тәэмин ителгән.

ЙӨЗӘ БЕЛМИСЕҢМЕ? ӨЙРӘТӘБЕЗ!

Балалар иҗаты йортының икенче катында берничә иркен кабинет шахмат клубына бирелгән. Ул кайбер башкала мәктәпләре дә көнләшерлек итеп җиһазландырылган.

Күз алдына китерегез: уен такталары өстендә махсус смартфоннар урнаштырылган, алар партиядәге һәр хәрәкәтне терки. Бөтен картина шунда ук уен залында да, холлда да урнаштырылган зур экраннарга чыгарыла, анда очрашу барышын «туры эфирда» тренерлар, уенчыларның әти-әниләре һәм барлык кызыксынучылар күзәтә. Гомумән, дөнья дәрәҗәсендәге мөһим матчлардан бер дә ким түгел.

Балалар иҗат йортында район башлыгы Айдар Сәлахов ярдәме белән VR-технологияләр белән җиһазландырылган яңа сыйныф ачканнар.



Боларның барысын да «Минзәлә – шахмат территориясе» клубы җитәкчесе Азат Шаһалиев уйлап тапкан. Һәм, әлбәттә, район хакимияте ярдәмендә тормышка ашырган. Үз клубының төп бурычын ул дөнья чемпионын үстерүдә түгел, бәлки мөмкин кадәр күбрәк баланы бу борынгы катлаулы уенга тартуда дип саный.

Әмма Минзәләне интеллектуаль спортта гына көчле дип әйтеп булмый. Шәһәрне һәр яктан елгалар уратып алган, монда йөзә белү бик кирәк. Һәм күпмедер күләмдә моны куркынычсызлык кагыйдәләре дә таләп итә, бигрәк тә сүз балалар турында барганда. Шуңа күрә район хакимияте шундый карар кабул итә: Минзәләдә яшәүче һәр бала йөзә белергә тиеш. Бүген дә районның икенче сыйныф укучылары Минзәләнең «Юбилейный» спорт мәктәбе базасында йөзәргә өйрәнә. Алар өчен ике заманча бассейн эшли.

Әлбәттә, «Юбилейный»да икенче сыйныф укучыларын гына өйрәтмиләр. Биредә дүрт спорт юнәлеше (өстәп, спорт аэробикасы, волейбол һәм көрәш) буенча 400 дән артык укучы шөгыльләнә. Мәктәпнең аеруча горурланырлык спортчылары бар, мәсәлән, йөзү буенча спорт мастеры

Ярослав Соколовский, ул IX Россия–Кытай яшьләр җәйге уеннары җиңүчесе һәм призеры, Татарстан җыелма командасына керә.

«Юбилейный» Минзәләдә бердәнбер спорт мәктәбе түгел. Шулай ук «Олимп» һәм «Юность» мәктәпләре бар. Анда хоккей, фигуралы шуу, бадминтон, чаңгы, бокс, теннис, футбол, гер күтәрү белән шөгыльләнәләр… Мәсәлән, 2016 елда «Олимп»та искиткеч заманча чаңгы базасы төзелгән, аның трассаларында яшь спортчылар кыш көне генә түгел, җәй көне дә, чаңгы роллерлары киеп, күнегүләр ясый ала. Базаны район акчасына җиһазландырганнар, шулай ук мәктәпкә ТР Чаңгы узышлары федерациясе һәм аның җитәкчесе Илшат Фәрдиев бик ярдәм итә.

– 20 пар һөнәри чаңгы комплекты бар, барлык тәрбияләнүчеләр дә спорт костюмнары белән тәэмин ителгән, – дип сөйли мәктәп директоры Чулпан Харисова. – Әлбәттә, мондый шартлар булганда балалар бик теләп шөгыльләнә. Нәтиҗәләр дә бар: берничә укучы спорт мастерына кандидат булды.

Шушы укучыларның берсе - 17 яшьлек Илмир Шәкүров безгә башкаланың атаклы Бауман исемендәге МДТУна керергә хыяллануы турында сөйләде. Спорттагы уңышлары ярдәм итәр дип уйлый, чөнки алар өстәмә баллар бирә. Егет чаңгыны ташларга җыенмый, югары уку йорты җыелма командасы өчен чыгыш ясарга өметләнә, ә яхшы спортчылар хәтта башкаланың иң яхшы университетларына да һәрвакыт кирәк.

Ә «Олимп» мәктәбенең төп горурлыгы – легендар тренер, Минзәләнең мактаулы гражданы Владиленин Мильчаков. Өлкән булуына да карамастан (90 яшь!), Владиленин Николаевич Минзәлә чаңгычыларының берничә буынын тәрбияләгән, бүген дә балалар белән шөгыльләнүен дәвам итә.

ДӘВЕР, ЯЗМЫШЛАР, ШӘҺӘР

Минзәләдә Ат мәйданы каян килгән? Моннан 450 ел чамасы элек Минзәлә елгасы ярында нигә ныгытма төзегәннәр? Шәһәрдә поляк дворяннары варислары ничек пәйда булган? Генералиссимус Суворовның әтисе биредә нишләгән? Минзәлә кешесе кан күчереп салуда нинди революция ясаган? Һәм, ниһаять, Минзәлә атамасы үзе нәрсәне аңлата соң? Безне кызыксындырган әлеге сорауларга җавапны төбәк тарихын өйрәнү музеенда табарга була.

Менә ул, XX гасыр башы Минзәләсе. Зур Уфа урамындагы сәүдәгәрләр йортлары янында халык сәйран кыла, товар төялгән арбалар, начар майланган тәгәрмәчләрен шыгырдатып, таш түшәлгән юлдан чайкала-чайкала бара. Зур Уфа – шәһәрнең таш түшәлгән бердәнбер урамы, әмма башка сыйфатлары буенча Минзәлә кайбер губерна калаларыннан бер дә калышмый. Алты чиркәү, мәчет, челтәрле таш койма белән әйләндереп алынган Илья пророк (Элҗен пәйгамбәр) хатын-кызлар монастыре. Византия стилендәге биш гөмбәзле Троица чиркәве исә шәһәр бинналары арасында чын энҗе булып балкый. Әмма биредәге чын тормыш, әлбәттә инде, Зур ярминкә мәйданында гөрли, анда ни генә сатылмый!

– Минзәләдә биш мәйдан була, – дип, революциягә кадәрге шәһәр макеты белән таныштыруын дәвам итә музей экскурсоводы. – Зур ярминкә, Ат, Урман, Печән һәм Балык мәйданнары. Минзәлә үзенең ярминкәләре белән дан казана: товарларны бөтен Россиядән һәм чит илләрдән китерәләр. Мәйданда нинди товар сатыла, ул шуның исеме белән атала да. Мәсәлән, Ат мәйда-

Фотолар: Әскәр Сабиров, Александр Ефремов

нына малкайлар Башкорт ягыннан көтүләре белән куып китерелә.

Минзәләдә ярминкәләр елына өч тапкыр үткәрелә, аларга кызыл мал бөтен Россиядән һәм чит илләрдән китерелә, һәм товар әйләнеше буенча алар инде XIX гасыр азагында ук бары тик Мәкәрҗә, Эрбет һәм Архангельск ярминкәләреннән генә калыша. Җирле эшкуарлар һәм һөнәрченең дә халыкка тәкъдим итәрлек товарлары бихисап җыела. Революциягә кадәр Минзәләдә дүрт пар тегермәне, дүрт такта яру заводы, өч поташ заводы, икешәр күн һәм май сыгу заводы, берәр шырпы һәм аракы куу заводы, бер дистә ярма яргыч эшли, 221 амбар ашлык белән тулы була. Бирёдәге су һәм җил тегермәннәренең саны исә дүрт йөздән арта.

УКЧЫЛАР ҺӘМ ПОЛЯК ШЛЯХТАСЫ БЕРЛЕГЕ

Агач дивар, агач каравыл манаралары һәм укчылар өчен берничә йорт – XVI гасыр азагында Минзәлә әнә шул тыйнак кына ныгытмадан башланып китә. Музейдагы реконструкциягә карап фикер йөртсәң, бер дә дошман һөҗүмен туктатырлык нык форт җәүһәренә охшамаган кебек. Әмма бирегә хезмәт итәргә җибәрелгән укчылар йөзлеген әйтерсең лә табигать үзе саклый. Биек ярда калкып чыккан ныгытманың бер ягыннан – Кичканка, икенче ягыннан Скородумка елгалары ага. Ә төп куркыныч янаган якта мул Минзәлә елгасы җәйрәп ята. Гарнизон үзе дә, вакыт күрсәткәнчә, таштан да ныграк булып чыга.

Ныгытма сакчылары 1676 елда каты сугышта катнаша – Минзәләгә, үзара берләшеп, башкортлар һәм кыргыз-кайсаклар һөҗүм итә. Бу вакытта инде гарнизон поляк шляхтичлары белән тулыландырылган була. Казаклар белән шляхтичлар арысландай сугыша һәм ныгытманы саклап кала...

Шунысы кызык: патшага тугры хезмәт иткән шул шляхтичларның варислары Минзәләдә бүген дә яши әле. Шимоновскийлар, Домбровскийлар, Сушинскийлар... өчен Минзәлә төбәге – кече ватан.

Тарих – бик көйсез кунак. Кеше язмышлары һәм вакыйгалар кайвакыт бөтенләй көтелмәгән урыннарда кисешә. Атаклы генералиссимусның әтисе Василий Иванович Суворовның җирле музейдагы портреты моңа дәлил булып тора. Киләчәктә генерал-аншеф булып танылачак Василий Иванович 1730 нчы елларда Минзәлә ныгытмасында нагайбәк казаклары бригадиры булган икән. Әлеге факт хәзергә кадәр төрле имеш-мимешләр тудыра – янәсе, кем белә, бәлки Александр Васильевич үзе дә бу якларда дөньяга килгәндер, ә?! Әлбәттә инде, моңа бернинди дәлил дә юк, әмма Александр Васильевич Суворовның туган елы һәм туган урынының бүгенгә көнгә кадәр билгесез булуы – хакыйкать.

ДӨЯ ЮЛЫ ҮЛЧӘМЕ

Минзәләнең беренче гербы: йөгереп баручы сусар һәм аста, зәңгәр фонда, алтын шоңкар. Герб Екатерина Минзәләгә өяз шәһәре статусын биргәннән соң расланa. Бу 1781 елда, ныгытма Пугачев гаскәре чолганышына бирешмәгән яудан соң берничә ел үткәч була. Фетнәчеләр бистәнең шәһәргә әйләнүенә булышкан, дип тә әйтергә мөмкин: урыннардагы хакимиятне көчәйтү өчен, патшабикә сигез өяздән торган Уфа наместниклыгын булдыра. Минзәлә төбәге шул өязләрдән берсенә, бистә үзе исә өяз үзәгенә әйләнә. Беренче рәсми гербтагы сусар – Уфа наместниклыгына керү дәлиле.

Хәер, җирле музейдагы археологик казу эшләре материалларыннан күренгәнчә, Минзәләнең текә ярында тормыш әлеге вакыйгалардан күптән элек үк кайнап тора. XII гасырдан башлап, бу җирләрдән Бөек ефәк юлы үтә, шәрык товарлары төялгән кәрваннар Көнбатышка агыла. Елганың биек ярында алар ялга туктала торган була – елганың исеме дә шуннан килеп чыккан, диләр. «Мәнзил» гарәпчәдән «туктап ял итү урыны» дип тәрҗемә ителә икән. Тагын бер мәгънәсе – кәрвандагы дөяләрнең туктамый үткән бер көчеше озынлыгы, әлеге ара якынча егерме чакрымга тәңгәл.

Шул рәвешле, сигез гасырдан соң биредә шаулаган Минзәлә ярминкәләре – Бөек ефәк юлы чорыннан калган сәүдә традицияләренең дәвамы икән ул. Нәкъ менә шуңа күрәдер дә XIX гасыр азагы – XX гасыр башында биредә кыйммәтле җәнлек мехы, йон, күн һәм ашлык белән генә түгел, бәлки затлы кытай савыт-сабасы, һинд кашемиры һәм тәмләткечләре белән дә гөрләтеп сәүдә итәләр.

ТАРИХТА ЭЗ КАЛДЫРГАН ШӘХЕСЛӘР

Бөтенләй башка эпоха. Нюрнберг процессыннан, Освенцим үлем лагереннан фотосурәтләр, атаклы «Рейхстаг өстендә Җиңү байрагы» фотосы… Минзәлә музеенда, «Правда» фотохәбәрчесе Виктор Теминның фотосурәтләре белән бергә, аның кайбер эшләренең бик кадерле негативлары да саклану бер дә очраклы түгел: Темин биредә мәктәптә укыган, биредә беренче фотоларын ясаган. Мондагы Казан Изге Ана иконасы чиркәвендә (бу – Чулман аръягында совет чорында да ябылмый эшләгән бердәнбер гыйбадәтханә) аның әтисе – Артемий атакай хезмәт иткән. Виктор Темин – 1945 елның сентябрендә «Миссури» линкорында японнарның капитуляциясен мәңгеләштергән бердәнбер совет фотохәбәрчесе. Бу Икенче бөтендөнья сугышының иң соңгы фотосурәте санала…

Пасмуров, Стахеевлар, Горбушин, Сәетбатталов, Корбангалин кебек дворян һәм сәүдәгәрләр Минзәләгә зиннәтле йортларын һәм гыйбадәтханәләр калдырган. Алар үз байлыгын туплау белән шөгыльләнгән чорда Минзәләдәге халык укытучысы гаиләсендә Владимир Шамов туган. Үзеннән соң зиннәтле сарайлар калдырмаса да, аның мирасы барлык җирле сәүдәгәрләрнең уртак байлыгыннан кыйммәтлерәктер, мөгаен. 1919 елда Шамов авыруларга кан салганда, илдә беренче тапкыр аның төркемен исәпкә алып эш итә, моның белән меңләгән кешенең гомерен саклап калырга булыша – моңа кадәр донор һәм пациентның каны туры килмәү еш кына фаҗига белән тәмамлана торган була. Соңрак Шамов илдә хәрби нейрохирургия мәктәбен булдыра һәм СССРда трансплантологиягә нигез салучылардан берсе булып таныла…

Язучылар Роман Солнцев һәм Вячеслав Шугаев, академик-физик Борис Никольский һәм рәссам Вадим Аксенов. Хатын-кызлардан беренче булып Тукай премиясе белән бүләкләнгән шагыйрә Гөлшат Зәйнашева. Совет чорында атаклы Мария театры дирижеры – Санкт-Петербург консерваториясе профессоры Виктор Федотов. Берлин һәм Прага операцияләрендә немецларны тар-мар иткән армия командиры, Советлар Союзы Герое генерал-полковник Василий Гордов…

Болар Минзәлә шәһәре һәм районында туып-үскән танылган шәхесләрнең кайберләре генә. Аларның иҗаты, ачышлары һәм сугыштагы батырлыклары безнең бәһасез мирасыбызны тәшкил итә. Мавыктыргыч, кайчак фантастик, кайчак исә фаҗигале язмышлары – мөгаен, төбәк тарихын өйрәнү музееның иң кадерле экспонатларыдыр.

МЕҢ ДӘ ӨЧ ЙӨЗ ЕЛЛЫК БӘХЕТ

Евгения Чеснокова

Үз гаиләсенең бик зур казанышы – 1300 еллык гомуми педагогик стажга – Минзәлә гимназиясе укытучысы Ленар Заһриев тагын чирек гасыр өстәгән. Яраткан җәмәгате Гөлнара белән гаилә коруларына да быел нәкъ 25 ел була икән.

Гөлнара белән Ленар Заһриевлар беренче сыйныфтан бирле таныш, Минзәлә районы Кадрәк авылы мәктәбендә бергә укыганнар. Алар бүген дә бер үк мәктәптә, тик инде укымыйлар, ә эшлиләр. Дөрес, Минзәлә гимназиясендә аларның кабинетлары төрле: Ленар Нур улы – физкультура, Гөлнара Рөстәм кызы исә татар теле һәм әдәбияты укыта. Гел бергә булу туйдырмыймы дигән сораудан Ленар көлә генә: «Без бит икебез ике катта эшлибез!» – ди.

Фото: Александр Ефремов

ЯРАТУ ҺӘМ КАЙГЫРТУ

Бүген Заһриевлар гаиләсе бергә җыелганда, иң кече варис – дүрт айлык Йосыф һичшиксез игътибар үзәгендә була. Ул – Ленар белән Гөлнараның беренче оныгы, олы кызлары Гүзәлнең улы. Әбисе белән бабасының сабыйны үлеп яратуы аңлашыла инде, әмма Гүзәлнең энеләре, унсигез яшьлек Ильяс белән унике яшьлек Фәһим дә бәләкәй энекәшләренә карап сокланып туя алмый.

Гаиләдә бер-береңә карата шундый күркәм мөнәсәбәт булсын өчен нишләргә кирәк икән? Бәләкәй Йосыфның әнисе Гүзәл моны төгәл белә:

– Әти-әнинең безне дә, бер-берсен дә ихлас яратуын без һәрвакыт тоя идек. Димәк, иң мөһиме ярату, мәхәббәт булып чыга.

– Һәм без барыбыз да бер-беребез турында кайгыртабыз, – ди елмаеп Ильяс.

АҢЛАУ ҺӘМ ЮЛ КУЮ

Бу мәсьәләдә тәҗрибәлерәк гаилә башлыгының исә үзара нык мөнәсәбәтләр серенең нидә булуына карата үз фикере бар:

– Озак еллар буе бергә тыныч-тату яшәү өчен, бер-береңне аңларга һәм кайчакта юл куя белергә дә кирәк, – дип саный Ленар Нур улы. – Кайвакытта исә дәшми калу да бик кирәк...

Гөлнара Рөстәм кызы исә өлкәнрәк туганнарның мисалы зур роль уйный, дип саный.

– Мин үскән гаиләдә дә, иремнекендә дә әти-әниләр озак еллар буе дус-тату яшәде, һәм күз алдындагы мондый үрнәк күп нәрсәгә өйрәтә ала, – ди ул. – Ә аларны әби-бабаларыбыз шулай тәрбияләгән. Матур гореф-гадәтләр менә шулай буыннан буынга күчеп бара да инде.

Заһриевларның дини гаилә булуын да искәртү зарур һәм, Ленар фикеренчә, уртак дини карашлар да берләштерә, якынайта.

Ә үз әти-әниләреннән Заһриевлар киләчәк тормыш өчен кирәкле әхлакый гына түгел, һөнәри нигезләр дә алган. Аларның әти-әниләре дә, әби-бабайлары да, хәтта ага-апалары да барысы да педагог булган. Династиянең 1300 елга якын гомуми мөгаллимлек стажы әнә шулай тупланган.

ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘРНЕ ДӘВАМ ИТҮ

Сүз уңаеннан, Гүзәл дә инде дипломлы педагог, татар һәм инглиз телләре укытучысы. Әлегә бәләкәй Йосыфны тәрбияләп өйдә утырса да, соңрак укытучы булып эшләргә ниятли. Баштарак мәктәпкә барырга теләмәгән, әмма педагогик практикадан соң мөгаллимлекнең үзенә ошавын аңлаган. Ни дисәң дә, геннар үзенекен итә шул!

Ильяс та әтисенең эшен дәвам итә, әмма бераз гына башкарак даирәдә. Эш шунда ки, Ленар Заһриев әле укытучы гына түгел, бәлки милли көрәш буенча спорт мастеры да, бүген дә көрәшчеләрне өйрәтә. Ике улы да көрәш белән шөгыльләнә, олысы быел Казандагы Идел буе физкультура, спорт һәм туризм университетына укырга кергән.

Быел Татарстанның «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» конкурсының зона этабында Гөлнара Заһриева «Хатын-кыз – ана» номинациясендә җиңү яулаган. Ә яраткан ире һәм уллары аңа җиңәргә булышкан – сәхнәгә барысы бергә чыкканнар һәм, матур итеп, иң кадерле кешеләренә багышланган шигырьләрен укыганнар.

Заһриевлар быел августта көмеш туйларын бәйрәм итәргә җыена.

«МИНЗӘЛӘ ЧЫНЛАП ТА ШАХМАТ ТЕРРИТОРИЯСЕНӘ ӘЙЛӘНСЕН!»

Евгения Чеснокова

– Карагыз, менә биредә шахмат буенча бөтен дөнья чемпионнарының портретлары эленгән, – дип күрсәтә безгә «Минзәлә – шахмат территориясе» клубы җитәкчесе Азат Шаһалиев һәркайсына шакмаклы такта куелган өстәлләр тулы бүлмә буйлап барганда. – Ә аларның астында – балалар портретлары. Болары инде безнең үзебезнең чемпионнар, районныкылар...

Юк, Азат Тимерхан улы үз клубында тәрбияләнүчеләрнең иң-иңнәре булса да һичшиксез шахмат Олимпына күтәрелер, дип өметләнми (гәрчә бу тормышка ашмастай хыял булмаса да). Әмма Минзәләнең яшь «гроссмейстерлары» өчен аларның фотосурәтләренең Алехин, Капабланка, Карпов, Карлсен портретлары янәшәсендә эленеп торуы да югары үрләргә омтылу өчен гаять зур стимул булуы бәхәссез.

МАКСАТ КУЙДЫМ, ШУҢА БАРАМ

Үзе әйтүенчә, Шаһалиев бала чагында һәм яшь вакытында ук «беренче разрядлы» шахматчы була. Банк сферасында хезмәт куйганда исә яраткан мавыгуыннан бераз аерылып торырга туры килә. Ә менә пенсиягә чыккач һәм Чаллыдан әнисе янына Минзәләгә күчеп кайткач, башында шундый фикер туа: ә нигә әле балалар белән шөгыльләнмәскә, аларны борынгы уен серләренә өйрәтмәскә?

Бу эшкә Азат Тимерхан улы бик теләп тотына. 2018 елда Минзәләнең яшь шахмат сөючеләре өчен үз мәйданчыкларын бул-

Фото: Александр Ефремов

дыра – башта «ВКонтакте» челтәрендә, виртуаль була ул. Аннары җирле мәктәпләрдә шахмат сыйныфлары ачтыруга ирешә. Балаларны уйнарга үзе өйрәтә, кайвакыт хәтта үзенең өендә дә дәресләр үткәрә.

– Күрәмсең, минем активлыгым район җитәкчелегенә ошады, нәтиҗәдә, безнең өчен Балалар иҗаты йортының икенче катындагы зур бүлмәне ремонтлап бирделәр, – дип көлә Шаһалиев.

Мондый активлыгының файдалы булуы гаҗәп тә түгел. Аның үз шәкертләре, җирле турнирлар, аларга керткән технологияләре турында илһамланып сөйләгәнен тыңлаганда, якын киләчәктә Минзәләнең шахмат башкаласына әйләнәчәгендә бер шик тә калмый.

Бүген шахмат клубы урнашкан заллар исә чыннан да искитәрлек. Берсе бик зур – биредә турнирлар да, шахмат дәресләре дә үткәрелә, чәршәмбе кич исә теләгән бөтен кеше уйнарга килә ала. Икенчесе бераз кечерәк, анда турнир лидерлары уйный (аларга биредә беркем дә комачауламый) яки билгеле бер яшьтәге төркем осталыгын чарлый. Ике залда берьюлы барлыгы 90 лап кеше уйный ала.

Әле тагын тренер бүлмәсе дә бар, уеннан буш арада барлык шахмат фигуралары да андагы стеллажларда саклана. Һәр җыелма аерым пакетта, һәркайсына үз тактасының саны язылган... Шаһалиев бөтен нәрсәнең дә үз урынында ятуын ярата: күрәмсең, банк сферасында эшләвe нәтиҗәседер – һәрнәрсә тәртиптә һәм исәптә булырга тиеш.

– Әле без күчереп йөртелә торган шахмат өстәлләре дә сатып алдык, аларны җәен Балалар иҗаты йорты каршына куярга ниятлибез – теләгән һәркем килсен дә уйнасын.

ШАХМАТ ӨЧЕН VAR

– Монда безнең кәгазьсез җитештерү, – дип, үз территориясе белән таныштыруны дәвам итә Азат Тимерхан улы. – Сезнең кайбер турнирларда кемнең кем белән уйнавын, кемнең ничәнче урында булуын күрсәткән исемлекләр элгәннәрен күргәнегез бардыр инде. Ә минем бөтен нәрсә бары тик компьютерда гына. Уенчылар, тренерлар һәм ата-аналар исә боларның барысын да безнең заллар каршындагы холлдагы экраннан карый ала. Бик уңайлы!

Бу экраннары белән ул бик горурлана. Уен бүлмәләрендә дә зур телепанельләр эленеп тора. Таблицалар һәм исемлекләрдән тыш, турнирлар вакытында экраннарга беренче ун тактадан видео да күрсәтелә. Моның өчен һәр уен кыры өстенә смартфон куелган. Ул турыдан-туры да күрсәтә, язып та бара. Әгәр бәхәс килеп чыга калса, судья язманы карый һәм кемнең хаклы булуын ачыклый ала (футболдагы кебек! Күптән түгел генә кертелгән VAR-технология - судья өчен видеокабатлауларны хәтерлисездер?) Матчлар вакытында тренерлар һәм ата-аналарны уен залларына кертмиләр бит, ә биредә алар, холлда утырган килеш, барысын да «туры эфирда» күзәтә ала.

ҮЗ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ

– Мин клубның тарихын да туплый барам, – дип хикәясен дәвам итә Азат Шаһалиев һәм безне тагын экспонатлар карарга чакыра. Биредә – клубка килгән дәрәҗәле кунакларның фотосурәтләре дә (мәсәлән, халыкара гроссмейстер Алисә Галләмованыкы), шәкертләрнең барлык грамота һәм кубоклары да... Клубның заллары район хисабына ремонтланган һәм җиһазландырылган булса да, Шаһалиев күп нәрсәгә үз акчасын кызганмый («Мин һәр диплом яисә фотография кысасына да акча сорый алмыйм бит инде»). Ул гомумән клуб территориясен үзенең икенче йорты кебек кадерләп саклый («Биредә безнең шундый матур, уңайлы, мин хәтта кунып та калыр идем!»).

Бүген клубта төрле яшьтәге 150 ләп бала шөгыльләнә. Азат Тимерхан улы элеккечә үк нигездә аларны үзе өйрәтә, әмма инде аеруча талантлы укучыларга бу гына җитми, Чаллыга өстәмә дәресләргә йөрергә туры килә. Әмма бит әле интернет та бар, анда да шахмат күнекмәләрен камилләштерү өчен ресурслар бихисап.

– Мин бит алар барысы да һичшиксез чемпион булсын дип кенә тырышмыйм, – дип, үз фәлсәфәсе белән уртаклаша тренер. – Иң мөһиме, мөмкин кадәр күбрәк кеше йөрсен. Минзәлә чынлап та шахмат территориясенә әйләнсен. Ә инде күп кеше йөри икән, алар арасында һичшиксез аеруча талантлылары да табылачак.



АГАФУРОВЛАР ЙОРТЫ ХӘЗИНӘСЕ

Дмитрий Сивков

Әгәр сезгә берәр вакыт Екатеринбургка барырга, аның урамнары буйлап йөрергә туры килсә, үзәк мәйданнан ерак түгел урнашкан бик матур бина – Сакко һәм Ванцетти урамындагы 24 нче йортка игътибар итми калмагыз. Чын архитектура җәүһәре ул. Аның уникальлеген Татарстан булышлыгы белән саклап кала алганнар.

Шәрык бизәкләре һәм Урал төбәгенә хас, агачтан уеп ясалган бизәкләр, төсле витражлар һәм грек классицизмы элементлары... Әлеге бинаны төзегән архитектор, гармониягә хилафлык китермичә, беренче карашка бер-берсенә бөтенләй туры килми торган стиль һәм юнәлешләрне берләштерә алган. Гаҗәп бит... Сырлы-бизәкле фасадка сокланып, эчкә узарга карар кылам. Чөнки бүген бу бина Татарстанның Уралдагы бер кисәкчеге булып тора. Бирелә ТРның Свердловск өлкәсендәге Даими вәкиллеге урнашкан.

МИЛЛИОНЕР СӘҮДӘГӘРЛӘР МИРАСЫ

– Сез татар сәүдәгәрләре Агафуровлар йортында. Династиянең нәсел башы чыгышы белән Лаеш өязеннән булган ярлы крестьян Хисаметдин Агафуровка барып тоташа. Екатеринбургта миллионер Агафуровлар күз өстендәге каш була, иҗтимагый һәм хәйрия эшчәнлегендә актив катнашалар, – дип сөйли Даими вәкиллек җитәкчесе Хәйдәр Гыйльфанов. – Зәйнетдин Агафуров, мәсәлән, берничә тапкыр шәһәр Думасының гласные итеп сайлана, Екатеринбургта гына түгел, губернадагы мәктәп-мәдрәсәләр дә ул биргән акча хисабына яши.

Автор фотолары



Агафуровлар йорты соңгы реконструкциягә кадәр.

Даими вәкиллекнең диварларын Урал төбәге һәм татар рәссамнарының картиналары бизи.

Бинаның эчке бизәлеше фасадтан калышмый. Диварларда – картиналар, витриналарда – тарихи экспонатлар, халык һөнәрчелеге эшләнмәләре. Бу хәзер шулай. Ә 2018 елда, Хәйдәр Мәсләхәтдин улы үз вазыйфасына керешкәндә, тарихи бина бик аяныч хәлдә була.

БУШЛАЙ АРЕНДА БӘРАБӘРЕНӘ РЕСТАВРАЦИЯ

– Ярдәм күрсәткәне өчен Татарстан Рәисенә бик рәхмәтлемен. 2018 елда Екатеринбургка халыкара күргәзмәгә килгәч, Рөстәм Нургали улы хәлләремне сорашты. Мин бинадан кала барысы да яхшы, дип җавап бирдем, – дип искә ала Хәйдәр Гыйльфанов.

Республика җитәкчесе шунда ук сораулар бирә башлый, мәсьәләнең асылына төшенә. Ә хәлләр болайрак тора: бинага 130 яшь чамасы, соңгы ремонт, анысы да косметик ремонт кына, унбиш ел элек булган, аренда өчен түләү елына 2 миллион сум тәшкил итә, ә ремонт сметасы ул вакытта 35 миллионга җыела.

– Рөстәм Нургали улы шунда ук өлкә губернаторы белән мондый вариант турында сөйләшеп карарга тәкъдим итте: Татарстан бинага капиталь ремонт ясый, ә өлкә аны 18 елга бушлай арендага бирә. Бу вариант барысын да канәгатьләндерде, – дип сөйли әңгәмәдәшебез.

Соңгы вариантта һәйкәлне реставрацияләүгә 128 миллион сум сарыф итәргә туры килә, әмма бинадан бушлай файдалану шартлары да үзгәрә – хәзер бу сан 49 ел тәшкил итә.

БИЗӘКЛӘР, ВИТРАЖЛАР ҺӘМ КАРАГАЙДАН ИШЕКЛӘР

Бина үзе, яше шактый булуга карамастан, чагыштырмача яхшы сакланган. Мәсәлән, фасадтагы такталар оригиналь булып чыга, аларны чистарталар һәм буйыйлар гына. Ә менә йортның тәрәзә рамнарын яңасына – чыршыдан ясалганына алыштырырга туры килә. Ә тәрәзәләр саны 60 ка якын! Ишекләр дә яңаларына алыштырыла, алары – карагай агачыннан. Түбәләрдәге матур күпертмә бизәкләр реставрацияләнә һәм үзләренең тарихи зәңгәрсу төсенә кайтарыла. Аларның шундый төстә булганы тышкы акбурны салдыргач беленә.

Төсле витражлар шактый мәшәкать тудыра, чөнки бүген Россиядә аларны эшләүчеләр юк диярлек икән. Осталарны Мәскәү тирәсендә табалар. Хәзер йорт бәлки XX гасыр башында булганнан да яхшырак кыяфәттәдер. Тырышлык бушка китмәгән.

Ахырда республиканың даими вәкиленә тагын бер сорау бирми булдыра алмадым:

– 1919 елда шәһәрне ташлап киткәндә, Агафуровлар үз хәзинәләренең бер өлешен кайдадыр монда яшергән, диләр. Соңрак өйдә ике пот алтын коелмасы табылган. Ремонт вакытында хәзинә табу турында хыялланмадыгызмы?

– Бер пот алтын хәзерге бәяләр белән күпме тора, йөз миллион тирәсеме? Әйе, мондый акчалар безгә комачауламас иде, кая куярга икәнен белер идек. Ә җитди итеп әйткәндә, ТР Даими вәкиллеге – Агафуровлар йорты өчен чын хәзинә. Вәкиллек булмаса, аны нинди язмыш көткәнен беркем дә әйтә алмый.

редакция кухнясы

ЕРЛАН ИСКАКОВТАН БИШБАРМАК

Татьяна Вафина

«Татарстан»ның редакция кухнясы бүген Казахстан Республикасының Казандагы Генераль консуллыгына күчте. Ә бу исә төшке ашка чып-чын казахча бишбармак булачак дигән сүз. Аны Казахстанның Казандагы Генераль консулы Ерлан Искаков пешерә.

БИК МАЙЛЫНЫ ЯРАТМЫЙМ

– Бишбармак – яраткан милли ризыгыбыз. Ул казахлар тормышындагы барлык мөһим вакыйгаларга – никах, бәби туе, юбилей һәм, гомумән, гадәти кичке ашка дип әзерләнә, – дип тәкъдим итә үзе әзерләячәк ризыкны Ерлан Узан улы. – Пешерүе катлаулы түгел, ләкин озак. Авызда эреп торырлык йомшак булсын өчен, ит 4–5 сәгать пешәргә тиеш. Ризыкка май төбәккә яисә кешенең теләгенә карап өстәлә – ул ит белән бергә эчәкләргә тутырыла. Мин – Алма-Атада туып-үстем, безнең якта казыга 10–15% май өстәлә. Төньякка таба климат кырысрак, андагы халык, туңмас өчен, майлыны күбрәк ашарга тырыша. Мин бик майлыны яратмыйм.

АСТАУ ҺӘМ ТУЗДЫК

Консуллыктагы аш өстәлен агачка бизәк уеп ясалган савыт-саба бизи – табак һәм зур кайчыга охшаган, ни өчен кулланылганы безгә аңлашылмаган кыскыч.

– Бу савыт астау дип атала, – ди Ерлан Узан улы. – Ә бу «кайчы» белән бишбармакның итен һәм камырын алалар. Осталарыбыз мондый матур нәрсәләрне каеннан яисә талдан ясый.

– Ит пешкән арада, мин сезне туздык ясарга өйрәтәм, – дип дәвам итә сүзен бүгенге ашчыбыз. – Бу махсус тозлык, аны соус дип тә атарга мөмкин. Туздыкны әзер ризык өстенә сибәләр. Суганны боҗралап турап, тоз-борыч өстибез дә кайнап торган шулпада пешереп алабыз. Менә шул. Уңган хуҗабикә кичке аш вакытында, кайнар булып торсын өчен, бишбармакка берничә мәртәбә туздык сибә. Моны мин, казахларның, бер табышы дип атар идем.

Гадәттә бишбармак елкы итеннән әзерләнә. Елкы ите бездә деликатес санала, чөнки ул – чиста ит, аллергия китереп чыгармый, майлы

БЕЗГӘ КИРӘК БУЛАЧАК:

(5 6 кешелек):
- Ат ите – 1 кг;
- Бәрәңге – 4 данә;
- Җәймә (бишбармак камыры) – 1 кап;
- Суган – 1–2 баш;
- Тоз, борыч – тәменчә.

Фото: Александр Ефремов

– Гомумән, консул буларак кабатлап искә алам: һәр бишбармакның үз протоколы бар. Кайдадыр аны классик вариантта әзерләргә кирәк, кайдадыр төрләндерергә рөхсәт ителә.

түгел. Елкы итен Үзәк Азиядә, Пакистанда, Таҗикстанда, Якутиядә, Алтайда, Азәрбайҗанда яраталар. Әлеге традицион ризык җиңел эшкәртелә, шул ук вакытта бик туклыклы азык санала.

ИТ БҮЛГӘНДӘ ДӘ ПРОТОКОЛ САКЛАНА

Бүген казахлар, чәнечке белән алырга уңайлырак булсын өчен, итне кечкенәрәк кисәкләргә бүлгәлиләр. Кайвакыт, кунаклар күп булганда, тупасрак ысул куллану да рөхсәт ителә – итне зур-зур кисәкләр белән чыгаралар. Ягъни аска камыр салына, ә аның өстенә зур ит кисәкләре куела. Гадәттә табындагы иң яшь ир-егет, бу итне кискәләп, һәркемнең күз алдында кунакларга тарата. Аңа шундый мактаулы вазыйфа йөкләнә.

– Бүген иң яше мин булырмын, – дип елмая Ерлан әфәнде.

Асылда исә, бу ризыкны юкка гына бишбармак дип атамаганнар. Аны чәнечке белән түгел, кул белән тотып ашаганнар, биш бармакны да эшкә җигеп, ит кисәкләрен камыр белән тотып алганнар. Бу бик борынгы ризык, ул вакытта, әлбәттә, бернинди чәнечке-кашык булмаган. Бишбармак сыер итеннән дә, сарык итеннән дә әзерләнә ала, кайвакыт дөя итеннән дә пешерәләр. Яисә дүрт төрле итне бергә салып…

Кайвакыт бишбармакка шужык, карта кебек эч-башларын өстиләр – кем ничек ярата. Алар үзгә бер тәм бирә. Яисә тәкә башы салып пешерәләр.

Һәр вакыйганың үз протоколы, тәртибе бар. Бу – тулы бер церемониал. Төбәгенә карап, кайдадыр – кишер, кайдадыр – бәрәңге, кайдадыр помидор өстиләр…

Казахстанның көнбатышында әзерләнә торган иң оригиналь һәм заманча бишбармак фишбармак дип атала, аны балык белән пешерәләр. Күбесенчә, мәрсин-чөгә ише балыклардан әзерлиләр, чөнки алар майлы, тәмле. Бу бәйрәмчәрәк милли яки гаилә ризыгы. Төгәлрәге корпоратив бәйрәмнәр ризыгы.

Гомумән, консул буларак кабатлап искә алам: һәр бишбармакның үз протоколы бар. Кайдадыр аны классик вариантта әзерләргә кирәк, кайдадыр төрләндерергә рөхсәт ителә. Казахлар моны белә һәм аңлый.

Әгәр, әйтик, кодалар кунакка килсә, махсус тәртип саклана: аларны атның арт саны яки калак сөяге тирәсендәге ит – җамбас белән сыйлыйлар. Әгәр итне дөрес бирмисез икән, дипломатик гауга килеп чыгарга мөмкин! Шуңа күрә кунакчыллык белән бәйле законнарыбызда һәрнәрсә бик катгый билгеләп куелган, һәрнәрсә исәпкә алына: кызга итнең ниндиен бирергә, кияүгә – ниндиен… Иң мөһиме – гореф-гадәтләрне бозмаска, югыйсә ике арада

аңлашылмаучанлык килеп чыгачак. Болар буыннан-буынга тапшырылып килә бит.

КОНСУЛНЫҢ ЯШЕРЕН КОРАЛЫ

– Сез бишбармак тарихын бик яхшы беләсез, аны рецепт буенча да, протокол кушканча да пешерәсезме? Аш-су остасы булып еш эшләргә туры киләме?

– Мин коллективта шундый бер традиция керттем: әгәр кемнеңдер туган көне яки ниндидер истәлекле вакыйгасы булган икән, ул безне берәр үзенчәлекле ризык белән шаккатырырга тиеш. Йә үзе пешерә, йә пешерттерә.

Ә үземә килгәндә... Хәләл җефетем бар, ул бөтен нәрсәне пешерә белә. Ул – минем яшерен коралым. Һәрвакыт шушы коралымны кулланам һәм хатыным әзерләгән сый белән барысын да сыйлыйм. Ул күп нәрсәгә әниемнән өйрәнде – әнием бик тәмле пешерә иде.

ЛАГМАН БУЕНЧА ОСТАЛЫК ДӘРЕСЛӘРЕ

Әле без Казандагы бер ресторанны казахча лагманны дөрес итеп пешерергә өйрәттек. Классик лагманны! Бервакыт мин рестораннарда казахча лагман эзләп йөрдем. Казанлылар миңа үпкәләмәсен, рестораннарда чын лагман юк! Чөнки лагманда ике төп нәрсә бар. Беренчедән, өй токмачы, аның камыры бик зур итеп җәелә, йомшак була. Гади токмач кебек, кистең дә эше бетте түгел, аның әнә шул җәю-сузу процессын узуы мәҗбүри. Икенче төп компонент – ит. Ул да бик йомшак булырга тиеш. Болары – стандарт таләпләр. Кемдер борыч, сельдерей, суган өсти. Монысы инде вариацияләр. Менә без бер ресторанны бу һөнәргә өйрәттек, алар безгә рәхмәтле. Башка халыкларның милли ризык әзерләү культурасын теләп өйрәнүләре бик шәп күренеш! Өйрәтәбез, осталык дәресләре үткәрәбез, нәтиҗәдә Казан кухнясы байый.

ДӨРЕС БАВЫРСАК

Сүз уңаеннан, татар бавырсакларына да дәгъвам зур. Сез бит бавырсактан чәкчәк ясагансыз! Бу бөтенләй башка ризык.

Ә бавырсак – изгерәк, камырлырак ризык. Һәм ул кунакларга аерым савытта бирелә. Ә сездә ул баллатылган, әле җитмәсә шикәр оны да сибелгән һәм чәй янына чәкчәк итеп чыгарыла. Шуңа күрә мин һәрвакыт ризасызлыгымны белдерәм. Ләкин мин каршылык тарафдары түгел, ә күбрәк сездә болай, ә бездә менә болайрак дип санау яклы.

БЕЗНЕКЕ КАЙДА ДА, СЕЗНЕКЕ КАЙДА?

Барыгызның да «Әниемә» җырын ишеткәне бардыр. Ә аның тарихы турында беләсезме? Халык артисты Флера Сөләйманова Казахстанда эшләгәндә, «Ана туралы жыр» – «Әни турында җыр» дип аталган казах җырын җырлый. Һәм аны татар теленә тәрҗемә итә. Сездә ул «Әниемә» дип атала. Җыр халыкка тарала. Бүген инде ул җырны өч-дүрт буын җырлый... Аны ничектер ишеттем дә җыр таныш кебек тоелды. «Бу җырны каян алдыгыз?» – дип сорадым. «Безнең җыр, халык җыры», – дип җавап бирделәр.

Шул вакытта мин артистларыбызны чакырдым һәм алардан репертуарга Шамша Калдаяков җырларын кертүләрен һәм: «Бу Казахстанның халык артисты Шамши Калдаяков җыры», – дип игълан итүләрен сорадым.

Концертта янәшәмдә республика җитәкчелеге утыра... Җырны казах телендә җырлап җибәрделәр. Һәркем: «Бу бит безнең җыр!» – диешә. Мин шунда аларга барысын да аңлатып бирдем!

Мин моны сөйлим икән, бу көнләшүемне белдерми. Мин бары тик телләребезнең никадәр охшаш булуын һәм мәдәниятләребезнең үзара кушылып китүен генә җиткерергә телим, хәтта кайчак безнеке кайда, сезнеке кайда икәнлеген аера да алмыйбыз. Шуңа күрә мин бу нәрсәләрне пропагандалау та-

– Бүген казахлар, чәнечке белән алырга уңайлырак булсын өчен, итне кечкенәрәк кисәкләргә бүлгәлиләр.

– Бу камырның бер үзенчәлеге бар. Беренче көнне, яңа пешкән ризыкны ашаганда, аның тәме бер төрле. Икенче көнне исә – башка тәмдә.

рафдары, без тарихи яктан гына түгел, тел, музыка буенча да уртак тамырдан икәнебезне белергә тиеш.

РУСЛАРНЫҢ ЩИ АШЫ КЕБЕК, ИКЕНЧЕ КӨННЕ ТАГЫН ДА ТӘМЛӘНӘ

Бишбармакның ите алынды, кискәләнде.

– Хәзер камырын салып җибәрәбез, – дип әмер бирә Ерлан әфәнде. – Ул бездә җәймә дип атала.

Тигез итеп киселгән турыпочмаклы юка камыр телемнәре кайнап торган шулпага юл тота.

Бүгенге ашчыбыз камыр басып мәшәкатьләнмәде:

– Мондый әзер продуктлар бездә инде күптәннән бар, – ди ул. – Хуҗабикәләрнең эшен җиңеләйтә. Дөрес җәймә ертылмый, артык пешеп таралмый.

Сүз уңаеннан, бу камырның бер үзенчәлеге бар. Беренче көнне, яңа пешкән ризыкны ашаганда, аның тәме бер төрле. Икенче көнне исә – башка тәмдә.

Ул русларның щи ашы кебек, көннән-көн тәмләнә генә бара.

ЯРАТКАН РИЗЫК

– Яраткан милли ризыгыгыз нинди?

– Һай, күп андыйлар! Әлбәттә, бу бишбармак. Аннары, әлбәттә, куырдак.

– Кавардак дисезме?

– Куырдак. Хәтта рус телендәге «кавардак» сүзе безнең «куырдак»тан килеп чыккан дигән риваять бар. Чөнки куырдак – сарык эч-башыннан пешерелә торган катнаш ризык. Йөрәк, бөер, үпкәләр турында бара сүз. Бары тик кайсысының күпме вакытта пешеп чыкканын гына белергә кирәк – берсе биш минутта әзер була, икенчесе – ун... Гадәттә бу ризыкны сарык суйганда пешерәләр. Төп ризык әзерләнгән арада, кунаклар күңелсезләнеп утырмасын өчен, куырдак инде табынга да чыгарыла.

Казахстанда популяр булган ризыкларны Татарстан культурасына да кертергә тырышабыз. Менә бүген редакциягезне бишбармак пешерергә өйрәтәбез. Аннары куырдакка да чират җитәр...

Милли ризыгыбыз булмаса да, мин манты да яратам. Бездә аны мАнты дип атыйлар, басым беренче иҗеккә төшә.

ӘНИНЕҢ БИШБАРМАГЫННАН ДА ТӘМЛЕРӘК НӘРСӘ ЮК

– Казахстанда иң яхшы ашчылар ир-атлармы, хатын-кызлармы?

– Гадәттә бишбармакның итен ир-ат пешерә, ә камырын хатын-кыз ясый, – дип җавап бирә Ерлан әфәнде. – Ләкин төрле хәл була. Мин үзем дә кайвакыт камырын җәя алам. Хәтта хатын да: «Син пешерә беләсең икән бит!!!» – дип гаҗәпләнә.

Ә гомумән алганда, Казахстанда бик матур гыйбарә бар: «Әнинең бишбармагыннан да тәмлерәк нәрсә юк!»

«ИРТӘГӘ» СҮЗЕН КЕМ ЯРАТА?

– Татарстан дипломатик вазыйфалар башкарган урыннарыгыз исемлегендә беренче түгел, ахры?

– Әйе, бу минем дүртенче эш урыным. Беренчесе Нью-Йоркта иде, мин анда дүрт ел эшләдем. Аннары – Венгриядә икътисад буенча киңәшче, соңрак Германиядә илченең икътисад буенча урынбасары булдым. Менә дүртенче командировкамда Татарстанга юлладылар.

– Кайда эшләү уңайлырак иде?

– Барысы да чагыштырмача. Нью-Йорк күбрәк яшьләр өчен, минемчә. Мин анда яшь вакытта эшләктем, бу шәһәр минем өчен шаккаткыч иде! Мәскәү кебек. Нью-Йорк never sleep, диләр, ягъни Нью-Йорк беркайчан да йокламый. Анда син эшлисең дә, ял да итәсең, барысына да өлгерәсең. Венгриядә тынычрак, салмаграк эш ритмы. Беркем беркая ашыкмый – венгрларның менталитеты шундый. Анда барысы да бик планлы рәвештә

бара. Венгрларның яраткан сүзе – «holnap» – «иртәгә». «Иртәгә, иртәгә...» – дияргә ярата-лар анда.

– Ә бездә – кичә...

– Бездә «кичә» сүзе, – дип ризалаша консул. Һәм дәвам итә: – Германия, мөгаен, миңа яшем буенча кызыклырактыр. Яшемә, салмаклыгыма бәйле рәвештә, миңа күбрәк Германия ошый иде. Немецлар үзләре дә шундый тыныч. Анда да шау-шулы төнге тормыш бар, кешеләр кәеф-сафа кора, ләкин миңа болар инде кызык түгел иде, күбрәк гаиләм, хатыным, балаларым белән буласым килде. Германиягә сәфәрем алдыннан гына – кызым, ә ике елдан соң улым туды.

Шундый мәзәк хәл булды: иртәнге дүрттә улым дөньяга килде, бала табу йортының хатыным яткан катына күтәрелгәч, барлык табибларның да миңа сәерсенеп каравын тоям.

Берсе яныма килеп сорады: «Зинһар, әйтегез әле, ни өчен улыгызга исемен Arsenicum (Арсений) дип куштыгыз?» Немец телендә бу сүз «мышьяк», «агу» дигәнне аңлата.

«Юк, ул Арсен, – дип аңлатам. – Бу көнчыгыш исеме. «Батыр», «куркусыз», «көчле» яки «затлы сугышчы» дип тәрҗемә ителә».

Барысы да тынычланды кебек. Бу хәлне ник искә алдым? Дипломатиядә дә шундый үзенчәлекле ситуацияләр була, кайвакыт аңлатырга, сөйләп бирергә туры килә.

КОНСУЛ НИЧӘ ТЕЛ БЕЛӘ

– Үзегез эшләгән һәр илнең дә телен беләсезме? Ленин кебек?

– Галимнәр фаразынча, Владимир Ильич Ленин унбер тел: инглиз, немец, француз, швед, грек, итальян, поляк, чех, латин, борынгы славян телләрен һәм үзенең туган теле – рус телен белгән. Туган телем – казах теленнән һәм аңа охшаган татар теленнән кала, инглиз, немец һәм венгр телләрен беләм. Иң катлаулысы – венгр теле. Ә Германиядә хатыным немецчаны шулкадәр яхшы үзләштерде ки, хәзер балаларга өйрәтә. Һәм бер уңайдан инглизчә дә.

Кызым International School Халыкара мәктәбендә укый, ә улымны Бала-Ситига бирдем. Анда ул татар телен дә өйрәнә. Аңа бик ошый. Ул инде татарча бик йөгерек сөйләшә. Өйдә казахча сөйләшәбез.

Узган атнада балаларымны Ульяновскига алып бардым. Аларга Ленин мемориалын күрсәттем. Һәм Володя Ульяновның барлык бертуганнарына төрле телләрне әниләре өйрәткәнен нәкъ әнә шунда белдек.

МИҢА ТАТАРСТАН ОШЫЙ

– Миңа Татарстан ошый. Икътисадны, мәдәниятне, тарихны ничек алып баруыгыз ошый. Мин бит федераль округ күләмендә эшлим, һәм сезнең башка төбәкләрдән ничек аерылып торганыгызны ачык күрәм. Һәр җирдә тәртип.

– Гадәттә бишбармакның итен ир-ат пешерә, ә камырын хатын-кыз ясый.

Татарстаннан чыккан кешеләр дә мондагы схема буенча эшлиләр. Мәсәлән, Мордовия губернаторы Здунов та шимбә көннәрендә бөтен хөкүмәтне җыя. Анда да тәртип шул ук. Күпләр монда укырга килә. Сездәге оперативлыкка шаккатам: очрашуга барасың – ярты сәгатьтән соң фотографияләр әзер! Беркемгә бер нәрсәне дә искә төшереп торырга кирәкми – бу бик шәп. Шундый вак-төяк кенә бер мисал кебек, әмма аннан соң республикага карата мөнәсәбәтең шулкадәр җылына, монда канатланып эшлисе һәм иҗат итәсе килә башлый.

Ризык әзер! Дастархан – табынга рәхим итегез! – дип дәшә консул.

ҺӘЙКӘЛ ҺӘМ КҮРГӘЗМӘЛӘР АЛМАШЫ

Төшке аш вакытында әңгәмәбезне дәвам итәбез.

– Безнең халыкларда күп нәрсә охшаш, кайберләре бөтенләй бертөрле, – ди Ерлан Узан улы. – Казан Казансу буена салынган, ә ка-

1 Пешерәбез

2 Алабыз

3 Пешерәбез, алабыз

4 Кискәлибез

5 Өстибез

6 Ваклап турыйбыз

7 Шулпада томалап пешерәбез

8 Тоз-борыч салабыз

9 Катламлап тезәбез

занлыларга бүләгебез – бронза тайказан Назарбаев һәм Качалов урамнары чатына куелган. Анда алтын хәрефләр белән: «Guldenere ber, Qazan!» дип язылган, «Казан, чәчәк ат!» дип тәрҗемә ителә ул.

Май аенда янәшәдә Абай Кунанбаев бюстын урнаштырырга планлаштырабыз. Ул сездәге Габдулла Тукай кебек, халкыбызга бик кадерле зат. Абай Кунанбаев – җәмәгать эшлеклесе, шагыйрь, фикер иясе, казах язуына нигез салучы. Татарстан Хөкүмәте сын кую идеясен хуплады. Һәм бу безнең Казахстанда Тукай һәйкәле куелуга җавабыбыз булачак. Тукай ярты гомерен үткәргән Уральскида шагыйрьнең һәйкәле бар, Сәмәйдә дә һәйкәл пәйда булды. Муса Җәлил бюстын без узган ел Көкчәтау шәһәрендә куйдык... Без татарларга татарлар безгә куйганнан күбрәк һәйкәл куябыз, дип, шаяртып та алабыз кайчак.

Күптән түгел Казан Кремлендәге Ислам мәдәнияте музеенда КФУ белән берлектә «Ясәви мирасы һәм борынгы Төркестан» күргәзмәсен ачып җибәрдек. Ул төрки-мөселман дөньясының күренекле шагыйре, фикер иясе Хуҗа Әхмәт Ясәвинең 930 еллыгына һәм Төркестандагы Хуҗа Әхмәт Ясәви мавзолееН ЮНЕСКОның Бөтендөнья мәдәни мирасы исемлегенә кертүнең 20 еллыгына багышланды. Дин белгечләрегез сөйләгәннәр минем өчен көтелмәгән яңалык булды, баксаң, Кол Шәриф – Ясәвинең дәвамчысы икән.

Ясәви әсәрләре беренче тапкыр Казан университетында 1848 елда басыла. Һәм бу күргәзмәдә университетның дәлилләре – Татарстан халкы тарафыннан күчереп язылган әсәрләр тәкъдим ителә. Болар Хуҗа Ясәвинең мөселманнар арасында бик танылган, бик хөрмәтләнгән булуын раслый.

Ә бездә, Казахстанда, Азрет-Солтан музейтыюлыгы бар. Анда Ясәви мавзолее урнашкан. Бик күпләр шунда хаҗ кыла. Аны кече Мәккә дип атыйлар. Мәдәният министрлыгы аша без анда татарстанлыларны да чакырдык. Ул вакытта мөфти урынбасары шаяртып: «Мәккәдә – Мөхәммәд, ә Төркестанда – Хуҗа Әхмәт», – диде.

Төрки халыклар арасында бәйләнешэлементләр борын-борыннан булган һәм, күргәнегезчә, хәзер дә дәвам итә. Халыкларыбызның тарихи яктан гына түгел, рухи яктан да якынлыгы минем өчен бер ачыш булды.

Идеяләр әле күп. Казан федераль университеты базасының Филология институтында Абай үзәге ачарга телибез. Анда казах телен өйрәтәчәкбез, төрле мәдәни чаралар үткәрәчәкбез. Һәм шул рәвешле телләребез һәм тарихыбыз үсешенә ярдәм итәчәкбез.

КИЛӘЧӘГЕ БИК ӨМЕТЛЕ РЕСПУБЛИКА

Гомумән, Россия, Татарстан белән хезмәттәшлегебез бик тыгыз. Мин махсус санап карадым: 2022 елда президентыбыз Касым-Жомарт Кемел улы Токаев Россия Президен-

ты белән – сигез тапкыр, ә Рөстәм Нургали улы белән дүрт тапкыр очрашкан. Бер ел эчендә бит ул, күз алдына китерәсезме!

Ике ел элек ике арада товар әйләнеше 758 миллион АКШ доллары иде, былтыр 9 ай эчендә генә дә 639 миллионга җитте, үсеш 37 процент тәшкил итте! Димәк, без узган елны, чама белән әйткәндә, 900 миллион доллар чигендә тәмамладык. Карагыз, нинди үсеш! Быел без товар әйләнешен миллиардка җиткербез, дип уйлыйм.

Инвестицияләр ягыннан да бик актив үсеш бара – безнең Караганда өлкәсендә KamaTyres шин заводы ачылды. Әгәр сезнекеләр 12 миллион шин чыгарса, бездә 3,5 миллион эшләячәкләр. Беренче этапта җиңел автомобильләр өчен – 3 миллион, йөк транспорты өчен 500 мең шин җитештерү күздә тотыла. Икенче этап – резина эшләнмәләр. Өченчесе – авыл хуҗалыгы техникасы өчен шиннар.

Быел «Татнефть» бездә бутадиен җитештерү заводын төзүгә бәйле яңа проектка керешәчәк. Бер үк вакытта Атырау өлкәсендә геологик разведка эшләре алып барыла – нефть һәм газ ятмалары эзлиләр. Ягъни чимал чыгару һәм әзер продукция җитештерүне күздә тоткан тулы цикл турында сүз бара. Булдыралар! Мин һәрвакыт шаккатам: Казахстанга барып кына кайталар, инде аларның яңа проекты өлгереп тә җитә. Казахстанда аларга илһам килә. Шуңа күрә республикагызның шундый актив булуы миңа бик ошый. Бигрәк тә сезнең җитәкчеләрегез. Рөстәм Нургали улы, минемчә, бөтенләй өйдә утырмый, һәрвакыт ниндидер сәфәрдә, ниндидер очрашуларда. Ничек арымый икән ул, дип аптырыйм. Аның һәрнәрсәне контрольдә тоту осталыгына гаҗәпләнәм. Менә Татарстанга «Киләчәк уеннары»н уздыруны ышанып тапшырдылар – бу бит үзе дә күп нәрсә турында сөйли! Монда күпме халык, күпме делегация килде! Барысын да каршы алырга, урнаштырырга, сыйларга кирәк. Һәркем монда килүенә бик шат. Мин Казанда өченче ел һәм бу вакыт эчендә дәүләт башлыгы биредә ике тапкыр сәфәр кылды! Татарстан ничектер үзенә җәлеп итә торган урын!

Киләчәге бик өметле республика. Күпләр Татарстанны Россиянең терәге дип атый.

Шуңа күрә мин һәрвакыт һәм һәркемгә Татарстанны үрнәк итеп куям.

ОНЫТЫЛГАН ТРАДИЦИЯЛӘРНЕ ТОРГЫЗУ

Миңа Татарстанның төрле онытылган традицияләрне торгызуы һәм аларны халыкка таратуы ошый. Мәсәлән, төрки дәүләтләрнең музыкантларын җыя торган «Шәрык базары» фестивале. Бездә дә үз

– Казахстанда популяр булган ризыкларны Татарстан культурасына да кертергә тырышабыз. Бүген менә редакциягезне бишбармак пешерергә өйрәтәбез. Аннары куырдакка да чират җитәр...

– Уңган хуҗабикә кичке аш вакытында, кайнар булып торсын өчен, бишбармакка берничә мәртәбә туздык сибә. Моны казахларның бер табышы, дип әйтер идем.

вакытында шундый ук фестиваль – «Азия тавышы» фестивале бар иде. Аңа бөтен дөньядан киләләр иде. Шуннан соң ул озак вакыт үткәрелмәде. Һәм менә былтыр фестивальне кабат яңарттылар. Һәм ул шунда ук зур уңыш казанды!

Тиздән думбра дәресләрен үткәрә башлыйбыз. Күптән түгел Министрлар Кабинетында бу темага киңәшмә узды. Беренчедән, культурология форумы үткәрү планлаштырыла. Икенчедән, онытылган музыка уен коралларында уйнау дәресләре башлап җибәреләчәк. Ул исемлектә думбра да бар.

Сүз уңаеннан, миңа Әлмәттәге төрки музыка уен кораллары күргәзмәсе бик ошады. Анда төрки халыкларның барлык музыка уен кораллары тәкъдим ителгән. Мин шулкадәр сокланып карадым, хәтта аларның «Телеграм» каналына да язылдым. Анда, музыкантлар җыелалар да уйныйлар. Мондый нәрсәләрне республика дәрәҗәсендә үстерүегез бик шәп. Без сезнең белән горурланабыз.

Тарихны да яңартасыз, ясалма интеллект турында да онытмыйсыз – менә Рөстәм Нургали улы ясалма интеллектның татар телендә дә булырга тиешлеге турында мәсьәләне күтәреп чыкты. Бик шәп! Без моңа кадәр барып җитмәдек, ә сез инде шундый адым ясадыгыз.

ҖИТЕЗ КИЛЕН ӨЧЕН ЧӘЙ

Бишбармактан соң касәгә салынган куе шулпа эчеп куябыз. Әнә шул рәвешле шулпа аш ахырына чыгарылырга тиеш. Аннары – чәй.

– Без чәйне татарча эчәчәкбез, ләкин казах йоласы буенча, – дип кисәтә Ерлан әфәнде. – Без халыклар дуслыгы яклы.

– Бик кызык! Ничек була инде ул?

– Сөтле яки лимонлы татар чәен чынаякның яртысына гына салабыз. Шул рәвешле кунакка хөрмәт күрсәтәбез. Ярты чынаяк чәй тулысы кебек тиз суынмый. Чәй ясап тору өчен җаваплы килен никадәр тизрәк йөгереп йөрсә, ул шулкадәр кадерлерәк санала. Менә шундый чәй эчү мәрасиме. Яшьләр кайвакыт: «Әйдә, чемпион кызны хәлдән тайдырыйк әле!» – диешеп, касәләрен тиз-тиз бушатып торалар.

Безгә минем ярдәмчем Наилә чәй ясар. Ул татар кызы, әмма тумышы белән Казахстаннан. Шуңа күрә бу татарча-казахча чәй эчертүне бик яхшы башкарып чыгачак.

ТӨН УРТАСЫ ҖИТТЕ. КАЗАХЛАР КИЧКЕ АШКА ЯТТЫ

– Без идәндә, аяк бөкләп утырырбыз дип өметләнгән идек...

– Бүген алай аксакаллар гына утырадыр инде, – дип көлә консул. – Хәзерге казахлар өстәл артына утырып ашый. Әмма аяк бөкләп утырып ашый торган урыннар сакланып калган. Казахстанда гына түгел, Әстерханда туганнарымда да кичке ашны шулай ашадык. Махсус буш бүлмәгә көрпе дип аталган йомшак матраслар куеп чыгалар. Ә бүлмә уртасында – клеёнка җәелә. Бу дастархан дип атала. Уңайлы, мин сиңа әйтим: утырырга да, ятарга да була. Хәтта казахлар турында шундый мәзәк тә бар: «Төн уртасы җитте. Казахлар кичке ашны ашарга ятты». Ягъни ашыйсың да, шунда ук ятып, ял итеп аласың. Чәй эчкәч, арып китәсең. Ятып алгач, тагын ашарга әзер.

НИГЕЗНЕ САГЫНЫП...

Бишбармак белән сыйлангач, Ерлан Узан улын һәм аның ярдәмчесе Наиләгә шундый шәп, туклыклы төшке аш өчен ихлас рәхмәт белдерәбез.

– Безнең кухнябыз ничегрәк? – дип кызыксына консул сүз уңаеннан. – Консуллык хезмәткәрләре өчен аны күптән түгел махсус эшләделәр.

– Ә сез бу кухняның коммуналь фатир кухнясы урынында булуын беләсезме? Элек Казахстан консуллыгы бинасында коммуналь фатир булган һәм «Татарстан» журналисты Евгения Чеснокова монда үзенең бәхетле балачагын үткәргән!

– Менә сиңа мә! – дип гаҗәпләнә Ерлан әфәнде. – Димәк, мин кухня урынын дөрес чамалаганмын. Монда бит кухняның әсәре дә юк иде – хезмәткәрләр өчен компьютер өстәлләре куелган гап-гади бер бүлмә.

Дулкынландыргыч мизгелләр. Элекке коммуналь фатир буйлап ашыгыч һәм планнан тыш экскурсия оештырыла.

– Бу бүлмәдә безнең гаилә яшәде, – ди Женя, күз яшьләрен тыя алмыйча. – Ә монысында – әнинең дус кызының гаиләсе. Ә бу балконда әтием, агачтан уеп, төрле нәрсәләр ясый иде, ә менә монда мич тора иде. Шушы ишегалдында без йөгерешә, куыша идек – бу йортта балалар бик күп иде. Моннан мин 39 нчы мәктәпкә беренче сыйныфка укырга бардым. Берүзем юл аркылы чыгып, җәяү йөрдем, ул вакытта аннан берниндә машина да узмый иде. Миңа бүлмәмдә фотога төшәргә мөмкин булмасмы?

– Әйе, әлбәттә. Сез үз өегездә диванда утырган кебек булсын, диванга утырыгыз. Хәзер бу бүлмәдә без китапханә ясадык. Сез каршы түгелдер?

– Мин монда килүемә бик шатмын. Бу бүлмә төшемә еш керә. Без барыбыз да монда бик тату яшәдек! Мин аны бер тапкыр булса да күрергә хыялланып йөрдем.

Хыяллар «Татарстан» журналы белән тормышка аша. Казахстан консуллыгында. Карл Маркс һәм Миславский урамнары чатында.

– Ә бу балконда әтием, агачтан уеп, төрле әйберләр ясый иде.

Женя тәүге мәртәбә беренче сыйныфка укырга бара.

48 елдан соң...

Хыяллар «Татарстан» журналы белән тормышка аша.

Intercollegiate

«Татарстан» журналының махсус проекты

ЗАРЛАНМЫЙЧА ЭШЛӘГӘН БУЫН

Авыр вакытларга, кырыс заманнарга, кайчак түзеп булмаслык тормыш шартларына да карамастан, зарланмый-сукранмый, үз юлларында очраган бөтен кыенлыкны җиңеп алга атлаучы, дөньяны ямьлерәк, уңайлырак итәргә омтылучы кешеләр бар. Алар тайгада юллар сала, елгалар аша күперләр суза, яу кырында һәм тылда бөек Җиңүне якынайта, сугыштан соң балаларга белем бирә, яшьләрдә спортка кызыксыну уята.

«Татарстан» үз укучыларын шундый якташларыбыз, аларның могҗизага тиң эшчәнлекләре белән таныштыруны дәвам итә.



17 НЧЕ ТАРИХ
Владиленин Мильчаков ничек легендар тренерга әверелгән

18 НЧЕ ТАРИХ
Фәһим Фәсхиев ничек укытучы булган

Элекке тарихларны «Татарстан» журналында укыгыз: 2022 елның 10-12 нче саннары, 2023 елның 1-2, 6 нчы саннары, 2024 елның 1 нче саны.

17 НЧЕ ТАРИХ

ВЛАДИЛЕНИН МИЛЬЧАКОВ ХАКЫНДА КЫЙССА

Фото: Александр Ефремов

Евгения Чеснокова

Бервакыт Минзәләдәге «Олимп» спорт мәктәбенә Пенсия фондыннан шалтыраталар һәм документларында хата җибәрүләрен хәбәр итәләр. Янәсе, тренерлар исемлегендә яше 80 нән узган бабай бар, ә бу яшьтә кеше эшли алмый бит инде...

Спорт мәктәбендә исә: «Ничек кенә эшли әле!» – дип җавап кайтаралар.

Быел 13 мартта «Олимп» мәктәбенең чаңгы бүлеге тренеры, Минзәләнең мактаулы гражданы Владиленин Мильчаковка 90 яшь тулган. Ул әле һаман балаларны чаңгы шуу осталыгына өйрәтә, көн саен өеннән эшкә җәяү йә велосипедта килә. Минзәләдә Мильчаков – легендар шәхес.

ЛЕГЕНДА ШУЛАЙ БАШЛАНГАН

– Ә үзегезнең беренче тапкыр кайчан чаңгы шуганыгызны хәтерлисезме? – дип сорыйм Владиленин Николаевичтан.

– Әлбәттә, – дип көлә ул. – Без, балалар, кисмәкнең бөгелгән такталарын киез итеккә каеш белән бәйләп, тау шуарга бара идек.

Сугышка кадәрге ул елларда ишле (биш малай, бер кыз) гаиләнең чын чаңгы алырга мөмкинлеге булмый, әлбәттә. Җиденче сыйныфтан соң улының мәктәптә укуын дәвам иттерү өчен дә акчасы булмый этисенең (СССРда 1956 елга кадәр өлкән классларда уку түләүле була). Шуңа күрә балачактан рәсем ясау белән мавыккан үсмергә Казан сәнгать училищесы хакындагы хыялы белән хушлашырга һәм Минзәләдәге педагогика училищесына укырга кирәргә туры килә.

ҮЗ МӘКТӘБЕН БУЛДЫРГАН

Нәкъ менә шунда укыганда ул чаңгы ярышларында катнаша башлый. Бүгенге шәкертләрендәге кебек амуниция турында ул чакта хәтта хыялланып та булмый, иң гади, агач чаңгыда шуалар. Сугыштан соңгы елларда студентлар өчен махсус чаңгы юлы салучы да булмый – ат чанасы калдырган эздән йөриләр. Әмма Мильчаков спортка нәкъ менә шул вакытта гомерлеккә гашыйк була.

Гел бер чаңгы белән генә мавыкмый ул. Педучилищеда унҗиде ел буе физкультура укыта, шунлыктан аның шәкертләре ара-

сында чаңгычылардан тыш, гимнастлар да, җиңел атлетика белән шөгыльләнүчеләр дә шактый...

Спорт мәктәбенә Владиленин Николаевич 47 яшендә, 1981 елда килә. Аңа кадәр, педучилищедан тыш, аның хезмәт кенәгәсендә Пионерлар сараендагы туристлар түгәрәге дә, җирле ПТУ да, район спорт комитеты да бар – ул аның рәисе була.

Спорт мәктәбенә беренче тапкыр укучылар җыйганда, барлыгы 186 бала туплана.

– Билгеле, инвентарь җитәрлек түгел иде, – дип сөйли героебыз. – Район мәгариф бүлеге ярдәме белән 15 пар чаңгы сатып алдык. Чиратлап шөгыльләнә идек: бер төркем чаңгыда узышканда, икенчесе физик күнекмәләр ясый тора. Аннары алышынабыз. Үзебезнең бинабыз да юк иде – гади мәктәптә бер бүлмә бирделәр. Әмма, кыенлыкларга карамастан, балалар безнең спорт мәктәбендә бик теләп шөгыльләнде!

Җитәкче итеп куелгач, ул үзе дә укырга керә – ул чакта СССРда бик көчле профильле уку йорты саналган Алма-Ата физкультура институтында югары белем ала.

ГЕЛ ХӘРӘКӘТТӘ

Шунысын әйтү мөһимдер: яшь спортчылар данлыклы тренер янына хәзер дә бик теләп йөри. Теләсә кайсы вакытта өенә дә килеп китәләр.

– Без аны бик ихтирам итәбез, – ди «Олимп» мәктәбенең 17 яшьлек шәкерте Ильмир Шәкүров. – Аңарда тренер өчен бик кирәкле бер сыйфат – юмор хисе бар! Өстәвенә, ул анатомияне дә бик шәп белә, бу аңа күнекмәләрне бик дөрес оештырырга булыша.

Әмма эш анатомияне яхшы белүдә һәм юмор хисендә генә түгелдер кебек тоела. Владиленин Николаевичтан педагогик принциплары хакында сорашкач, иң беренче итеп ул һәрвакытта да укучыларына хөрмәт белән каравын әйтте.

– Мин беркемгә дә, беркайчан да аның башкалардан көчсезрәк булуын әйтмим. Аны әкренләп нығытырга, кирәкле дәрәҗәгә җиткерергә кирәк.

Остазның тагын бер принцибы бар: күнекмәләрне хезмәт тәрбиясенә бәйләп алып бару. Мәсәлән, мәктәп базасының яңа бинасы янәшәсендәге хәзерге чаңгы трассасын «Олимп»та укучылар үзләре ясаган.

– Мин әзерлекне ашыктырмыйм, – дип дәвам итә Мильчаков. – Балаларны һәрьяклап үстерергә тырышам – аларны гимнастика белән дә таныштырам, спорт уеннары да өйрәтәм. Болар барысы да яхшы база булдыру, техниканы камилләштерү мөмкинлеген бирә. Башта техника, аннары гына нәтиҗә.

Озак яшәү сере турында сорауга Владиленин Николаевичның җавабы юк.

– Дөресен әйткәндә, мин ничек туксан яшькә җитүемне сизми дә калдым, – дип, тыйнак кына елмая ул. – Гел балалар, гел яшьләр белән. Гел хәрәкәттә...

Быел легендар тренер җәйсыз егылып аягын имгәткән, шуңа чаңгы шуа алмаган (әмма барыбер озаклап җәяү йөрергә тырыша). Ә моңа кадәр һәр тренировка саен 10-15 чакрым ара үтү аның өчен норма булган.

Аның шәкертләре арасында чаңгы буенча сигез спорт мастеры, егерме мастерлыкка кандидат бар. Тренерның осталык мәктәбе аша үтүчеләрне исә санап та бетерерлек түгел. Шунысы кызык: шәкертләре турында сөйләгәндә, шактыеның хәзер йә физкультура укытуы, йә тренер булуы ачыклана... Һәм бу, мөгаен, Мильчаковның педагоглык талантына иң яхшы дәлилдер: әгәр укучылары да мөгаллимлек юлын сайлаган икән, димәк, укытучылары шәп булган!

18 НЧЕ ТАРИХ

ВЕТЕРАН ХЫЯЛЫ

Фото: Лилиана Вәлитова

Руфия Фазылова

Инде традициягә әйләнде дисәк тә була: апрель–май айларында Бөек Ватан сугышы ветераннары турында язабыз. Аннан соң да аларның хәл-әхвәлен белешеп торабыз. «Исән-сау, әйбәт кенә йөри», – дигән хәбәргә чын күңелдән сөенәбез. Мисал өчен, узган ел Харис ага Салихов, Зиннәт ага Хәйруллин турында язган идек. Шөкер, алар бүген дә Бөек Җиңү бәйрәмен исән-сау каршы ала.

Матур традициябезне дәвам итеп, быел да Бөек Ватан сугышында катнашкан каһарманнарны барлыйбыз. Алар белән очрашып сөйләшү үзе бер тарих...

«БУ КӨННЕ ДӘ КҮРДЕК»

Фәһим ага Фәсхиев Апас районының Багыш авылында гомер кичерә. Төпчек улы Рашат, килене Кәүсәрия тәрбиясендә яши. Туксан сигезенче яше белән бара. Әле бер-ике ел элек кенә күлгә балыкка барган булса, быел инде өйдә генә тора икән. Ни дисәң дә, сугышта алган яралар үзен сиздерә.

Хәрби хезмәткә ул унсигез яшендә чакырыла. 1943 елның ноябрь ае була. Яшь солдатлар алты ай эчендә Свердловск өлкәсендә хәрби күнекмәләр ала. Шуннан соң аларны Псков шәһәренә җибәрәләр. Фәһим Фәсхиев анда элемтәче булып хезмәт итә. Әле өйрәнүләр вакытында ук егетнең оста язуын күреп алалар. Шуның өчен дә соңрак Фәһимне полк штабының топографы итеп билгелиләр.

– Сугыш бит, төрлесен күрдек, – ди өлкән яшьтәге ветеран. – Фронтның иң кайнар нокталарында йөрергә, дошман тылында бу-

лырга да, бомба яңгыры астында калырга да туры килде. 1944 елның сентябрендә Псков шәһәре янында каты яраланып госпитальгә эләктем. Аннан савыгып чыккач, Эстония чигендә снайпер булып хезмәт иттем. Янә яраландым...

Фәһим Фәсхиев Җиңү көнен Рига шәһәрендәге госпитальләрнең берсендә каршылый. 9 нчы майның ул көнен әле дә елмаеп искә ала: җыр-бию, кичке салют. Яралы солдатлар госпиталь тәрәзәсеннән бу манзараны елап күзәтә. «Бу көнне дә күрдек бит», – диешәләр.

Өч ел эчендә Фәһим Фәсхиев шактый җәрәхәтләр ала: уң кул чугын пуля аркылыга тишеп чыга, аягында ядрә кыйпылчыклары, эчке әгъзаларына да зыян килә. Сугышка киткән өрлектәй егет туган ягына әнә шулай яралар белән кайта. Бәхеткә, туган авылының саф һавасы сугыш кичкән егетне дәвалый.

ҖАН ТАРТМАСА, КАН ТАРТА...

Сугыштан кайткач, егет кулына пычкыбалтасын ала. Кечкенәдән оста рәсем ясаган Фәһим йорт кирәк-яраклары ясый башлый. Яралары төзәлеп беткәч, колхоз эшенә дә чакыралар. Әнә шул чакта авылдашы Асия белән җылы мөнәсәбәтләр урнаша. Сугышка кадәр комбайнда бергә эшләп йөргән кыз белән егетнең арасы көннән-көн якыная.

– Асия апага фронттан хатлар язмадыгызмы соң? – дим Фәһим агага.

– Юк, без бит сугышка кадәр дус кына булдык, ул минем ярдәмчем иде. Мине армиягә алгач, ул комбайнга үзе утырган. Ут иде ул, картайгач та үткен булды. Минем холык тынычрак.

Фәһим белән Асия 1953 елда гына өйләнешә. Бер-бер артлы дүрт балалары туа. Шөкер, ул-кызлары барысы да тәртипле, гаиләләре бар. Ике кызлары Казанда, ә бер уллары Магнитогорск шәһәрендә яши икән. Балалары турында сүз чыккач, бабай әйтеп куйды:

– Әти дә Магнитогорск шәһәрендә җирләнгән, улым да шунда яши. Бу дөнья шундый кызык. Җан тартмаса, кан тарта шул...

Янәшәдә утырган Рашат абый бу урында ачыклык кертте:

– Безнең бабайның ике гаиләсе булган, эти беренче никахыннан туган беренче бала, – диде ул. – Бабай НКВДда эшләгән. Ыгы-зыгы башлангач, репрессиядән куркып, ул Магнитогорск шәһәренә чыгып киткән, дөресрәге, качкан. Әби исә өч баласы белән монда калган. Ул аларны ялгыз үстергән. Әтинең энесе Вәгыйзь абый 1942 елны үпкәсенә салкын тиеп үлгән. Бабай Магнитогорскида яңадан өйләнгән. Анда да балалары туган. Алар белән аралашабыз. Абый да шунда яшәгәч, кунакка да баргалыйбыз.

Фәһим абый көндәлегеннән:

– 1939 елда ат көтүе көттем. Яшьтәшем Шәрифҗан белән ат өстендә җилдереп рәхәтләндек. Эш сәгате иртәнге алтыдан кичке алтыга кадәр иде. Сугышка кадәр безнең колхоз чәчәк атты. Рабига апа избач иде, колхозның завхозы булып та эшләде. Кышын без дә малайлар белән ферма ызбасына төшәбез, бергә күңелле.

Авылда халык кирпеч тә сукты. Без, үсмер малайлар, шунда да эшләдек. Зират астында салам ягып, кирпечне яндырып саттык. Акчасын сеңлемә уку әсбаплары алырга дип әниемә бирдем.

1941 елның җәендә колхозда избач булып эшли башладым. Лозунглар, плакатлар яздым. Авыл советына урманнан чыбыклы телефон сузылган иде, шуның төзеклеген күзәтергә дә миңа куштылар. Иртә-кич барып, карап кайта идем.

1942 елда авылда ирләр калмады. Берәм-берәм минем яшьтәшләр дә китә башлады. Туу таныклыгына әни мине 1926 елгы дип яздырган, шуның өчен сугышка повестка 1943 елның көзендә генә килде. Әни белән сеңлем Буа районына кадәр озата барды, анда сбор булды. Әни елый, энем дә авырудан үлеп китте. Сеңлем белән икәү генә калалар. «Исән генә кайт», – ди. «Ярар», – дидем әнигә. Сүземдә тордым...

ИҖАДИ КЕШЕ

Авыл җирендә яшәп тә, әллә ничә талантка ия кешеләр еш очрамый. Фәһим ага исә әнә шундыйлардан. Дүрт сыйныф белем белән ул әллә нинди катлаулы сызымнарны укый белә, ә ясаган рәсемнәрен әйтеп тә тормыйм. Ул бит махсус бер җирдә укымаган, фәкать табигать биргән таланты. Тагын әле оста итеп гармунда уйный, челтәрләп тәрәзә яңаклары, өй җиһазлары ясый. Әйе, хәзер инде үткән заманда язарга кирәктер. Соңгы ике елда бабай кулына гармун да, эш кораллары да, карандаш та алмаган.

– Ә менә балык тотарга барасы килә, – ди ветеран. – Сигез яшемнән балык тоттым. Эшләгән вакытта балыкка бик йөреп булмады, ләкин лаеклы ялга чыккач, күлдән кайтып кермәдем. Күл якында гына безнең. Мәрхүмә карчыгым: «Тагын кармагын алган бу!» – дип әрли торган иде. Балык тоту минем өчен ял бит ул.

Фәһим ага кайда гына эшләмәгән: колхоз умартачылыгы, клуб мөдире. Ләкин шулар арасында аеруча горурланып сөйли торган эше бар:

– Егерме елга якын Чирмешән урта мәктәбендә балаларга сызым, рәсем дәресләре укыттым, – ди ветеран. – Укучылар мине бик хөрмәт итә иде. Мәктәп эшенә кирәкле бөтен плакатларны матур итеп язып бирә идем. Әле колхозга да гел заказ биреп тордылар.

– Боларның барысына да үзлектән өйрәндегезме? – дим.

– Әйе, үзлегемнән. Әйтәм бит, балачактан матур рәсемнәр ясадым, яздым. Андый эшләрне укытучылар гел миннән эшләтә иде. «Сиңа укырга Мәскәүгә барырга кирәк», – дип әйтәләр иде. Әле сугыштан кайткач та уку хыялым бар иде. Аннары инде суындым. Гаилә корырга, тормыш алып барырга кирәк бит. Ярар, авылның үзешчән рәссамы булу да бик мактаулы бит. Мин ясаган тәрәзә яңаклары Багышта да, күрше-тирә авылларда да әле дә бар.

КАДЕРЛЕ ЯДКӘР

Рашат абый әтисенең көндәлеген әзерләп куйган иде. Дистә ел элек Фәһим ага күңел сандыгында булган бик күп истәлекләрне дәфтәргә язган. Анда балачагы, сугыш еллары, Багыш авылы тарихы – барысы да бар.

– Бу көндәлек гаиләбезнең кадерле бер ядкәре, – диде Рашат абый.

Фәһим аганың хәрефләре энҗе кебек тезелеп киткән: тәҗрибә барлыгы күренеп тора. (Ул көндәлектән кайбер истәлекләрне сезгә дә тәкъдим итәрбез, хөрмәтле укучыбыз).

Рашат абый әтисе язганнарның бер өлешен кычкырып укып чыкты. Янәшәдә Фәһим агада утырды: кайбер җирләрен төзәтеп җибәрде...

– Әтиегез сезгә карата ничек булды? – дидем Рашат абыйга.

– Бик яхшы булды. Бармак белән дә чиертмәде ул безгә. Югыйсә шук идек. Ә менә әнидән күп эләкте. Андый вакытта әти яклап чыга иде. Ул безгә ак белән караның нәрсә икәнен тыныч кына аңлата белде. Әтигә рәхмәттән башка сүз юк. Исән-сау булсын, бергәләп йөз яшен дә каршы алырга язсын.

...Сугыш ветераннары белән аралашу һәрвакыт күңелне кузгата. Тын да алмыйча, аларның истәлекләрен тыңлыйсың, йөрәк яраларына кагылудан куркасың. Ә менә Фәһим ага белән сөйләшү җиңел булды. Күбрәк иҗат, тормыш турында гәпләшкәнгәме, киеренкелек сизелмәде. Нечкә күңелле, иҗатка гашыйк ветеранга саулык, сөенечле гомер телибез. Балалары җәйгә ничек тә күлгә балыкка алып барырга вәгъдә бирде. Шулай булгач, бабайның бу теләге дә тормышка ашыр, дип өметләнәбез.

мәңгелек кыйммәтләр /

игелекле эшләр

акыллы гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Шакир Измайлов татар тарихында **нинди** эз калдырган

Хәмит Ярми ядкәре **кайда** саклана

Безнең киштәдә **нәрсәләр** бар

Югары Тәкермән **нинди** хыяллар белән яши

ШАМИЛ ИЗМАЙЛОВ – ИКЕ ФОТОСУРӘТ АРАСЫ

Римма Вильданова, тарих фәннәре кандидаты

Алдымда – ике фотосурәт, якынча 15–20 ел аерма белән төшелгән. Беренчесеннән безгә яшь кызылармиячеләр үткен, шул ук вакытта тыныч карашы төбәлгән. Икенчесендә тормышның ачысын-төчесен татыган, талчыккан кеше сурәтләнгән. Бу вакыт аралыгына коммунист Шамил Измайловның бөтен хезмәт юлы сыйган.

Шакир Измайлов – ТАССРның хезмәт халык комиссары, соңрак – СССР Тышкы эшләр халык комиссариаты хезмәткәре. Шакир Сембер шәһәренең Куликовка бистәсендә туып-үскән. Машинист Сафиулла Измайловның ишле гаиләсендә алты бала була. Иң олысы һәм бердәнбер малай – Шакир. Сүз уңаеннан, бу гаиләдә туып-үскән тагын бер күренекле шәхес – ТАССРның халык артисты, җырчы, 50 ел Мәскәү консерваториясендә укыткан Асия Измайлованың исеме дә безгә бик таныш.

Тарихи документларга караганда, Сафиулла Измаил улы 1903 елда графиня Кассининың Лаеш тегермәнендә пар машинасы машинисты булып эшли, ә 1906 елда Сусоколов заводында хезмәт куя: «тырышып һәм эшен белеп эшли, ...яхшы эшче санала, хәмер белән мавыкмый һәм эшен санга сукмауда гаепләнми». Илдә нэп чоры башлангач, Сафиулла Буада «Красная Звезда» авыл хуҗалыгы кредит ширкәтен җитәкли, аннары, Яшел Үзәндәге Серго исемендәге заводка күчеп, хезмәт ударнигы була. Һәм, әлбәттә, район Советының, ВКП (б) шәһәр Советының, профсоюзның актив әгъзасы санала. Гаиләдәге әни кеше турында мәгълүмат сакланмаган.

Шакир 1897 елда туа, әти-әнисе аны укырга тырыша, шуңа күрә мөселман белеме бирү белән генә чикләнеп калмыйча, 1910 елда 4 сыйныфлы Шәһәр училищесына укырга бирә. Монда дворян, мещан, эшче балалары белем ала, әмма төп катлам крестьяннар була. Училищеда рус теле, арифметика, геометрия, табигать белеме, физика, тарих, география, чиста язу, сызым, рәсем укытыла. Моннан тыш, җыр һәм гимнастика керә. Әлеге училищены тәмамлаучылар дәүләт хезмәтенә сынауларсыз кабул ителә, хәрби бурычны үтәүдә дә алар өчен ташламалар карала. 215 укучы малайның дүртесе генә мөселман була. «Алдан әзерлеге йомшак булган» Шакир Измайлов беренче сыйныфта, уртача 2,8 баллга ия булып, икенче елга утырып кала. Шуңа күрә аның училищеда иң яхшы укучылар арасында булуы турындагы кайбер фикерләр документлар белән расланмаган, дип әйтәсем килә.

СУГЫШЧАН ЮЛ

Әмма монда төпле белем бирелә, документларга караганда, Шамил Измайлов матур итеп язуы һәм дөрес сөйләм теле белән башкалардан аерылып тора. Беренче бөтендөнья сугышы башланганда егеткә 17 яшь тула, армиягә алынганчы ул тимер юл депосында паровозларны майлаучы булып эшләргә дә өлгерә. 19 яшендә армиягә алынып, Самарада сапер полкында хезмәт итә, намуслы хезмәте өчен кече сержант Шамил Измайлов «Сугышчан казанышлар өчен» медале белән бүләкләнә. Шул арада илдә сәяси үзгәрешләр башлана – Февраль революциясе кузгалә. Шакир 1917 елның августында Берләшкән мөселман социалистлар комитетының большевистик үзәгенә керә, аннары Самарада совет хакимиятен урнаштыруда катнаша.

Октябрь революциясеннән соң ук большевиклар оештырган иң беренче комиссариатлар арасында Милләтләр эшләре буенча халык комиссариаты да була. «Россия халыклары хокуклары декларациясе» халыкларга үзбилгеләнү хокукы, үз дәүләтчелеген төзү, алга таба икътисади һәм мәдәни үсеш мәсьәләләрен үзләре

Фотолар автордан алынды

хәл итү мөмкинлеген бирә. Әлбәттә, мондый милли сәясәтнең миллионлаган тарафдарлары да табыла. Тиз арада РКП (б) губерна һәм өяз комитетлары каршында типлаштырылган вәкиллекләр (милли бүлекләр), шул исәптән мөселман бүлекләре дә төзелә. 1918 елның апрелендә – Самарада, ә декабрьдә Сембердә милли бүлекләр барлыкка килә, аларны эшчеләр Г. Садриев (Самара) һәм С. Гафуров (Сембер) җитәкли. Күрше Самара губернасы большевиклары исемлегендә таныш фамилияләр очрый, мәсәлән, безне кызыксындырган 21 яшьлек Шакир Измайлов. Сыналган һәм грамоталы кеше буларак, Шакир РКП (б) губкомының мөселман секциясе рәисе Г. Садриевның секретаре вазифасын башкара. 1918 елның җәендәге сугышлар нәтиҗәсендә Идел буенда хакимият Комучка күчә, бары тик октябрьдә генә большевиклар идарәне тулысынча үз кулларына ала. Измайловны Мәләкәскә эшкә күчерәләр, ә тиздән ул С. Гафуровның секретаре сыйфатында туган шәһәре Сембергә кайта. Шәһәрнең мөселман секциясе күпмедер вакыт Азатлык йортының 1 нче катында урнаша, аннары – Гончаров урамына, ниһаять, 1921 елдан татар районының үзәге саналган Лосевая урамына күчә. Йортларның номерлары үзгәргәнлектән, хәзер бу якынча Федерация урамындагы 29 нчы йорт дип санала. Ул вакытта, әлбәттә, беркем дә Октябрь революциясенең һәм вәгъдә ителгән социализмның озакка сузылган Гражданнар сугышына әйләнеп, зур югалтуларга китерәчәген белми әле.

ЯҢА ТОРМЫШ ТӨЗҮ

Тирә-юньдә нинди генә куркыныч вакыйгалар барса да, яшь большевиклар өчен бу яңа идеяләргә, якты киләчәк, гадел тормыш өчен көрәшкә романтикларча ышану вакыты була. Шулай ук мәхәббәткә дә, чөнки Самарада Шакир үзенең булачак хатыны – математика укытучысы Фатыйма белән таныша. Укытучы кыз инде коммунист була, ә Шакир әле теләктәшлек күрсәтүче генә санала. Һәм менә 1919 елның маенда ул да партиягә кабул ителә. Мөселман секциясендә барлыгы 7 РКП (б) әгъзасы исәпләнә, шуларның кайберләре даими рәвештә Мәскәүгә яки Казанга алына, ә кайберләре турыдан-туры фронтка чакырыла. Шул рәвешле Шакир да 1919 елда Көнчыгыш фронт гаскәрләрен формалаштыру, комплектлау һәм укыту идарәсенең сәяси бүлеге хезмәткәре булып ала. Командировка озакка сузылмый, һәм менә актив коммунист яңадан Сембер авыллары буйлап йөри, совет хакимиятен хупларга өнди, большевиклар ячейкалары төзи. Аны губерна бюросы әгъзасы итеп сайлыйлар, Мәскәүгә II Бөтенроссия Көнчыгыш халыкларының коммунистик оешмалары съездына җибәрәләр, ә анда Татар-Башкорт республикасы язмышы хәл ителә.

1920 елда татар секциясе рәисе С. Гафуровны Казанга алалар һәм аның урынына Шакир Измайлов билгеләнә. 10 гыйнварда узган губерна бюросында ул беренче тапкыр татар яшьләрен – Коммунистик яшьләр союзын, татар хатын-кызларын үз оешмаларын төзергә чакырып доклад белән чыгыш ясый. Яңа инициативалар өчен җаваплы итеп Фатыйма һәм Шакир Измайловлар билгеләнә. Мөселман секциясе актив рәвештә пропаганда белән шөгыльләнә, атна саен митинг, конференцияләр үткәрә, лекцияләр укый, наданлыкны бетерү, Кызыл Армияне тулыландыру белән шөгыльләнә. Нәкъ менә шәһәр бүлеге коммунистларның төп үзәге санала, монда беренче татар китапханәләрен оештыру, эшче клубларын ачу идеяләре яңгырый, концерт һәм спектакльләр куеп, милли эшләр өчен акча җыела. Тиздән башка өязләрдә дә бу ысулларны куллана башлыйлар.

Гражданнар сугышы, элеккеге байларның саботажы, акчаның бөтенләй булмавы шарт-

РКП (б)ның Сембер губкомы. 1918 ел.

Көнчыгыш халыкларының II съезды делегатлары. Мәскәү, 1919 елның декабре.


Принять к сведению

ПРЕДСЕДАТЕЛЬ

СЕКРЕТАРЬ

С. Гафуров һәм Ш. Измайловның шәхси имзалары. 1919 ел.

ларында секциянең кечкенә генә штаты куелган зур бурычларны үтәргә тырыша. Чынлыкта планнар үтәлмәслек дәрәҗәдә катлаулы була һәм күп вакыт коммунистлардан искиткеч фидакарьлек таләп итә. Эшләр авыр бара, дәртле шигарьләр бары тик сүздә генә кала, халык тормышның яхшыруын күрми. Авылларда анда-санда фетнәләр күтәрелеп тора, зур авырлыклар белән оештырылган совет хезмәт мәктәпләре салкын кышларда җылытылмый, дәреслекләр җитми, китапханәдә өстәл-урындыкларга кытлык зур була, драма театры агитбригада рәвешендә генә эшли һ.б. Ялгышлар да шактый була. 1920 елның март башында Карсун татар съездын мисал итеп китерергә мөмкин. Делегатлар, олаулар җигеп, съездга берничә тәүлек дәвамында җыела. Мөселманнар күптән хыялда йөрткән Татар-Башкорт республикасын оештыру мәсьәләсе кискен бәхәсләр уята. Башкортларның татарлар белән бердәм республикага риза булмавы турында Үзәк Комитет күрсәтмәсен алган Шакир Измайлов корылтайда катнашучыларны зур авырлык белән әлеге гамәлнең максатка ярашмавына ышандыра, съездда фикер агышын үзгәртүгә ирешә. Нәтиҗәдә «Татар республикасы татар хезмәт массаларына бернәрсә дә бирми, киресенчә, РСФСР төзелешен катлауландыра, бигрәк тә икътисади яктан» дигән резолюция кабул ителә. Делегатлар «революцион Россиянең алдынгы пролетариаты белән ныклы элементдә баруны» яклый. Әмма өяз резолюцияләренә карамастан, аерым Татар һәм Башкорт республикалары төзелә.

СӘЯСИ АГАРТУ ЮЛЫНДА

1920 елның сентябрендә Сембердә губерна конференциясе оештырыла, делегатларның кәефе шәптән булмый. Ибраһимов дигән бер иптәш коммунистларның мәгариф юнәлешендәге эшен тәнкыйтьли, шуннан соң... кулга алына һәм Губчекага тапшырыла. Шуңа күрә «демократик централизм» һәм партия дисциплинасы совет хакимиятенең беренче елларыннан ук шәйләнә башлый. Шул ук вакытта Губчека хезмәткәре булган иптәш Бикмөхәммәтов губерна милли бүлегенә мәдәни-агарту бүлекчәсе мөдире итеп билгеләнә. Совет кадрларына кискен кытлык 1921 елның маенда татарча 3 айлык сәяси курслар оештырырга, моның өчен кирәкле акчаларны табарга мәҗбүр итә. Дәресләр Сембер шәһәрендә үткәрелә, курсантлар паек һәм хезмәт хакы, юл акчалары һ.б. ала. Татар секциясе хезмәткәрләре лекторлар сыйфатында эшли. Әйтик, дөнья белемен һәм сәяси икътисадны - Шакир Измайлов, арифметиканы Фатыйма Измайлова укыта. Чыгарылыш укучылары агитаторлар буларак губернаның төрле өязләренә җибәрелә. Ул еллардагы хисап кәгазьләрендә «клубта бернинди массакүләм һәм сәяси эш алып барылмый, портретлар, лозунглар юк, плакатлар, газеталар һ.б. чыгарылмый. Клубта сайлау законы, Конституция һәм иптәш Сталинның докладлары буенча бер чыгыш та булмаган, түгәрәкләр оештырылмаган» дип язылган.

АЧЛЫККА КАРШЫ КӨРӘШ

Икенче бер кискен проблема – сукбай балаларның күбәюе. Алар өчен балалар йортлары оештыруга бәйле рәвештә җир бүлегеннән «Акчуриннар һәм Сәет Шакуловның Иске Тимошкинодагы алпавыт утарларын сорарга» дигән карар кабул ителә. Измайловка Сембердә ике балалар йорты һәм милли азчылыктан булган инвалидлар йорты оештыру бурычы йөкләнә. Өлкән яшьтәге татарлар өчен Сембер өязендәге Абушаевларның элеккеге утарында яшәү урыны ачыла. Ачлыктан интегүчеләр ихтыяҗына акча җыю 1921 елның иң авыр проблемасы була. Сембердәге фаҗигале хәлләр турында иң ачык мисалларның берсе – җирле «Таң» татар газетасында эшләүче Галиев дигән берәү үз балаларын балалар йортына тапшыру турында үтенеч белән мөрәҗәгать итә. Ул моны нишләргә белмәгәннән эшли бит инде... Шул ук вакытта Иске Алгашы авылыннан 30 крестьян гаиләсе «иген уңмау аркасында көн итү мөмкинлеге калмау сәбәпле, аларны Себергә күчерүне» сорый. Шакир Измайлов 1921 елның язында һәм җәендә шәһәрдә ачлыкка каршы көрәшнең алгы сафында була. «Ачлык кичерүче татарларның күпчелеге урамда йөри һәм, йортсыз калып, пристаньнарда куна, алар арасында йогышлы авырулар тарала» дигән борчылуын белдерә, алар өчен даими яшәү урыны табу белән шөгыльләнә, азык-төлек бирүгә, ашханәләр ачуга ирешә.

ХАКИМИЯТНЕҢ ЮГАРЫ БАСКЫЧЫНДА

Шакир Измайловның тырышлыгын күреп алалар, һәм аның карьерасы кискен күтәрелә. 1922 елда ул Мәскәүдә РКП (б) Үзәк Комитеты каршындагы татар-башкорт бюросы секретаре, ВЦСПС инструкторы була. Ләкин 1924–1925 елларда Измайлов турында мәгълүмат җирле архив материалларында кабат күренә. 1924 елның гыйнварында киңәшмә уза, анда бер балалар йортының аяныч хәле турында фикер алышалар. Җыелыш балалар йортына ярдәм итәргә, аның өстеннән шефлык алырга карар кыла. Җиде кешедән торган комиссия (шул исәптән Шакир Измайлов) оештыралар һәм аңа балалар йорты өчен акча эзләүне йөклиләр. Шул ук елда РКП (б) ҮКның агитация һәм пропаганда бүлеге җаваплы сәяси хезмәткәр – иптәш Шакир Измайловның сеңелләрен җирле рабфакка кабул итүне сорый: Хәдичәгә – 17 яшь, Рәйханага 16 яшь була. Ә тагын бер сеңлесе Зәйнәпне К. Маркс исемендәге интернат-мәктәпкә урнаштыралар.

1925 елда Шакир Измайлов ТАССРның хезмәт халык комиссары, Татар Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасы итеп билгеләнә. Хатыны һәм ике улы белән Казанга күченә. М. Подольскаяның «Шакир һәм Урания» мәкаләсендә тасвирланганча, алга таба нарком язмышында кискен борылышлар башлана. «1920 нче еллар ахырында Мәскәү илнең мөселман лидерлары белән шактый кискен көрәш алып бара. Аларның иң күренеклесе – Мирсәет Солтангалиев – кабат кулга алына. Органнар, әлбәттә, Шакирның бу кеше белән Самарада, Казанда һәм Мәскәүдә бергә эшләвен белә. Аның партия исәп карточкасында бу көннәрдә кызыл кара белән «02.1928 елдан эшсез» дигән язу пәйда була... 1928 елның җәендә тәгәрмәчле пароходта Идел буенча барганда Шакир яңа мәхәббәтен – Уранияне (милләте буенча – грек) очрата. Ике тыелгысыз характер, ике яшәү көче очраша. Җитез һәм үзсүзле Шакир Уранияне никахны теркәргә күндерә, җае да килеп тора: моны теләсә кайсы ЗАГСта эшләп була. Кирәк булса, аерылышуны да тиз оештырырга мөмкин. Шакир кемгәдер шалтыратып, үзе кайтканчы, хатыны Фатыйма белән ике кечкенә улын – Борис белән Равилне – Ташкентка җибәрергә боера. Кырыс наркомга каршы төшү беркемнең дә башына килә алмый».

Яңа хатыны белән ул Мәскәүгә китә. Башта ВЦСПС инструкторы, Профинтернның оештыру бүлеге инспекторы була. Ләкин Шакирны СССР Тышкы эшләр халык комиссариатының җаваплы хезмәткәрләре курсларына юллыйлар, стипендия дә билгелиләр. Ил бу вакытта Якын Көнчыгыш күршеләре белән мөнәсәбәтләр урнаштыра, ашыгыч рәвештә мөселман дипломатик хезмәткәрләре кирәк була. Шакир дәресләрдән соң да тырышып телләр өйрәнә. Инглиз, гарәп, фарсы телләрен үзләштерә. Бик күңелле яшиләр. Бертуганы Асия Измайлова Мәскәү филармониясендә җырлый, алар ире – язучы Шамил Усманов белән кичләрен еш кына кунакка килә. Шамил белән Шакир күптәнге сугышчан дуслар булганга, уртак сүзләре шактый була. 1931 елда дипломатик курсларны уңышлы тәмамлаган Шакир Измайловны СССРның Согуд Гарәбстаны Корольлегендәге Тулы вәкаләтле вәкиллегенең беренче секретаре итеп җибәрәләр. СССР Тышкы эшләр халык комиссариатының 1 нче Көнчыгыш бүлегендә җаваплы референт булып та эшли.

Делегат С.И. Измайлов мандаты. 1934 ел.

ФАҖИГАЛЕ ЯЗМЫШ

1936 ел. Шакирны Мәскәүгә чакырып алалар һәм кыска вакытка Азәрбайҗан ССРга СССР Тышкы эшләр халык комиссариатының вәкаләтле вәкиле вазифасын башкаручы итеп җибәрәләр. Күршедәге Иран тиз арада әйдәп баручы Көнчыгыш илләренең берсенә әйләнә. 1937 елның сентябрендә Шакир Измайлов Иранга илче вазифасына билгеләнә. Билетлар сатып алынган, багаж җыелган, әмма шушы көннәрдә икенче никахтан туган олы улы Фәриткә алты яшь тула. Китәр алдыннан бөтен гаилә белән җыелып алырга уйлыйлар. Татарстаннан этисе Сафиулла белән сеңлесе Зита килә. 21 сентябрьдә театрга китәләр, аларга Асия дә кушыла. Төнлә исә Леонтьев тыкрыгында урнашкан йортлары ишегеп шакыйлар, тентү башлана. Йортның астын-өскә әйләндерәләр. Шакирны кулга алалар. Аның кыйммәтле әйберләрен, иң кызганычы, Якын Көнчыгыш сәясәте һәм икътисады турында язылып яткан китабының кульязмасын алып китәләр. Соңгы елда ул китап өстендә күп эшли, гомумән, Якын Көнчыгыш буенча әйдәп баручы экспертларның берсе була.

Аның хатыны Урания артыннан 14 декабрь төнендә киләләр, берничә сорау гына бирәбез дип ышандыралар. Ул көнне сорау алу вакытында хатын бер сүз дә әйтми. Аңа ирен шпионлыкта, панисламчылыкта һәм контрреволюцион эшчәнлектә гаепләргә тәкъдим итәләр. Урания иренең шул ук бинада – Лубянкада утыруын, аның яшәренә инде бер генә көн калуын белми әле.

Икенче көнне, 1937 елның 15 декабрендә, коммунист Шакир Измайлов суд карары нигезендә атып үтерелә. Исеме 1956 елда аклана. Хатыны Урания исә ун көннән соң, «халык дошманы» хатыны буларак, 8 елга Караганда тирәсенә сөргенгә сөрелә. Балаларны Сафиулла бабалары Яшел Үзәнгә алып китә. Урания 1950 нче елларда, аклангшаннан соң, Мәскәүгә килә. Ил аңа үтерелгән ире өчен шәхси пенсия билгели. Ике ел кабинет бусагаларын таптаганнан соң, коммуналь фатирда кечкенә генә (икегә биш метрлы) бүлмә алып, шунда теркәлү хокукына ирешә, икенче торагын кайчандыр ире Шакир һәм балалары белән бәхетле гомер иткән Леонтьев тыкрыгындагы йорттан ала. Т

Шакир Измайлов Мәккәдә. 1934 ел.

ӘКИЯТЛЕ ИТКӘН ЯРМИ

Айдар Шәйхин

Хәмит Ярми турында ишетмәгән татар кешесе күп булырга мөмкин, әмма аның хезмәтләреннән файдаланмаган татар баласы калдымы икән? Хәзерге буынга балачактан таныш әкиятләрне, халык авыз иҗатының башка бихисап үрнәкләрен туплаган, эшкәрткән һәм калын җыентыклар итеп бастырган галимнәрнең берсе бит ул. Тукай премиясенә вафатыннан соң лаек дип табылган сирәк шәхесләрнең дә берсе...

СЕБЕР ТАТАРЫНЫҢ КАЗАНГА КИЛҮЕ

Хәмит Хөснетдин улы Ярмөхәммәтов, яки кыскача Хәмит Ярми дип фольклор һәм филология фәннәре тарихына кереп калачак егет 1904 елның 5 маенда туган. Туган җире – Тубыл губернасы Төмән өязенең Кырынкүл авылы. Мондый язмаларга хас мөһим бер мәгълүматны уртаклашмый булмый. Кырынкүл шактый билгеле авыл булган. «Булган», дигәннән... Ул тәмам юкка чыкмаган, тора-бара Төмән шәһәре территориясенә кергән. Шәһәрнең бер өлеше буларак, ул һаман да яши әле. Бу авыл үзе XVII гасырдан ук билгеле. Ярмиләр нәселе исә монда XIX гасырда төпләнгән булса кирәк.

Гасыр башы зыялыларының шактыена хас булганча, Хәмитнең дә этисе – мулла кеше. Хөснетдин Ярмөхәммәт (Ирмөхәммәт) улы Кырынкүл авылының имам-хатыйбы вазыйфасын

Фотолар автордан алынды

башкарган. Аның язмышы катлаулы: 8 яшендә ятим калып, атаклы Ямбай авылы сәүдәгәре Нигъмәтулла хаҗи Сәйдуков тәрбиясендә үсә ул. Үзе эти кеше булгач, балалары Сәйфи, Хәмит, Рәшит һәм Гайшәгә тиешле тәрбия-белемне бирергә тырыша. Шулай ук Хөснетдин мулла, үзенең балачак тарихын кабатлап, Мөхәммәтгали Тимергалиев атлы бер ятим баланы да тәрбияләп үстерә. Мөхәммәтгали совет елларында авылның мулласы булып кала.

Хәмит Ярминең этисе муллалык вазыйфаларын Октябрь инкыйлабыннан соң да калдырмый, шуңа күрә 1930 елда кулга алына, сөргенгә хөкем ителә. Себердә туган кеше тагын да салкынрак, дәһшәтлерәк якларга сөрелә. Ул Ханты-Мансийск якларында үлеп кала.

Хәмит тә кайчандыр этисен тәрбияләгән Нигъмәтулла хаҗи Сәйдуков мәктәбендә, Ямбай ягында укып чыга. Соңрак Төмән шәһәрендә педагогика училищесын тәмамлый. Бик тиз арада авыл һәм шәһәрдәге иҗтимагый тормышта катнаша башлый. 1923 елның 9 мартында «Сабан һәм чүкеч» дигән газетада Хәмитнең беренче мәкаләсе дә басыла. Ул мөгаллим Габдулла Урманчиев турында була.

1923–1930 елларда Хәмит Төмәндәге «Юксыллар чаткысы» газетасында – хәбәрче, Карбан, Бурбар авылларында ызбачы, авыл советы рәисе урынбасары булып хезмәт итә, Төмәннең 7 нче татар мәктәбендә, медтехникумда укыта, халык мәгарифе бүлегендә инструктор булып эшләп ала.

Укымышлы егет 26 яшендә туган ягын калдырып, югары белем алырга дип, Казанга китә. Аның нәкъ менә 1930 елда юлга чыгуы очраклы түгелдер. Этисе мулла буларак кулга алынган дәвердә, Хәмитнең үзенә дә яла якмый калмыйлар. Ничек инде мулла малае була торып, ул совет оешмаларында эшләргә тиеш, ди? Бу хакта органнарга донослар гына түгел, газеталарда ачык хатлар да күренә башлагач, Хәмиткә үзен коткарыр өчен, Татарстанга китәргә туры килә.

Хәмит Ярми КДУ студентлары Шаһидә Максудова-Ахунова һәм Нурихан Фәттах белән Актанышта фәнни экспедициядә. 1948 ел. Төмән өлкәсе туган якны өйрәнү музее фондыннан.

Төмәндә татар-башкорт клубы активистлары. Сулдан беренче – Хәмит Ярми. 1925 ел. Төмән өлкәсе туган якны өйрәнү музее фондыннан.

Казан Себер егетен яхшы каршылый. 1934 елда Хәмит Көнчыгыш педагогика институтын тәмамлый. Берничә ел дәвамында төрле оешмаларда: Баулыда район газетасында, Казанда «Кызыл Татарстан»ның культура бүлегендә эшләп ала. Берникадәр вакыт Татарстан Язучылар берлегенең җаваплы сәркатибе вазыйфасын били, Татарстан китап нәшриятында мөхәррирлек итә.

1939 елда исә ул хәзерге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшли башлый. Алга таба аның хезмәте дә, тормышы да шушы оешма белән бәйле. Сугыш елларында институт директоры вазыйфасын биләсә дә, калган чорларда ул фольклор секторын җитәкли. Казан университетының татар бүлегендә фольклор буенча лекцияләрне дә озак еллар буена Хәмит Ярми укый.

ФОЛЬКЛОР – УЛ ЯРМИ

Төмәндә педагогика техникумда укыган чакта Хәмит беренче тапкыр фольклор экспедициясенә чыга. 1923 ел бу. Техникумда татар әдәбияты укытучысы Тура елгасы буендагы бер татар авылына барырга тәкъдим итә. Шул сәфәр вакытында Хәмит әлеге өлкәдә беренче тәҗрибәсен ала. Әлбәттә, алар ул чакта фольклористика методологиясе белән якыннан таныш булмагандыр, әмма әле Каюм Насыйридан ук калган «халык сөйләгәнне язгыз» дигән принциптан чыгып, бу хезмәтне намус белән башкарып чыгалар.

Хәмит халык авыз иҗатын җыюга яңадан тиз генә әйләнеп кайтмаса да, бу беренче экспедиция барысына да нигез булып чыга. 1939 елда Казанда Татар теле һәм әдәбияты фәнни-тикшеренү институты төзелгәндә, Хәмит Ярми фәнни оешманы нигезләүдә катнаша. Катнашып кына калмый, ул әле аның структурасында фольклор секторын оештыра.

Габдрахман Әпсәләмов, башкорт язучысы һәм фольклорчысы Кирәй Мәргән һәм Хәмит Ярми. 1963 ел. Татарстан Милли музее фондыннан.

Институт архивының татар халык авыз иҗаты фондына да ул нигез сала. Ә бу фонд татар халкы өчен искиткеч кыйммәткә ия. Анда – безнең бөтен тарихыбыз, халык күңеленнән саркып чыккан иҗат.

Ярмигә кадәр татар фольклорчысы булганмы? Әлбәттә. Без халык авыз иҗатын җыйган һәм өйрәнгән Каюм Насыйрины, Хуҗа Бәдигыйны, Гали Рәхим, Галимҗан Ибраһимов кебек шәхесләрне яхшы беләбез. Тукайның да фольклор туплау белән мавыкканын хәтерлибез. Сүз уңаеннан, Хәмит ага үзе дә Тукайның халык авыз иҗатын өйрәнүе турында тәфсилле мәкаләләр язган, бөек шагыйрьнең бу юнәлешкә керткән хезмәтен югары бәяләгән.

Әйе, Ярмигә кадәр дә фольклорчылар булган. Әмма аңа кадәр бу фән белән шөгыльләнүчеләр өчен фольклор өстәмә бер эшчәнлек кенә булып торган. Хәмит Ярми исә, гомеренең билгеле бер этабын үткәч, төп фәнни көчен фольклорга багышлый. 40 ел буена ул халык иҗатын өйрәнә. Шуңа да аны беренче һөнәри татар фольклорчысы дип йөртәләр. Олуг хезмәтенең нәтиҗәсе – аның җитәкчелегендәге 30 лап фольклор экспедициясе, өйрәнелгән 500 ләп татар авылы, докторлык диссертациясе, «Татар халкының поэтик иҗаты» монографиясе, йөзләгән мәкалә һәм иксез-чиксез санда тасвирланган фольклор берәмлекләре.

ГАЛИМНЕҢ ХАТЫНЫ, ФОЛЬКЛОРЧЫ ХАЛИДӘ ГАТИНА ИСТӘЛЕКЛӘРЕННӘН:

– Язучылар берлеге белән безнең институтның фольклор секторы халык иҗаты кичәсе оештырды. Шуларның берсен оештыруга әзерлек эшләре барган көннәрдә егетләр барысы да төрлесе төрле эш белән йөри, ә мин телефонда кизү торам. Шулвакыт Гасыйм Лотфи шалтырата.

– Сеңлем, Ярми кичәсенә берәр артык билет юкмы шунда? Мин билетсыз калдым, – ди.

– Гасыйм абый, бу бит Ярми кичәсе түгел, фольклор кичәсе, – дим.

– Соң инде Ярми – фольклор дигән сүз, фольклор – Ярми дигән сүз, без бит барыбыз да шулай икәнен беләбез, – ди Гасыйм Лотфи.

«ИДЕГӘЙ» СЕЗ, ӘММА БӘЕТЛЕ

«Идегәй» дастанының татарча тәнкыйди текстын беренче булып Нәкый ага Исәнбәт «Совет әдәбияты» журналында бастыру бәхетенә ирешә. 1939–1940 елларда галимнәр тарафыннан дастанның Татарстанда һәм башка төбәкләрдәге татарлар арасында таралган вариантларын туплау максаты да куела. Бу эш белән шул исәптән Хәмит Ярми дә шөгыльләнә. Исәнбәт төзегән текстны академик басма рәвешендә әзерли башласалар да, Бөек Ватан сугышының башлануы, ә аннары, 1944 елдан, партиянең Алтын Урда тарихын өйрәнүгә мөнәсәбәтен үзгәртүе бу планнарны чәлпәрәмә китерә. Хәмит Ярминең дә, башка галимнәрнең дә, XV гасырда иҗат ителгән дастанны халыкка кайтару хыялы ул вакытта чынга ашмый кала. Әмма бәхеткә Ярминең фәнни эшчәнлеге шактый киң булып чыга.

Авыз иҗатының үзенчәлекле шигъри һәм музыкаль жанры булган бәетләрне Хәмит Ярми игътибарсыз калдырмаска тырыша. Бәетләргә ул аеруча саклык белән карый. Ул тарихи бәетләрне дә, «актуаль» темаларга чыкканнарын да барлап бара. Мәсәлән, сугыш елларында ул «Совет әдәбияты» журналы битләрендә илгә килгән хәсрәт турында чыккан бәетләр белән халыкны таныштырып бара. 1960 елда исә аның «Бәетләр» дигән гади генә исемле китабы дөнья күрә. Җыентык бик тиз арада сатылып бетә. Фольклорны өйрәнәчәк галимнәр өчен яхшы нигез барлыкка килә.

1976-1988 елларда Татарстанда фундаменталь әһәмияткә ия проект гамәлгә ашырыла: татар халык иҗаты үрнәкләре 12 томлык булып басылып чыга. Кайчандыр Хәмит Ярми милли фольклорны һичьюгы 6 томлык китап итеп нәшер итәргә хыялланса, сәгате суккач, аның укучылары 12 кисәктән торган тупланма әзерләү бәхетенә ирешәләр. 12 томлыкның проспектын төзүгә Хәмит ага күп көч түгә, ә әкиятләрдән торган ике томны башлыча үзе төзи. 1981 елда Хәмит ага вафат булып, алга таба томнарны шәкертләре әзерләп бетерә. Тулаем алганда, бу зур хезмәтне Хәмит Ярми, Илбарис Надиров, Хуҗиәхмәт Мәхмүтов, Флора Әхмәтова-Урманче һәм Ленар Җамалетдинов коллективы башкарып чыга. Ярми һәм аның шәкертләре-хезмәттәшләре командасы 1989 елда бу хезмәт өчен Тукай премиясенә лаек дип табыла. Ярми, шулай итеп, данлыклы бүләкне вафатыннан соң алган сирәк шәхесләрнең берсе булып чыга.

ӨЧ ДУС ДАСТАНЫ

Хәмит Ярми – гасырның әдәби һәм фәнни тормышы үзәгендә кайнаган шәхес. Шуңа да аның төрледән-төрле иҗатчылар белән тыгыз элемтәдә булуы табигый. Кайберләре белән ул аеруча дус була.

Флора Әхмәтова-Урманче үз хатирәләрендә Ярминең Шәйхи Маннур, Гомәр Бәширов һәм Хәсән Туфан белән якын дуслыгын искә ала.

Заманында Ярми, Маннур, Бәширов – өчесе бергә, «Идегәй»нең Казан татарларында сакланган вариантларын эзләр өчен, Татарстан авылларына экспедициягә чыга. Эзләгәннәрен тапмасалар да, данлыклы «Алпамша» дастанының борынгы вариантларын язып алып кайталар алар.

Бу экспедиция барышында Гомәр Бәширов көндәлек алып барган. Анда шундый кызыклы юллар бар:

«23 ноябрь 1940. Без Хәмит Ярми һәм Шәйхи Маннур белән бергә йөрдек. Ярми – киң күңелле, юмарт кеше. Эшен яратып, тырышып эшли. Иптәшлеге дә бик һәйбәт. Тик бераз җил як кеше. Үз фикере белән түгел, иптәше фикере белән йөрүчән. Кайчакны, шул кеше фикере белән йөри торгач, үзе дә күңелсезлеккә калгалый».

Имеш, шул вакыттан бу өч дус арасында Гомәр Бәшировның – «Кылтап патша», Шәйхи Маннурның – «Шыяп солдат», ә Хәмит Ярминең «Төпчек малай» һәм «Алпамша» дигән кушаматлары барлыкка килгән. Сөргеннән Хәсән Туфан кайткач, ул да бу дуслар төркеменә кушыла. Бу дүрт ирнең дүртесе дә Себер белән яхшы таныш булган шул: кемнедер тумышы, кемнедер хезмәте, сәяхәтләре, Гражданнар сугышы еллары сынаулары, сөрелүләр чиксез Себер иле белән бәйләп торган.

Хәсән, Шәйхи, Гомәр, Хәмит дуслыгы күпләргә үрнәк булырлык. Алар аксакаллар абруена ирешкәнче дә, ирешкәч тә, бергә күңел ачуның кадерен белгән. Бергә җыелып, озаклап утыруларын, гәп коруларын, шаяртып, «мальчишник» дип атаганнар. Туган көннәрен дә, башка күңелле вакыйгаларны да бергә үткәрергә яратканнар. Гомәр Бәширов 1964 елда Хәмит дусты турында мондый сүзләр яза:

«Хәмит Ярмине мин беренче мәртәбә моннан утыз ике ел чамасы элек газетада эшләгән вакытында очраткан идем. Уртачарак кына буйлы, калын коңгырт чәчле, беренче карауда берникадәр Алтай ягы халыкларына охшыйрак төшкән калкурак яңаклы, җиңел гәүдәле, хәрәкәтчән кеше. Ул, матросларча бераз алгарак йөгенеп, кулларын болгын-болгый, тиз-тиз атлап каядыр ашыга иде. ...Кайчан гына очрамасын, нинди шартларда гына күренмәсен, Хәмит Ярми һәрвакыт нindидер җитди бер эш башкарып йөрүче, һәркайчан кайдадыр ашыгучы эшлекле кеше тәэсирен калдыра. Әйе, гомер буе, һәрвакыт аның нинди дә булса бер җитди һәм ашыгыч эше булып килде. Моннан биш ел элек, ун ел, унбиш ел элек тә шулай иде, әле хәзер, алты дистәне тутырып, чәченә чал кергәннән соң да шулай. Әйе, аның һәрвакыт эше бар. Шуның өстенә, ул эшне һич тартырга-сузарга, соңга калдырырга ярамый, һич! Аннары аны кәфен кәфкә, кафын кафка китереп, бөтен ягыннан килештереп, тәмам җиренә җиткереп эшләргә кирәк.

Без халыкның фольклоры (яки авыз иҗаты), дибез. Болай дигәндә без җәмгыять тормышында, аның тарихында һәм әдәбиятында, сәнгатендә һәм көнкүрешендә ифрат зур урын тотучы бик зур бер тармакны, халыкның бик борынгы заманнан бирле телдән телгә, буыннан буынга күчеп килгән чиксез бай күңел хәзинәсен күз алдына китерәбез. Бу – санап бетергесез әйтемнәр, мәкальләр, табышмаклар, экиятләр, бәетләр, бу – уң меңнәрдән артып китә торган соклангыч җырлар, көйләр, төрле уеннар... Хәмит тә аны һичшиксез шулай күз алдына китергән булса кирәк. Әмма ул моннан байтак еллар элек Тел, әдәбият һәм тарих институтының ике еллык фольклор төркемендә эшли башлаганда, бу кулга кермәгән, хыялдагы байлык кына иде әле. Чөнки фольклорның язып алынган кадәресе ул вакытта кечерәк кенә бер папкага сыеп бетә иде. Диңгездән бер тамчы! Шул вакыттан башлап Хәмит Ярмине, көнен-төнен белмичә, илнең җир асты байлыкларын эзләүче тынгысыз геологка тиңләп булыр иде».

ХӘТЕР ТУРЫНДА

Хәмит Ярми 1981 елның 30 октябрендә вафат була. Аны Казанда да, туган ягы – Төмән өлкәсендә дә хәтерлиләр. Аңа багышлап үткәрелгән конференцияләр, басылган китаплар бар. Шунысы үзенчәлекле: Хәмит Ярми тормышын сурәтләгән ядкарьләрнең күбесе Төмән өлкәсе туган якны өйрәнү музеенда саклана. Тормыш иптәше Халидә ханым зур галимнең мирасын кече ватанына тапшырган. Шәһәрнең элек мөстәкыйль Кырынкүл (Казарово) авылы урнашкан өлешендә Хәмит Ярми урамы да бар.

Әмма галимнең исемен мәңгеләштергән иң мөһим нәрсә – аның без файдалана торган мирасы. Халык авыз иҗаты тупламалары һәрвакыт киләчәк буыннарга Хәмит Ярмине искәртеп торачак.

Дүрт дус – Хәмит Ярми, Шәйхи Маннур, Хәсән Туфан һәм Гомәр Бәширов. 1977 ел. Төмән өлкәсе туган якны өйрәнү музее фондыннан.

«БЕЗ КЕШЕЛӘРНЕ, КОМДАЙ, ИЛӘК АША ИЛИБЕЗ...»

Луиза Янсуар

Дөнья прокатына, ниһаять, без 2021 елда беренче өлешен караганнан бирле түземсезлек белән көткән Дени Вильнёв картинасы – «Дюна» чыкты. «Икенче Дюна» экраннарга килеп ирешкәнче, Фрэнк Герберт кайчандыр монументаль сагасында чагылдырып калдырган вакыйгалар, әйтерсең, чынбарлыкка үзләре дә әйләнеп кайтып урнашты.

Дөнья һәм без ышанган кыйммәтләрнең күпчелеге асты-өскә килде. Шулай итеп, бүген инде без һәм Вильнёвның, һәм Гербертның даһиена, күрәзәчәлек сәләтенә ышанмый булдыра алмыйбыз.

Теләсә нинди эшне башлаганчы, билгеле булган фактларны тупларга кирәк. Моны Гессер кызларының һәркайсы белә. Муад'Дибны аңлар өчен, иң беренче чиратта, аның туган вакытын исәпләп чыгару мөһим. Ул Падишаһ-император Шаддам IV идарә иткән чорның 57 нче елында дөньяга килде. Шулай ук туган урынын билгеләүдә дә бик сак булырга кирәк – аның планетасы Арракис. Каладанда туган һәм беренче 15 ел гомерен шунда уздырган дип алданырга ярамый. Бары Арракис, икенче төрле әйткәндә, Дюна гына – мәңгелеккә Муад'Дибның тарихтагы урынын билгеләгән җир.

Принцесса Ирулан,
«Муад'Диб турындагы язмалар»

Арракис планетасы шәфәкъ кергәндә аеруча матур. Кояш, әйтерсең, комнарга кадәр үк төшеп коена. Һавада меланж җемелди. Төн җитүгә, чүлгә краулерлар төшеп утыра, шул спайсны җыючылар болар. Чит планета вәкилләре көндезге челләгә кадәр өлгереп калырга ашыга. Алар инде бик күп еллар буе безнең җирләрне талый. Минем халкым килмешәкләрнең коточкыч явызлыгыннан изелә. Бу варварлар, Харконненнар, мин туганчы, бик күптәннән монда килеп урнашкан. Кулларына меланж чыгару мөмкинлеге бирелгәч, алар иләмсез байлык туплаган, хәтта императорны да куркытырлык байлык. Безнең яугирләр Арракисны Харконненнардан азат итә алмады. Әмма көннәрдән бер көнне, император указы буенча, аларга планетадан китәргә боерылды.

Бу карарны нинди максат белән кабул иттеләр икән? Һәм кем безнең яңа дошманыбыз булачак?

Фрименнар тарихы,
яки Чани истәлекләреннән

Фото: kinopoisk.ru

ПРЕЛЮДИЯ

Дөресен генә әйткәндә, Вильнёв «Дюна»ны экранлаштырырга алына, дигән хәбәр үзе үк авантюра иде. Кайбер кино тәнкыйтьчеләре әйтүенә караганда, «алдагы карьераңа кабер казуга тиң авантюра». Әмма «Прибытие», «Бегущий по лезвию» фильмнарыннан соң Вильнёвның Гербертка алынуы шәхсән минем өчен логик яктан бик тә аңлаешлы. Әйе, бу чынлап та сынау, әмма Вильнёв тудырган галәмнәр, бигрәк тә «Прибытие» атмосферасы, аның Арракиска да искиткеч тере итеп җан өрәсенә шикләндермәде.

Яхшы беләбез, моңа кадәр Гербертның «Дюна»сына инде «абынучылар» булмады түгел, булды. 1984 елда Америка киноиндустриясенең бүгенге көндә культ дәрәҗәсендә йөргән төп визионеры Дэвид Линч төшергән фильмны студияләр дә, тамашачы да пыран-заран китереп ташлаган иде. Ул 42 миллионга төшерелеп, Америка прокатында нибары 27 миллион җыеп, финанс ягыннан да уңышсызлыкка иреште, дип табылды. Аннан да бигрәк, Фрэнк Герберт фанатлары Линчны китап сюжеты белән артык ирекле кылануы өчен гаепләде. Режиссер үзе лентаның бәхетсез язмышын соңгы версия аның катнашыннан башка монтажлану белән бәйләп аңлата һәм үз фикерендә еллар буена катгый булып кала бирә.

Кайчандыр Линч тарафыннан «эпик космик опера» буларак экранга чыккан беренче чирканчыктан соң, студияләр «Дюна»ны кинотеатрлар хронометражына сыйдыра алмаячагына тулаем инана. Әсәрдән 14 сәгатькә сузылган сюрреалистик, психоделик космик масштабтагы картина төшерү идеясе белән янган Алехандро Ходоровски идеясе дә чәлпәрәмә килә. Ахыр чиктә, «Дюна»ны Сальвадор Дали, Мик Джаггер, Орсон Уэллс, Шарлотта Рэмплинг белән төшерергә хыялланган, контркультура кысаларында киң колач җәяргә омтылган Ходоровски проекттан баш тартырга мәҗбүр була.

Бу проект хәзергә кадәр Голливудта «төшерелми калган иң бөек фильм» дип искә алына. 2013 елда режиссер Фрэнк Павич аның масштабы һәм чынга ашмый калган язмышы турында документаль фильм төшерде һәм киң прокатка чыгарды – ул «Дюна Ходоровски» буларак билгеле. Аны Youtube белән Rutube киңлекләрендә табып алып карарга мөмкин. Сүз уңаеннан, Ходоровски хыялында йөрткән бер актрисага, еллар узгач, барыбер дә «Дюна»да төшү насыйп була – Шарлотта Рэмплингны Вильнёв Преподобная ролендә күрә.

Фрэнк Гербертның «Дюна» галәмен мини-сериал форматында 2000 елда тәкъдим итәләр. Сценарий авторы һәм режиссеры – Джон Харрисон. Тәнкыйтьчеләр сериалны нигездә уңай кабул итә, аның Герберт сюжетыннан ерак китмәвен, беренчел чыганак белән сак эш итеп әзерләнгәнен ассызыклыйлар. Шул ук вакытта аз бюджетлы сериалның «арзанлы» күренүе турында да сүз күп була. Асылда, бу хаклы дәгъвалар – сериал тулаем диярлек киностудия ангарларында төшерелә һәм күбрәк театрлаштырылган кинопостановканы хәтерләтә.

Баштарак Харрисон һәм аның командасы натурадан төшерергә ниятләсә дә, бу идеядән баш тартырга туры килә. Алар Австралия, Тунис, Марокко, хәтта Намибия чүлләрендә дә булып кайта, әмма бюджет белән график андагы һава шартларын, маневрга мөмкинлек калмавын искәртә.

ВИЛЬНЁВ ҺӘМ ШАЛАМЕ

«Дюна»ны төшерү хыялын режиссер Дени Вильнёв кечкенәдән күңелендә йөртә. Фрэнк Герберт романын ул беренче мәртәбә 13 яшендә укый һәм андагы дөньяларга баштанаяк гашыйк була. «Бу китапны гади генә, өстән генә аңларга кирәкми, ул глобаль галәми масштабтагы проблемалар белән беррәттән, үсү, балигъльк чорына керү, беренче мәртәбә мәхәббәт уяну, ул мәхәббәтне корбан итү, мәкер белән очрашу... һәм, әлбәттә, планетар экологик һәлакәт, капитализмның фаҗигасе турында да...» Әйтергә кирәк, әле тагын кайчан «Дюна» бүгенгедән актуальрәк, тәэсирлерәк була алыр иде икән?

2016 елда Legendary Pictures студиясе Фрэнк Герберт әсәрен экранлаштыруга хокук ала. Аның вәкилләре, билгеле инде, Вильнёвның хыялы турында ишеткән булалар. Һәм артык уйлап тормыйча чакыралар да. Вильнёвның шартлары арасында иң әһәмиятлесе – Пол Атрейдес ролендә ул бүгенге киноиндустриядәге һәм җир йөзендәге бары

тик бер генә актёрны күрә, башка берәүгә дә риза түгелмен, дип кистереп әйтә. Бу – Тимоти Шаламе.

Моңа кадәр нигездә арт-хаус жанрында эшләгән режиссерлар тарафыннан иркәләнеп килгән Тимоти Шаламе өчен «Дюна» – югары бюджетлы Голливуд блокбастерлары магистраленә чыгу мөмкинлеге. Ул, әлбәттә, берсүзсез ризалаша. Фильмны төшерү башланудан ярты ел элек тренировкаларга керешә, трюкларны булдыра алган кадәр үзе башкарырга теләвен белдерә.

> «ШАЛАМЕ РИЗАЛАШМАГАН БУЛСА, МИН ФИЛЬМНЫ ТӨШЕРЕРГӘ АЛЫНМАС ИДЕМ. ЙӘ – АНЫҢ БЕЛӘН, ЙӘ – БӨТЕНЛӘЙ КИРӘКМИ».
>
> **Дени Вильнёв**

Әйтергә кирәк, эш Шаламе харизмасы, тәңгәллеге белән генә тәгәлләнми, Вильнёв төшергән «Дюна» үзенең касты – иң йолдызлы составы белән дә яңа заман кино индустриясе тарихындагы тиңдәшсез очрак. Бу исемнәрне пиар-кампания вакытында, трейлерларда күрү генә дә инде соң чиккәчә ымсындыра иде: Джейсон Момоа, Зендея, Ребекка Фергюсон, Хавьер Бардем, Джош Бролин, Остин Батлер, Кристофер Уокен, Стеллан Скарсгард, Шарлотта Рэмплинг, Оскар Айзек, Леа Сейду, Дэйв Батиста, Флоренс Пью һ.б.

Фильмны караганда, ничек шулкадәр баланста һәм гармониядә була алалар соң, дип аптырыйсың, ансамбльгә, һәрберсенең үз урынында икәнлегенә, араларындагы бәйләнешкә сокланасың.

ДЮНА (2021)

Dune: Part One 12+
Кинопоисктагы рейтингы: 7,7
Елы: 2021
Иле: АКШ, Канада, Венгрия
Жанры: фантастика, боевик, драма, мажаралар
Слоганы: «Час настал»
Сценарий авторлары: Джон Спэйтс, Дени Вильнёв, Эрик Рот
Режиссеры: Дени Вильнёв
Композиторы: Ханс Циммер
Дөньякүләм премьерасы: 3 сентябрь, 2021
Бүләкләре: 6 номинациядә «Оскар» (иң яхшы оператор эше, иң яхшы куючы рәссам эше, иң яхшы тавыш, иң яхшы монтаж, иң яхшы визуаль эффектлар, иң яхшы саундтрек); «Алтын глобус» (иң яхшы саундтрек); Британия киноакадемиясе (иң яхшы оператор эше, иң яхшы тавыш, иң яхшы визуаль эффектлар һ.б.); «Сатурн» (иң яхшы грим); Актёрлар гильдиясе премиясе (иң яхшы каскадерлар составы).

ДЮНА: ЧАСТЬ ВТОРАЯ (2024)

Dune: Part Two 12+
Кинопоисктагы рейтингы: 8,6
Елы: 2024
Иле: АКШ, Канада, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Венгрия, Италия, Яңа Зеландия, Гамбия
Жанры: фантастика, боевик, драма, мажаралар
Слоганы: «Час настал»
Сценарий авторлары: Дени Вильнёв, Джон Спэйтс, Фрэнк Герберт
Режиссеры: Дени Вильнёв
Композиторы: Ханс Циммер
Дөньякүләм премьерасы: 6 февраль, 2024



ФРЭНК ГЕРБЕРТ КИТАБЫНА ШУЛКАДӘР САК ЯКЫН КИЛӘ ВИЛЬНЁВ ҺӘМ ШУЛ УК ВАКЫТТА КҮЗ ЯВЫН АЛЫРДАЙ УНИВЕРСАЛЬЛЕККӘ ДӘ ИРЕШӘ.

БӨЕК ҖИҺАДТАН СОҢГЫ... ЧЫНБАРЛЫК

Шулай итеп, инде киң форматлы сыйфатлы экраннарга (ә яңа «Дюна»ны бары тик IMAX форматында гына карарга кирәк!) яңадан озын кинолар кайткан дәвердә Дени Вильнёв «Дюна» мисалында баланс эзли. Герберт әсәрен өлешләргә бүлеп, мөмкин кадәр сюжетны да саклап, аны җиңеләйтеп тә, ничек эшләп булганын сынап карый ул. Әлбәттә, кино тәнкыйтьчеләре «Оскар»дан алып башка премияләргә кадәр бүләкләр өләшкәндә, Вильнёвны сценарий белән эшләүдә гаепләде һәм өлешсез калдырды. Янәсе, беренче өлеш – бары тик экспозиция генә, ни өчен әле тамашачы аңа үзенең ике сәгать ярым вакытын әрәм итәргә тиеш, бу – тиешле кануннарга сыешмау. «Дюна»га прокатта уңышсызлык юрадылар һәм... ялгыштылар. Тамашачы беренче «Дюна»ны ябырылып карап кына калмады, ә икенчесен сабыр гына тагын 3 ел көтте һәм прокат башланган беренче уик-эндта ук аны яртылаш диярлек җыемнар белән тәэмин итте.

Фильмның перспективалары булмавына ишарә итүчеләр, Герберт дөньяларының шушылай бирелүенә ризасызлык белдерүчеләр хәзер дә – җитәрлек. Шәхсән миңа Вильнёв «Дюна»сы иң уңышлылардан һәм нәкъ менә үз чоры, вакыты, кешелек язмышы турында сөйләгән иситкеч кырыс та, нечкә-нәфис тә намуслы картиналардан булып күренә. Аның беренче өлеше без инде чисталыкны, наз-нәзакәтне, ихласлыкны югалтып барган бу чынбарлыкта сискәндерерлек дәрәҗәдә ишарә булса, икенче өлеше – чын мәгънәсендә колачлы, шомлы, канны өшетә торган блокбастер. Син кайвакытта ышанып та бетә алмыйсың: ничек прокатка чыгардылар икән аны? Ничек безгә карарга рөхсәт итәләр? Ә иртәгә инде рөхсәт итмәсәләр?

Вильнёв сулыш алырга, уйларны йодрыкка тупларга да ирек бирми – менә, яңа гына Харконненнар тәхет тоталар иде, ул арада император Арракиска Атрейдеслар йортын китереп утыртты һәм аларны коточкыч мәкер белән һәлакәткә дучар итте; менә яңа гына Пол сәер төшләр дөньясында адашып йөрүче үсмер малай иде, инде ул Комнар Патшасын үзенә буйсындырган, фрименнарны үз артыннан иярткән Мәһди; менә яңа гына без чын-чынлап Бөек Сугышның сәбәпчесе һәм башында торучысы кем икәнен анык белә идек, ә икенче бер мизгелдә барлык яшерен җепләрнең борынгы Бене Гессерит орденына килеп тоташуын, асылда бу яуның гасырлар, меңьеллыклар дәвамында Бөек Генетик эксперимент, селекция хакына барганын ваемлап алабыз...

Асылда, без монда барыбыз да – корбаннар гына.

«Сине Мәһди дип әйтәләр. Ә карап торышка – гап-гади бер малай», – ди Чани, Пол Атрейдесның күзләренә кеше карашы күтәрә алмый торган зәңгәр күзләрен төбәп.

Нинди Мәһдине көтәләр бу халыклар? Нинди Квизац Хадерачны?

Фильм турында сөйләү спойлерлардан башка мөмкин түгел диярлек, шуңа аны карарга калдырыйк. Мин кинотеатр залында караганда, бигрәк тә яшьрәк тамашачыларга игътибар итеп утырдым: ничек аларга, дулкынландырамы, аңлашыламы ни дә булса... ягъни, «керәме?» Һәм, ни гаҗәп, күзләре яна, гәрчә Гербертны укып түгел, ә бөтенләй тотып карамаган булсалар да. Ә инде интеллектуаль тамашачы, барлык нюансларны йөрәге аша уздырып, бөтенләй иң югары кимәлдәге ләззәткә күмелә ала.

Беренче китабы уңышка ирешкәнчегә кадәр, Фрэнк Гербертка шактый күп иза чигәргә туры килә. Ә инде уңыш елмайгач, нәширләр аны, аңлашыла ки, тынычлыкта калдырырга җыенмый. Шулай итеп, трилогия гексалогиягә әверелә. Әтисенең соңгы китабы – «Капитул Дюны» чыкканнан соң 15 ел узгач, Гербертның вафатына 13 ел тулгач, улы Брайан язучы Кевин Андерсон белән берлектә әсәрнең дөньяларын тагын да киңәйтергә була.

25 ел дәвамында алар тагын 17 китап бастырып чыгара. Фанатлар арасында бу ике авторга мөнәсәбәт кискен аерыла: кемнәрдер Брайанны әтисенең эшен дәвам итүче дип күкләргә чөйсә, хупласа, икенче берәүләр «Брайан Фрэнкның мирасын пычратучы, акчага сатылучы» дигән караштта тора.

Барысын бергә туплап, исәпләп чыгарсак, «Дюна» галәме үз эченә 15 000 елны ала.

«ДЮНА ХРОНИКАЛАРЫ»: НИНДИ ТӘРТИПТӘ УКЫРГА?

- «Дюна»
- «Мессия Дюны»
- «Дети Дюны»
- «Бог-император Дюны»
- «Еретики Дюны»
- «Капитул Дюны»
- Брайан Герберт һәм Кевин Андерсон китаплары

P.S. Һәм, бонус буларак, интернетта «Дюна» саундтрек к сериалу» дип эзләгечтә җыярга, Циммер музыкасы тупланмасын йөкләтеп алырга киңәш итәм. Яхшы колакчыннарда тыңларга дигәнен өстәп торырга кирәкмидер, шәт?



«Татарстан» журналы үз битләрендә яшь прозаикларның кечкенә күләмдәге әсәрләрен бастыра башлады. Без бу авторларның исемнәрен бик ишетеп-белеп бетермәскә дә мөмкин. Бу – табигый. Араларында әле вакытлы матбугат битләрендә тәүге басылучылары да булачак. Димәк, үзенә күрә сынау, укучы алдында җавап тоту дигән сүз.

Бу кызлар белән егетләрнең заманыбызга, бүгенге көн вакыйгаларына, вазгыятенә үз карашлары, мөнәсәбәтләре бар. Үтә җитди, кискен иҗтимагый темаларга да мөрәҗәгать итә алар, мәңгелек сорауларга да җавап эзли, нечкә хиссияткә бирелеп, парча, нәсер кебек жанрларда да үзләрен сынап карый, юмористик рухта да иҗат итәргә омтылыш ясый.

Бүген без сезгә әле урта мәктәптә генә укый торган яшь авторның әсәрен тәкъдим итәбез. Әйдәгез, укып карыйк.

Таңчулпан Гыйлаҗова



Фотолар автордан, Лилиана Вәлиеваддан алынды

Автор турында белешмә:

2006 елның 14 маенда Теләче районы Баландыш авылында туган. Туган авылындагы төп мәктәпне кызыл аттестатка тәмамлаган. Бүгенге көндә Олы Мишә урта гомумбелем бирү мәктәбенең 11 нче сыйныфында белем ала. Татар теле һәм әдәбияты буенча республика фән олимпиадалары призеры. «Иделем акчарлагы» (2022, 2023) һәм башка иҗат белән бәйле конкурслар җиңүчесе.

Татар кинематографиясе, журналистика белән кызыксына.

ТУЗГАНАК БАЛЫ

Бүгенге шимбә иртәсе күңелгә әллә нинди рәхәтлек алып килде сыман. Эштән арып кайтып, көннең соңгы сәгатендә генә йокыга китүемә карамастан, кояшның беренче нурлары белән үк уяндым. Йокым туйган – бу сәер. Башка көннәрне бер дә алай булмый торган иде. Ничә тапкыр: «Бүген эшкә барасың юк бит, йокла инде!» – дип, үз-үземә ачуым килсә дә, тәрәзә төбендә сайраучы кошлар һәм әле өйләренә кайтмаган яшьләрнең шәһәрнең таш юлларында тыз-быз йөрүләре мине, җылы урынымнан торып, тәмле итеп чәй эчәргә чакырды.

Баксам, сәгать иртәнге өченче ярты гына икән! Үземнең бүгенге сәерлегемә

шаккатам. Ничек инде, көндезге уникедә дә трактор белән дә сөйрәтеп уята алмаслык мин, «йокым туйды» дип, таң белән уянсын әле!

Бу уйларымны читкәрәк куып, кичә эштән кайтышлый кибеттән кереп алган чәчәк балы белән чәй эчим әле дип, бар кайгымны онытып, хатирәләргә чумдым.

...Менә минем бала вакыт, менә әби. Һәм без икәү болында тузганак чәчәге җыеп йөрибез.

– Кайткач, чәчкәләрне кайнатырбыз да бал ясап куярбыз, кызым. Салкын тиеп авырганда, ютәлдән файдалы ул...

– Әбиме, бабаймы? – дим мин, аның нәрсә сөйләгәнен колакка да элмичә, кулыма йомарлап тоткан «картайган» тузганакны әбигә сузып.

Әби җавап кайтырырга да өлгерми, мин, шаярып, шунда ук тузганакка өрәм. Аның нәни «кулчатырлары» әбиемнең ак яулыгына килеп ябыша. Әле берсе көмеш төстәге кашына да эләгә, анысын әби табып алып, очып киткән иптәшләре ягына өреп җибәрә.

– Каян таптың аны? – дип аптырый әби. – Әллә агара да башлаганнармы? Бер-ике көн соңрак килсәк, балсыз да каласы булганбыз икән, кызым.

Ә болын – сап-сары. Кояш та көнне кыздыра башлаган кебек. Шуңа әби уйлавынча «җитәрлек» булгач, әкрен генә кайтырга кузгалабыз.

– Менә шулай, кызым, күрәсеңме, иртүк чыгып киткәч, болынның бу башына кадәр килеп җиткәнбез! Безгә балның иң тәмлесе әлэкте инде, – дип, озак барабыз бит инде дип шыңшыганга, мине тынычландырмакчы була әби. – Хәзер кайтып җитәбез дә, бергәләп, бал кайнатабыз.

Ләкин мин нигәдер киреләнәм. Имеш, аякларым арды – туктап хәл алам. Ә әби, әкрен генә барса да, мине узып, әллә кая, еракка барып җитә. Аны куып җитәм дип йөгерәм, әби туктап көтеп тора да, аннан тагын икәү атлыйбыз. Ул әкрен бара, ә мин, хәл җыеп торгач, аны узып киткән булам. Аннан әби миңа:

– Хәзер-хәзер, куып җитәм! Узып та китәм, – дип, куышлы уйнаган була.

Мәчет манарасындагы ай да күренә башлый. Димәк, күп калмаган, тиздән кайтып җитәбез икән.

– Беләсеңме, кызым, безнең заманда бу болында икмәк басуы иде. Бабаң шушында менеп, чалгычы егетләргә мине озаттым дип сөйләгән бит, – әбиемнең йөзе нурланып китә. – Ә ул мине озатмаган иде, менә шул. Тегеләргә үзен күрсәтмәкче булган.

– Ничек инде ул алай? Аны син озаттыңмы? Алай булса, кызыграк булыр иде, – дип, тагын киремне сукалыйм.

– Юк ла... Күрше урам Бибисаралардан сугышчыларга җибәреләсе оекбашлар бәйләүдән кайтып килешем иде. Аларның аталары станциядә эшләгәч, лампалары бар, – әби, туктап яулыгын рәтләгәндә, теге тузганак бөртеген табып, миңа бераз ачуланып карап ала. – Бабаңның каян кайтышы булгандыр, анысын белмим. Кызлар, караңгыда үзең генә йөрү куркыныч, кунып кал, дигәннәр иде, мин әни янына кайтырга ашыктым.

Мин инде әбинең бернидән дә курыкмаганын беләм идем. Кич белән караңгыдан шүрләп, аның кулын тотмыйча йоклап китә алмаганда, ул үзенең яшь чагында бернидән курыкмыйча йөрүен сөйли бит. Әле, киресенчә, бөтен кеше миннән куркып торган, дип тә шаярта ул.

– Шулай Миңлебикә апалар турысыннан кайтып киләм (син аны белмисең инде, хәзер алар урынында Саматның әбисе тора), артымнан гел кеше килгән кебек, – әби тагын туктап тора да, минем дикъкать белән тыңлаганымны күреп, дәвам итә. – Бара торгач, безнең урам тыкрыгына җиттек, өйгә керергә дә ике атлап, бер сикерәсе генә – теге арттан килә бит! Түзмәдем, кинәт туктап калдым да, шалт кына борылып, тегенең каршына килә башладым. Ул тыкрыкка кереп качмакчы иде, эләктереп алдым үзен. Караңгыда кем икәнен дә танымыйча торам әле! – Әби иң кызык мәзәк ишеткән кебек көләргә тотына. – Артымнан бабаң кайтып килә икән! Әй, син икәнсең, дидем дә өйгә кереп киттем.

– Ә бабай? – дип аптырыйм.

– Калды шунда үрә катып. Икенче көнне шушы басуга менгәч, бөтенесенә, озаттым, дип сөйләп йөргән, мәрхүмкәем.

Әле дә хәтерлим, бу сүзләрне әйтеп бетергәндә әбиемнең күзләре сагыш яшьләре белән тулы иде...

Их, әби кайнаткан балны тагын бер генә кашык кабасы иде ул, ә!

Үткәннәрдән айныганчы, әби белән чәчәк балы ясап йөреп, чәем суынып та беткән. Теге кибеттән алган балны әбинеке диеп капкан идем, әллә нәрсә булды үземә. Тиз генә киендем дә, машинама утырып, авылга кузгалдым.

Авыл уртасыннан әби-бабай нигезен карап узам. Анда хәзер мин белми торган кешеләр яши.

Томан күк – ничек барып җиткәнемне хәтерләмим. Каршымда – Тузганак болыны. Ап-ак. Янымда – әби.

– Өлгермәдең...

Иллюстрация: Равил Заһидуллин картинасы

ҮЗЕБЕЗНЕҢ ЛӘЙЛӘ

– Ниһаять! Авылга кайтам!

Бу сүзләр белән Ләйлә тиз-тиз әйберләрен җыя башлады. Аның күз алдында күптән көтелгән күренешләр: урман һәм басу кырыеннан үткән сикәлтәле юл, ерактан сәлам биреп торган күрше авыл таулары һәм менә – аны сагынып көтеп торучы дәү әнисе белән дәү әтисе!

...Бу юлы да Ләйлә авылга кайтып җиткәндә генә уянды. Шүрәле яшәгән урманны узганда, тәмле төшеннән бүлеп, чокырлы юллар тагын сәламләде үзен. Шүрәле махсус үзен искә алсыннар өчен, шулай чокырлар казып куя, дип шаяртырга ярата әтисе. Тагын да күбрәк казып куйган бугай, бүген бигрәк каты сикертә бит, чыдаган машинага рәхмәт!

– Ләйлә кызым да кайтып җиткән икән бит, – дип шат елмаеп, капка төбендә үк каршы алды дәү әтисе. – Дәү әниең син ярата торган мич коймагы пешерә, күптән көтәбез инде үзеңне.

Күперешеп пешкән коймаклардан бик тиз җилләр исте. Озак кына чәйләп алгач, кызның әти-әнисе кабат калага ашыкты. Көн кичкә авышкач, Ләйлә дәү әнисе белән көтү каршыларга китте.

Әллә тәпи китеп, беренче сүзләрен әйткәнче үк кызчыкны дәү әни белән дәү әти йортына алып кайту, әллә инде сабыйның йөрәге авылны сайлагангамы, Ләйлә дәү әниләрендә теләп кала, хәтта китәсе килмичә елый да иде. Ә менә аңардан соңрак туган сеңлесе исә бер дә апасына охшамаган: әти-әнисен дә, дәү әни белән дәү әтисен дә каладан кайтырга теләмичә аптыратып бетерә иде. Менә ул – гади генә заман аермасы...

Яңа сауган сөтнең тәмен беләсезме? Кичке салкын төшә башлаган саф һавалы көнне җылы сөтне күз ачып йомганчы эчәсең дә бетерәсең... Тагын кирәк! Шулай итеп 1–2 чокыр сөт юкка да чыга. Әле янында иптәшкә гел ашарга сорап торучы песи балалары да булса...

Менә хәзер Ләйлә нәкъ шуның белән мәшгуль дә. Янында алты баласы белән Йомшаккай да, Ләйләдән калышмыйк дип, ашыга-ашыга сөт эчәләр. Хайваннарны бигрәк ярата шул кыз.

Шулай беркөнне дуслары белән уйнарга чыгып киткән җирдән кыз пычракка батып беткән йонлач көчек алып кайтты.

– Сарбайны юындырырга һәм ашатырга кирәк! – диде кыз, бер дәү әнисенең аптыраш тулы түгәрәк күзләренә, бер кап-кара балчыкка баткан көчеккә карап. Көчек, аның сүзләрен дәлилләп, сыкраулы тавыш чыгарып куйды. Алар арасындагы беркем аңлый алмаслык серле мәхәббәт беренче караштан ук уянгандыр. Чөнки Сарбай белән Ләйлә шул көннән алып маэмайның картлыгына кадәр бер-берсен ташламады.

Ул елны күрше апаларның карлыганнары күп булды. Карлыган «өмәсенә» Ләйлә дә чакырулы, әлбәттә. Ниләр генә сөйләшми бу күрше апалар! Бер әйберне сөйли башлыйлар да, бөтенләй башка әйбер килеп чыга! Нәни кызның барысын да аңлап җиткерергә түземлеге җитми: «Су эчеп киләм, сезгә дә алып чыгам», – дип, тиз генә йөреп килә. Барыбер дә «Карлыганны иң күп җыючы» исемен ел саен Ләйләгә бирәләр бит.

Күрше апалар да, кызның саф күңелле икәнен белүче бөтен кеше дә Ләйләгә гел:

– Дәү үскәч, бик еш искә төшерерсең әле монда үткәргән көннәреңне. Тик безне онытма инде син, балам. Шулай кайткалап йөрерсең. Син бит үзебезнең Ләйлә! – дия торганнар иде. Нигә шулай дип баш катыралар? Ул бит әле үсәргә ашыкмый. Икенче кайтканда да «карлыган җыючы кыз»ны мавыктыргыч маҗаралар каршы алыр, ә ул аларны түземсезләнеп көтәр!

Шулай икән шул... Барысы да элеккечә кебек. Тик хәзер йорт капкасының тоткычына аяк очына басып үреләсе түгел, аңа өстән дә карап була икән... Урман белән басу яныннан үтә торган юл да бүтән сикертми – Шүрәле урманнан качкан ахрысы...

Татарстан авыллары

ЮГАРЫ ТӘКЕРМӘН – ГЕЛ БИЕКТӘ...

ЮГАРЫ ТӘКЕРМӘН

Фото: Лилиана Вәлитова

Минзәләгә «Татарстан» журналы десанты төште, ягъни районның яшәеше, эшчәнлеге белән тәфсилләп таныштык. Тукай районыннан чыгып, Минзәләгә кергәч тә, юл уңаенда Югары Тәкермән авылы шәйләнде. Иң беренче тукталыш шунда булды.

Руфия Фазылова

МӘКТӘП, МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ – АВЫЛ КҮРКЕ

Югары Тәкермән – зур авыл, 592 кеше яши, 263 хуҗалык бар. Үзәк урамда өр-яңа мәдәният йорты, аның янәшәсендә музей каршы ала. (Музейда әлегә капиталь төзекләндерү бара.) Ә төп белем бирү мәктәбе зурлыгы, матурлыгы белән тагын да әсир итә.

Мәдәният йорты 2019 елның азагында ачылган. Ул «Мәдәният» илкүләм проекты кысаларында күпфункцияле үзәк буларак төзелгән. Мәдәни үзәк Югары Тәкермәндә үскән шагыйрә һәм драматург Гөлшат Зәйнашева исемен йөртә. Китапханә дә шунда ук. Без килгәндә биредә мәктәп укучылары кино карый иде. Минзәләдән килеп, еш кына шу-

1

Мәдәният йорты Югары Тәкермәндә үскән шагыйрә һәм драматург Гөлшат Зәйнашева исемен йөртә.

2

Россиякүләм олимпиадага укучыларны Югары Тәкермән төп белем бирү мәктәбенең химия, биология, физика укытучысы Фәридә Шәрәфетдинова әзерләгән.

лай зур экранда төрле фильмнар күрсәтәләр икән. Гомумән, Югары Тәкермәндә мәдәният йортының ишеге бер дә бикле тормый.

– Без балаларны чын татар рухында тәрбиялибез, – ди Югары Тәкермән авыл җирлеге башлыгы Алия Шәрипова. – Әдәбият, сәнгать дөньясына берничә атаклы шәхесне биргән авыл бу. Шуның өчен район күләмендәге төрле чаралар да биредә уза. Балаларыбыз матур итеп ана телендә сөйләшә, мәктәптә татарча укыйлар. Белем йортының уңышлары бик зур.

Чынлап та, Югары Тәкермән төп белем бирү мәктәбе абруйлы. Биредә укып киткән балалар БДИларны гел югары баллга тапшыра. Республика, Россиякүләм бәйгеләрдә катнашып, призлы урыннар яулыйлар.

– Әле менә яңа гына ике укучыбыз экология буенча Россиякүләм олимпиададан җиңү яулап кайтты. Берсенең – беренче, икенчесенең өченче урын, – диде белем йорты директоры Флера Гәрәева. – Мәктәп бинасы 1980 елда салынган, 300 урынга исәпләнгән. Ике ел рәттән мәктәптә төзекләндерү эшләре булды. Бер елны белем йортының – эчен, икенче елны тышын яңарттылар. Аш бүлмәсе, «Үсеш ноктасы» программасы кысаларында җиһазландырылган химия, физика кабинетлары, спорт залы – барысы да заманча. Район башлыгы Айдар Фәслах улы бөтен программага кертергә тырыша, аңа бик зур рәхмәтле без.

Югары Тәкермән төп белем бирү мәктәбендә бүген 54 укучы белем ала. Быел тугызынчыны ике укучы тәмамлый, алты бала беренче сыйныфка киләчәк. Алга таба да балалар саны кимергә тиеш түгел, диделәр.

Мәктәптә химия, биология юнәлешенә дә игътибар зур. Дәрестә дә, дәрестән тыш чараларда да тәҗрибәләр ясыйлар, төрле тикшерену эшләре алып баралар. Директор әйтеп узган экология буенча Рос-

3

«Үсеш ноктасы» программасы кысаларында җиһазландырылган химия, физика кабинетлары, спорт залы – барысы да заманча.

сиякүләм олимпиадага укучыларны Югары Тәкермән төп белем бирү мәктәбенең химия, биология, физика укытучысы Фәридә Шәрәфетдинова әзерләгән. Мөгаллимә бу турыда менә тагын нәрсәләр сөйләде:

– Быел без үзебезнең якта үскән үләннәрне киптереп, шифалы чәйләр, хуш исле мендәрчекләр, гербарий ясадык. Олимпиаданың теория өлеше дә бар иде, укучыларыбыз аңа да бер дигән итеп җавап бирде.

Фәридә Шәрәфетдинова – үз һөнәренең чын фанаты, химия һәм биологияне ул җиңел итеп аңлата белә. Үз кызы да әнисенә охшаган: химиядән БДИны 100 баллга тапшырып, Казан дәүләт медицина университетына укырга кергән.

101 ЯШЕНДӘ УРАЗА ТОТА!

Авыл җирлеге башлыгы Алия Шәрипова безне Югары Тәкермәннең иң өлкән кешесе янына алып керде. Майда Гайниҗамал апа Дәүләтгәрәевага 101 яшь тула. Әбекәй ялгызы яши, кияүгә чыкмаган, балалары булмаган. Үсмер чоры, яшьлеге Бөек Ватан сугышы елларына туры килгән әбиләрнең берсе ул. Төп йорттан китмичә, әти-әнисен караган. Үзе әйтүенчә, аларның хәердогасы әбекәйгә әле дә ярдәм итә: һаман да кышын кар көри, җәен бакчасында печән чаба. Ай дәвамында уразасын да калдырмаган…

Әбекәй белән авылның үткәне турында сөйләштек. Бер гасыр яшәү дәверендә ниләр генә күрмәгән. Иң гаҗәбе – ул вакыйгаларның күбесен әле дә хәтерли.

– Авылда ике колхоз оешты, аның берсе – «Тукай», икенчесе «Сталь» исемен йөртте,- диде әбекәй. – Колхозда тугыз бригада иде. Башта кешеләр колхозга керергә теләмәде. Андыйларның өенә килеп: «Колхозга керсәгез, үзе ура, үзе суга торган машина бирәчәкләр», – дип үгетләп йөрделәр. Шуннан соң күпләр ризалашты инде. Кешеләр колхозга атларын, сабаннарын, чәчүлек орлыкларын да бирде. Язын бергәләп чәчү чәчтеләр. Ул елларда акча урынына номер бирәләр иде. Шул номер белән аннан азрак икмәк аласың. Кулак дип авылдан куылучылар да шактый булды. Кайберләренең исемнәре истә калган: Гали, Гает, Салих… Сугыштан соң колхозларны берләштерделәр. Аңа Муса Җәлил исемен бирделәр. Безнең авыл халкы бик эшчән, тырыш булды. Мәсәлән, минем эшләмәгән эшем калмады: урман да кистем, урак та урдым, соңрак колхозда бригадир да, келәтче дә булдым. Хисапчы, кассир, әйтәм бит, эшләмәгән эш калмады.

Гайниҗамал апа дүрт класс укыган. Ул Түбән Тәкермәндә яңа ачылган башлангыч мәктәптә уку бәхетенә ирешә. Заманасына күрә чынлап та яхшы белем йорты була ул. Бу урында Түбән Тәкермән мәктәбе тарихына тукталасы килә: 1921 елгы ачлык вакытында башлангыч мәктәп бинасын балалар приюты итәләр. Андагы ятим балаларны «Кызыл

Хач» җәмгыяте ярдәме белән ачлыктан саклап калалар. Ә бер елдан башлангыч мәктәп янә үз вазыйфасын үти башлый.

Гайниҗамал апа үз сөйләгәннәренә үзе аптырап утыра төсле тоелды. Еш кына: «И Аллам...», – дип куйгалады. Чынлап та, бер кеше гомеренә нинди күп үзгәрешләр туры килгән бит.

– Туганнарыгыз бармы соң? – дим әбекәйгә.

– Бертуганнарымның барысы да үлеп бетте инде, дүрт бала идек, иң олысы мин. Иң озак яшәүчесе дә мин булдым. Аллаһка шөкер дим, аягымда йөрим, ни теләсәм, шул бар.

– Болай озын гомерле булуның сере нәрсәдә дип уйлыйсыз?

– Әтинең хәер-догасы. Әти соңыннан сукырайды, саңгырауланды. Аны бала карагандай тәрбияләдем. «Кызым, мин сиңа гел дога кылып утырам, рәхмәт. Рәхәт яшәрсең», – дия иде. Әнине дә шулай кадерләп карап-тәрбияләп, соңгы юлга озаттым. Ул 98 яшькә кадәр яшәде. Аннары минем янга Түбән Тәкермәндәге сеңлем күченеп килде, җиде ел элек ул да мәрхүм булды. Менә шулай бөтен гаиләне барлап, зурлап, соңгы юлга озатырга миңа насыйп иткән. Моның өчен Аллаһы Тәгаләмә рәхмәт укыйм. Күршедә энемнең балалары яши, алар хәлемне белеп тора. Авылдашлар да ташламый. Ялгыз тоймыйм үземне, әйтмәгәнем булсын. Китаплар, газета-журналлар укыйм, намазымны калдырмыйм.

Йөзьяшәр әби-бабайларны күргән бар. Гайниҗамал апа, мөгаен, алар арасыннан иң җитезе, иң сәламәтедер, сөбханаллаһ. Сокландык әбекәйгә. Күкләр аңа нинди сәламәтлек, акыл, зиһен биргән, киләчәктә дә Аллаһ Тәгалә ярдәменнән ташламасын үзен.

4
Май аенда Гайниҗамал Дәүләтгәрәевага 101 яшь тула.

ДӘҮЛӘТОВЛАР ДӘҮЛӘТЕ

Югары Тәкермәнгә баргач, районның гына түгел, республиканың да иң мактаулы крестьян-фермер хуҗалыгы белән таныштык. Нәсим Дәүләтовны ТР Рәисе Рөстәм Миңнеханов та чыгышларында мактап телгә ала. Узган ел атаклы фермер «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнгән.

«Дәүләтов» крестьян-фермер хуҗалыгы Россиядәге ачык һавада яшелчә үстерүчеләр арасында иң заманча техника-технологияләргә нигезләнгән сирәк хуҗалыклардан берсе. Алар үстергән бәрәңге, кәбестә, кишер, кызыл чөгендер һәм башка төр яшелчәләрне, Татарстаннан тыш, Башкортстаннан, Оренбург өлкәсеннән, хәтта Казахстаннан да килеп алалар.

Нәсим Дәүләтовның 680 гектар җире бар. Шуның 200 гектарында – бәрәңге, тагын 150 гектарында кәбестә, кишер, кызыл чөгендер кебек яшелчәләр үстерәләр. Ә калган мәйданда – иген культуралары.

– Уңыш күләменә килгәндә, ул бездә хәзер тотрыклы. Ел саен бер тирә дияргә мөмкин, чөнки бөтен басуларыбыз да ясалма сугарулы, – диде фермер. – Республиканың Авыл хуҗалыгы министрлыгына рәхмәт, алар ярдәме белән ике плотина төзедек, 8 «Фрегат» су сиптерү машинасы урнаштырдык. Хәзер табигать шартларына безнең бәйлелек сизелерлек кимеде. Дөрес, Аллаһы Тәгаләдән узып булмый. Шулай да хәзер, яңгыр көтеп, күккә карап утырмыйбыз инде.

«Дәүләтов» крестьян-фермер хуҗалыгында кул хезмәте бик аз кирәк, чөнки иң заманча технологияләр кулланыла. Мисал өчен, бәрәңге, кишер алу комбайннары үзйөрешле, чит илдә ясалган. Гомумән, һәр агрегат заманча. Ел саен 20–25 миллион сумлык техника гына алалар икән.

– Заманча техниканы йөртергә дә кирәк бит әле? – дим Нәсим абыйга.

– Ул яктан бәхетем бар. Ике улым – Шамил белән Камил – төп ярдәмчеләрем. Һәр төр

5
«Дәүләтов» крестьян-фермер хуҗалыгында кул хезмәте бик аз кирәк, чөнки иң заманча технологияләр кулланыла.

техниканы беләләр. Камил улым тракторларны автопилотка тоташтырды. Аның өчен космостагы иярчен ярдәмендә эшли торган 3,5 миллион сумлык җиһаз сатып алдык. «Тракторлар механизаторсыз да эшли алачак», – дип кызыктырды улым. Яшелчәне көндез генә түгел, караңгы төшкәч, төнлә дә утырту мөмкинлеге бирде ул безгә. Җеп сузган кебек, түтәлләрне тип-тигез итеп утырта алабыз хәзер. Ә бу исә югалтуларны киметүгә китерә.

Тәвәккәл йөрәкле Нәсим Дәүләтов дистә ел эчендә яшелчә үстерү буенча менә шундый «дәүләт» булдырган. Иң гаҗәбе – фермерлык эшенә ел саен ниндидер яңалык кертә. Бер урында гына тора белми ул. Уңышның сере дә шул түгелме икән?!

МАТУРЛЫК ТУДЫРУЧЫ...

Мәдәният йортында күргәзмәгә куелган чигүле яулык-сөлгеләргә башта ук игътибар иткән идек. Соңрак шушы гүзәллекне тудыручы Фәрүсә Юмаева белән танышырга да җай чыкты. Югары Тәкермән төп белем бирү мәктәбендә китапханәче булып эшләүче бу ханым үз эшенең чын остасы икән. Иң кызыгы – чигү белән ныклап торып өч-дүрт ел элек кенә шөгыльләнә башлаган һәм инде бу өлкәдә танылырга да өлгергән.

– Мәктәптә укыганда хезмәт дәресендә чигә идек, – ди Фәрүсә. – Шуннан соң бу эш онытылды. Күргәзмәләр оештырганда, әнинең чигүле әйберләрен мәктәпкә алып килә идем. Әнинең эшләре искиткеч матур. «Ә син чигә белмисеңме?» – диде коллегалар. «Беләм дә, күптән утырганым юк», – дия идем.

Берничә ел элек «Ак калфак» иҗтимагый оешмасы «Татар сөлгесе» күргәзмәсе оештыра. Фәрүсәгә әнә шунда катнашырга тәкъдим итәләр. Нәтиҗәдә, аның эше районда җиңеп чыга. Менә шуннан башлана инде. Нинди генә бәйрәм, чара булса да, Фәрүсәгә мөрәҗәгать итәләр.

– «Татарстан Республикасының чиккән картасы» акциясе кысаларында Минзәлә районы картасын чиктем, – дип горурлана оста. – Билгеләнгән вакытка сыешу өчен, иртәнге өчтә торып, кичке тугызга кадәр эшләдем. Бу хезмәтемне нык бәяләделәр, район тарихында минем дә эзем кала. Туганнар, гаиләм дә минем өчен куанды.

Фәрүсә Юмаева Югары Тәкермәнгә килен булып төшкән. Кияүгә чыкканчы Чаллы шәһәренең бер мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыткан. Җәмәгате белән бүген ике кыз тәрбияләп үстерә.

– Кызларыгызны да чигү эшенә өйрәтмисезме? – дидем остага.

– Әлегә юк, алар сәйләннән картина ясау белән мавыга. Ә болай мин эшләгәнне бик дикъкать белән карап торалар. Бәлки үсә--үсә кызыксынулары тагын да артыр.

6
– «Татарстан Республикасының чиккән картасы» акциясе кысаларында Минзәлә районы картасын чиктем, – дип горурлана Фәрүсә Юмаева.

...Авыллар яшәтүдә, төрле дәүләт программаларында катнашып җиңүдә җирлек башлыкларының да өлеше зур. (Мисал өчен, Сарман районы Карашай-Саклау, Арча районы Наласа авыл җирлекләре башлыкларының активлыгына сокланып кайткан идек.) Югары Тәкермән авыл җирлеге башлыгы Алия Шәрипова да халык өчен янып йөрүчеләрнең берсе. Ишектән кертмәсәләр, тәрәзәдән керә ул. Югары Тәкермән алга таба да токтан юлын, кыйбласын югалтмас, дип ышанып калабыз. T

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

– Югары Тәкермән авылы Казан губернасы составында пәйда булган. Тарихи документларда авыл 1709 елда оеша дип язылган. Авыл тарихы белән кызыксынучыларның сүзләренә караганда, «Тәкермән» исеме «тегермән» сүзеннән алынган.

Ләкин аның икенче версиясе дә бар: Балтай, Күзкәй, Йөзекәй исемле өч ир туган, безнең якларга килеп чыгып, бу урыннарны үз иткән дип санала. Нәтиҗәдә, берберсеннән ерак түгел өч авыл оеша: Балтай, Күзкәй һәм Югары Тәкермән. Бервакыт ул Йөзекәй Тәкермәне дип тә аталып йөргән. Тарих белән бәйле тагын бер фикер яши: аерым чыганакларда авылга Йөзекәй бабай белән Апач бабай нигез салган диелә. Тагын шунысы мәгълүм: авылны Югары Тәкермән дип рәсмиләштергән кешенең исеме Сармәт Кадерматов була. Ул да биредә яшәгән.

Алия Шәрипова, Югары Тәкермән авыл җирлеге башлыгы.

КАЗАН – ТУКАЙ ШӘҺӘРЕ (12+)

Яз саен Казанга Тукай кайта. Быел да искәрмә түгел... Г. Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры артистлары Тукайны быел сәхнәгә дә алып менә. Спектакльдә бөек шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы күрсәтеләчәк. Даһи шәхеснең фаҗига тулы кыска гомере, буыннар тарихында, аңында яшәгән образы белән кисешеп, сәхнәдә яңа театр хәрәкәте буларак гәүдәләнәчәк.

Спектакль өчен пьесаны шагыйрә Резедә Гобәева (Зәйниева) язган.

2, 3 май, 19:00 сәг.
Г. Камал исем. Татар дәүләт Академия театры, Казан, Татарстан ур., 1

афиша

«МАТУРЛЫК»НЫ КҮРМИ КАЛМАГЫЗ! (6+)

Туган туфрак... Барысы да шунда башлана һәм шунда тәмамлана. Ә менә кем булуыңны, кайдан икәнеңне оныту өчен күпме вакыт һәм ара ераклыгы кирәк? Балалар авыру әниләрен үлеп барган авылдан зур шәһәргә алып килә. Бар да дөрес шикелле: монда аны карыйлар, тәрбиялиләр, дәвалыйлар. Әмма аның васыятенә колак салырга вакытлары юк.

Мәрхүм булганчы Акъәбинең соңгы гозере бар. Ул гозерне үтәрлек кеше табылырмы? Оныклар – кечкенә нәселнең һәм зур халыкның якты киләчәге, алар дөрес адым ясый алырмы? Һәм әбиләреннән бөркелгән Матурлыкны сакларга көчләре җитәрме?

28 май, 13:00 сәг.
Кариев исем. Казан яшь тамашачы театры, Казан, Петербург ур., 55 Б



СИМФОНИК БЛОКБАСТЕР (6+)

Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә «Губернаторский» Ульяновск дәүләт академия симфоник оркестрының гаять зур концерты көтелә. Баш дирижёр Эдуард Дядюра җитәкчелегендәге оркестр симфоник блокбастерлар – «Звёздные войны», «Гарри Поттер», «Индиана Джонс», «Миссия невыполнима», «Титаник» һәм башка кинофильмнардан иң популяр саундтрекларны башкарачак. Музыкаль программа тулысынча кино галәменә чумарга мөмкинлек бирүче кинокартина кадрлары фонында барачак.

20 апрель, 18:00 сәг.
Г.Тукай исем. Татар дәүләт филармониясе, Казан, Павлюхин ур., 73

Фото: puppet-show.ru, kazan-kremlin.ru, tinchurinteatr.ru, kamalteatr.ru, tatfil.ru

ТОРМЫШ ҖЫРЫ (12+)

«Әкият» курчак театры сәхнәсендә Илгиз Зәйниев либреттосы буенча куелган «Әлфия» спектакле – бөек татар җырчысы Әлфия Авзаловага чиксез хөрмәт һәм мәхәббәт чагылышы. Әлеге спектакль җырчының тормыш һәм иҗат юлына нигезләнеп эшләнсә дә, биографик төгәллеккә дәгъва кылмый, киресенчә, бөек шәхес исеме тирәсендәге хыялга әверелә.

Әлфия Авзалова кара төндә очкан күбәләк кебек, гомере буена, үзенә ни дәрәҗәдә авыр булуга карамастан, тамашачысына яктылык, нур бүләк иткән. «Әлфия» – үз үрнәге белән башкаларның күңелендә яшәргә өмет тудыручы, көчле шәхескә мәдхия.

27 апрель, 17:00 сәг.,
«Әкият» Татар дәүләт курчак театры,
Казан, Петербург ур., 57

ЯСӘВИ МИРАСЫ ҺӘМ БОРЫНГЫ ТӨРКЕСТАН (0+)

Бөек ефәк юлындагы оазис – XII гасырда төрки-мөселман дөньясының күренекле шагыйре һәм фикер иясе Хуҗа Әхмәт Ясәви үзенең шигъри һәм фәлсәфи җәүһәрләрен иҗат иткән борынгы шәһәр белән безне «Азрет Солтан» музей-тыюлыгы (Казахстан Республикасы, Төркестан шәһәре) тупланмасындагы экспонатлар куелган күргәзмә таныштыра. Фотолар, рәсем сәнгате әсәрләре, реконструкция һәм макетлар ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирасы һәйкәле – Хуҗа Әхмәт Ясәви мавзолее турында сөйли. Экспозициядә уникаль җәүһәрләр дә – яктырткычлар, алты гасыр элек Тимерлан указы буенча төзелгән мавзолейның тышкы һәм эчке бизәлеше элементлары тәкъдим ителә.

Көн саен 9:00 дән 19:30 сәг. кадәр
Ислам мәдәнияте музее,
«Казан Кремле» музей-тыюлыгы

КАЛАЛАР ЮККА ЧЫКМЫЙ (0+)

Алтын Урданың XIII гасыр уртасында Идел елгасы ярында нигезләнгән иң зур шәһәрләренең берсе – Үкәкнең матурлыгы һәм байлыгы турында ул вакыттагы атаклы сәяхәтче һәм географлар – Гильом де Рубрук һәм Марко Поло, Ибн Баттута һәм Әбү Фида язган. Казан Кремлендә оештырылган күргәзмәдә тәкъдим ителгән археологик артефактлар моңа тагын бер кат инанырга мәҗбүр итә. Экспозициядә урта гасыр тукучылыгының искиткеч үрнәкләре һәм көмеш акчалар, зәркәнчелек, чүлмәкчелек эшләнмәләре урын алган. Экспонатлар «таудагы сандык»ның (шәһәрнең исеме монгол теленнән шулай тәрҗемә ителә) күпмилләтле һәм күпконфессияле халкы – Алтын Урданың монгол элитасы һәм элеккеге Идел буе Болгарстаны территориясендә гомер иткән кешеләр, исламлашкан мордва һәм итальян католиклары, тәңречелеккә тугры күчмә кыпчаклар һәм православиеле диаспораның үзара ничек тату-дус яшәве турында сөйли.

Көн саен 10:00 дән 18:00 сәг. кадәр (җомга – 11:00 дән 20:00 гә кадәр)
Дүшәмбе – ял
Татарстан Республикасы һәм татар халкы дәүләтчелеге тарихы музее,
«Казан Кремле» музей-тыюлыгы

ЯШӘҮ (6+)

«Ай, былбылым!» – шәһәр картлар йортында яшәүчеләрнең моңсу да, көлкеле дә тормышын бәян ителә торган комедия.

Спектакльнең геройлары гомер көзендә төрле сәбәпләр аркасында картлар йортына эләгә. Ләкин алар үзләренең биредәге тормышына һич кенә дә гомернең «соңгы тукталышы» дип карамый. Күнегелгән гадәти тормыш белән яшәүләрен дәвам итә. Хәтта Гөлҗәннәт белән Фикус кавышырга да ниятли. Тик кара күзлекле Рәхимҗан пәйда булгач кына, вакыйгалар башка төс ала.

Чын тормышны чагылдырган, елата да, көлдерә дә торган әлеге спектакль җылы атмосферасы, матур куелышы һәм театрның өлкән буын сәхнә осталарының ихлас уены белән тамашачының күңеленә хуш килер.

23 апрель, 17.00, 26 апрель, 18:30 сәг.,
7 май, 18.30 сәг.
К. Тинчурин исем. Татар дәүләт драма
һәм комедия театры, Казан, Горький ур., 13

ТАТАРСТАНДА УКЫЙСЫҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАНДА ҖИҢӘСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЭШЛИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

Реклама 16+

WWW.PROTATARSTAN.RU

12 МЕҢ КЕШЕЛЕК ИФТАР

Мөселманнарның көтеп алынган иң изге ае – рамазан да узып китте. Шунысын әйтергә кирәк: ураза тотучылар елдан-ел күбәя. Һәрхәлдә, хәзрәтләр, мәчеткә йөрүчеләр шулай дип белдерә.

Ураза тотучылар күбәйгән кебек, зурлап ифтар үткәрү дә елдан-ел популярлаша. Туганнар, кардәшләр, коллегалар – барысы да, Ураза аенда очрашып, бергәләп авыз ача.

Шундый изге чараның иң зурысы – Республикакүләм ифтар 29 мартта «Казан Экспо» халыкара күргәзмәләр залында үтте. Быел 12 нче тапкыр оештырылган масштаблы чарага 12 мең кеше чакырулы иде. Алдагы еллардан аермалы буларак, махсус хәрби операциядә булган ир-егетләр дә Республикакүләм ифтарда катнашты.

Камил хәзрәт Сәмигуллин, ТР мөфтие:

« Быел республика ифтары беренче тапкыр халыкара дәрәҗәгә чыкты: Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Кувәйт, Бәхрәйн, Согуд Гарәбстаны, Катар, Төркиядән дә кунаклар катнашты. Киләсе елга республика ифтарының географиясен тагын да киңәйтү ягын караячакбыз. Монда мөселманнар күрешә, аралаша, бергәләп авыз ачу аларны тагын да берләштерә.

Фото: dumrt.ru, Илнур Мифтахов

Вәсилә Рәхимова, журналист:

Якташларны, сыйныфташларны, группадашларны бер табын артына җыйган авыз ачу мәҗлесләре быел аеруча күп булды.

Рамазанны изге, айлар солтаны, бәрәкәт, кунак ае, инсаннарны берләштерүче ай, дибез. Без аның шушы гүзәл сыйфатларына ай буе сөендек.

Инде күмәк ифтарларга килгәндә, дини мәҗлесебез шоуга әйләнеп калмасын иде. Алайса җырлар белән гөрләп бара торган чарага әйләнеп бара кебек. Һәрнәрсәнең үз урыны, үз вакыты бар, дип уйлыйм мин. Аллаһны олылый, тәүбә кыла һәм көне-төне дога кыла торган аебызны шау-шуга әйләндермик.

Марина Заказова, күн эшләнмәләр остасы:

Бүгенге Республикакүләм ифтарда күннән эшләнгән хатын-кыз бизәнү әйберләре сатам. Аларның барысын да үзем ясадым. Эшләнмәләрне яратып алалар.

Мин христиан динендә, тик матур итеп мөселманча киендем. Бу минем ислам диненә булган хөрмәтемне күрсәтә. Татарстанда гомергә ике дин вәкилләре күрше, дус булып яшәгән, хәзер дә шулай. Бик күп мөселман танышларым бар, үзара дус яшибез, дини бәйрәмнәр белән котлашабыз. Бүгенге ифтар да күңелемә хуш килде: кешеләр бер-берсе белән аралаша, чын бәйрәм бу!

**Йосыф хәзрәт Дәүләтшин,
Казан шәһәре Вахитов
һәм Идел буе районнары имам-мөхтәсибе:**

Ифтарда бер-берең белән көрешәсең. Ә бер көрешү – үзе бер гомер, ди халык. Бүгенге көндә безнең яшьләр заман белән бергә атлый – тематик ифтарлар уздыра. Әгәр без, хәзрәтләр, теге яки бу дөрес түгел дип әйтәбез икән, алар үз тормышлары, без үз тормышыбыз белән яшәячәкбез. Ә алай ярамый.

Әйе, хәзер «Бизнес-ифтар», Fashion Iftar, тагын башкалары бар. Сер түгел, бизнес-ифтарда катнашу өчен ун мең сум түләделәр, ләкин ул акча бит хәйрия эшенә китә. Моның нинди начарлыгы бар?

Мин, мәсәлән, туган ягым Сарман районында «Остазлар ифтары» үткәрдем. Беренче елларны үземне укыткан укытучыларны чакыра идем, быел администрация белән элемтәгә кереп, райондагы барлык укытучыларны җыеп авыз ачтырдык. Киләсе елларга шигърият, туган тел ифтарлары да ясыйк. Бөтен татар теле укытучыларын бергә җыеп, аларга рәхмәт әйтәсем килә. Шуның өчен нигә әле киләсе елга барлык татар теле укытучыларына ифтар уздырмаска?

Ифтар барышында рамазан аенда игълан ителгән «Нурлы Рамазан» бәйгесенә йомгак ясалды. Бәйгедә җиңүче булып Кукмара районының Туембаш авылыннан Мөэминә Хәбибуллина йорты танылды. Шунысы игътибарга лаек: әлеге өйне хуҗабикә түгел, ә йортта вакытлыча яшәүче Нигъмәтҗановлар гаиләсе бизәгән. (Үз йортлары янганнан соң, алар вакытлыча бирегә күченгән.) Нигъмәтҗановлар Мөэминә ханымга рәхмәт йөзеннән, төп приз – хаҗга юлламаны җиңгән йорт хуҗабикәсенә бүләк итте.

Хәерле иртә!
Бу тәрәзәләр белән һәр иртәгез якты булыр!
Николай
ТӘРӘЗӘЛӘРЕ
искиткеч матур, катлаулы һәм кабатланмас
Шулай ук:
ЧЕБЕН-ЧЕРКИДӘН САКЛЫЙ ТОРГАН ЧЕЛТӘРЛӘР,
ТӘРӘЗӘЛӘРНЕ РЕМОНТЛАУ
Тел.: +7 (917) 873-49-36
РЕКЛАМА